# Казан утлары

10

ОКТЯБРЬ

1968

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

10
ОКТЯБРЬ
1968

## Бу санда:

### РОМАН, ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬ

Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Миңа унтугыз яшь иде. Повесть. 3
Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Бәйрәм; Ташлар белән; Рәхимҗан күпере; Сөрелгән җир; Сөюем борчый җанымны; Сорыйсың; Бер кычкырдым; Таш өстендә гөлләр. Шигырьләр . . . . . 43
Ф. ХӨСНИ. Поп кызы Әхсәнә. Хикәя . . . . . 47
Г. АХУНОВ. Хуҗалар. Роман . . . . . . . . . 60
К. МОСТАФИН. Тез наратлар утка аумасыннар; Урманнарга тагын ялкын капкан; Кешеләр, китмәгез! Күңелемдә сабый малай яши; Мин — бер кеше. Шигырьләр . . . . . . 95
С. САБИРОВ. Гәрәйнең бер җәе. Хикәя . . . . 98

### ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Э. ГЫЙЗЗӘТОВ. Хат ташучы; Күпме мин белгәннәр; Чия бакчасында . . . . . . . . . 122

### ЗАМАНДАШЫБЫЗ

Х. ХӘЙРУЛЛИН. Хуҗида үскән батыр. Очерк . . 124

### ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫ

М. МӘҺДИЕВ. Себер татарлары иҗаты . . . . 129

### ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА — ШАГЫЙРЬ

Ә. РӘШИТОВ. Газаплы эзләнүләр, сөенечле табышлар . . . . . . . . . . . . . . . 133

### СӘНГАТЬ

Я. ГИРШМАН. Җыр башлаучы, юл башлаучы . . 138

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. ХАРИСОВ. «Эзләр» буйлап** . . . . . . . 142

**Р. ЗАКИРОВ. Торналар китүендә; Тормыш җыры.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 145

## ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ТИРӘСЕНДӘ

**Э. КАСЫЙМОВ. Җиде сорауга бер җавап** . . . 146

## ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

**Ш. МАННУР. «Патша кызы»; Кызлар хаты; Борынгы шагыйрьдән; Картлар гыйшкы; Омтыла кеше яңага; Кайтып булса; Җенем сөйми.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 150
**Р. ГАТАУЛЛИН. Үпкә; «Бөеклек» турында.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 153
**З. НУРИ. Өйләнүдән курыккан ирләргә.** Шигырь . 154
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 155
Хөрмәтле укучыларыбызга ачык хат . . . . . 159

**Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый**

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: **Зәки Нури.**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Производствога бирелде 15/VIII-1968 ел. Басарга кул куелды 25/IX-1968 ел. ПФ 09052. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 64846 экз. Заказ Д-1363. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1968 ел.

**Габдрахман Әпсәләмов**

# МИҢА УНТУГЫЗ ЯШЬ ИДЕ

Повесть

Комсомолның илле еллыгына багышлыйм.
АВТОР

## Укучыларга берничә сүз

*Бу әсәрне язу турында бик озак еллар буе уйлап йөрдем. Башта аны документаль повесть итәрмен дигән идем, әсәрнең баш герое — разведчик-минер — чынлыкта булган кеше. Аның турында беренче тапкыр «Советская Татария» газетасында басылган В. Санников мәкаләсеннән белдем (23 февраль, 1954 ел). Аннары Санниковның үзен дә күреп сөйләштем. Ул батыр комсомолецның Казан егете булуын, фамилиясе Мулюков икәнлеген әйтте, исеме хәтереннән чыккан. Мулюковның фронттагы якын дусты — Терентьев фамилияле булган, исеме шулай ук хәтерендә калмаган. Санников аның Мәскәү егете икәнлеген генә хәтерли. В. Санников үзе — Мулюковлар хезмәт иткән аерым сапер батальонының комиссары. Батальон нигездә Казан кешеләреннән оешкан булган.*

*Эзли торгач, Мулюковның исеме Галим икәнен, Казанның Арча кыры дигән урамында — совет-партия мәктәбе подвалында торганын, унсигезенче татар мәктәбендә укыганлыгын белдем. Галим Мулюков Мәскәү янында сугышларда зур батырлык күрсәткән, үлгәннән соң аны Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исемгә куялар. Санников әлеге мәкаләсендә аңа Ленин ордены бирделәр дип яза, чынында исә ул Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән.*

*Тора-бара Галим Мулюков минем күңелемдә Мәскәү каласын саклашкан йөз меңнәрчә совет яшьләренең җыелма бер художество образы булып гәүдәләнә башлады. Ләкин әсәрне тиз генә яза алмадым, аның нәрсәседер «өлгереп» җитмәгән иде. Ниһаять, менә ул әзер. Күп нәрсә үзгәрде. Иң элек: аны хәзер «документаль повесть» дип атап булмый. Байтак нәрсәләрне файдалансам да, Галим Мулюков үзе дә бары тик прообраз булып кына калды. Әсәрнең героена Малик Газыймов дип яңа исем бирелде. Уйлана торгач, әсәрнең формасы да алмашынды. Мин аны, традиция буенча, «повесть» дип атасам да, асылда ул героик-драматик хроникага тартым булды. Тәнкыйть бу турыда да үзенең фикерен әйтер дип ышанып калам.*

*Әсәр туа-туа гомумән күп үзгәрә. Шуңа күрә бу турыда язып тору да кирәкмәгәндер. Ләкин үземнең хәтсез күп чыгышларымда укучыларга Галим Мулюков турында да сөйләгән идем. Шуңа күрә искәртеп китәргә үземне бурычлы дип санадым. Аннары әдәби эшемдә булышкан өчен укучыларга чын күңелемнән рәхмәт әйтүсем килә. Шулай ук, рәхмәтемне әйтеп, Галимнең туганнары, якын дуслары һәм хәрби иптәшләре алдында да баш иям.*

АВТОР

### 1



Мине 1941 елның декабрь азакларында Мәскәү янындагы сугышларда үтерделәр.

Үләннәрдән хат килми, алар белән инде сөйләшеп булмый, диләр. Ни үкенеч, исән чакта мин ватандашларым белән күзгә күз карашып сөйләшә алмадым. Бәлки бик яшь булганмын, бәлки тормышның әле мәгънәсен аңлап җиткермәгәнмендер, бәлки артык оялчан булганмындыр. Хәзер, соң булса да, әйтәсе сүзләремне әйтмәсәм, исәннәр алдында бурычлы булып калырмын шикелле.

Мәскәүгә без сентябрь ахырларында, ягъни гитлерчыларның яңа һөҗүмнәре башланып алдыннан, килеп төштек. Аңарчы минем башкалада булганым юк иде. Бик кызыксынган идем. Мәскәүне, Кызыл Мәйдан аркылы үтеп, Ленин мавзолеена, чал Кремльгә баш иярга уйлаган идем. Төн иде, безне ниндидер караңгы урамнардан алып бардылар, ике якта да биек таш биналар шәйләнә, бер ут юк, күктә ай да күренми, бары аэростатлар гына. Ә таң атканда инде еракта — урманда идек. Соңгы өмет белән артыма борылып карадым: Мәскәү күренмәде. Төнлә шәйләнгән биек таш пулатлар да төштә генә түгел идеме икән? Юк, монысы булмаска тиеш. Кичә янымдагы сугышчан дустым Панкратовтан да: «Бу кай төшләр?» — дип сораган идем. Панкратов җавап бирергә өлгермәде, яныбызга командир килеп житеп: «Сөйләшмәскә!» — диде.

Иртә белән мине сакка куйдылар. «Менә шул тарафны яхшылап күзәт», диде разводящий. Әнә урман юлы. Ул каядыр еракка кереп югала, буп-буш, тып-тын. Тирә-як яшел, тик ялгызак каеннар гына саргайган, гүя хәсрәт шәле бөркәнгәннәр, ә җирдә — коры, җансыз яфраклар. Сугышчылар шул яфраклар өстенә ятып ял итәләр,— төн буе килгәч, иртән ял биргәннәр иде. Тик постлар гына уяу.

Көн бүген дә аяз, жылы булачак, әнә кояш урман өстеннән ашыкмый гына күтәрелә. Тыныч, хәтта агачлар арасында ап-ак томым жепләре күренә. Сугышның якында гына булуына, кинәт урманның мең тавыш белән үкерә башлавына ышанасым килми. Аннары без, унтугыз яшьлек малайлар, дөньяда ни күргән? Дөрес, үзебезнең бердәнбер илебез — Советлар иле икәнен, аны капиталистлар күрә алмауларын, уттан битрәк куркуларын яхшы беләбез. Мәктәптә, комсомол жыелышларында безгә бу турыда күп сөйләделәр, хәтта фин сугышы вакытында шәһәребез урамнары буйлап вокзалга төшүче солдатларны — ил сакчыларын үзебез дә күргән идек. Әмма озакламыйча безгә үзебезгә дә шинель киярга туры киләсен, винтовканы кысып, фронт янындагы урманда постта торасыларны кем уйлаган? Солдат булгач, торасың икән. Хәер, солдат дигән сүз дә безгә артык ябышып бетми әле, өстебездә шинель, башыбызда пилотка, кулыбызда корал булса да, хәтта хәрби һөнәргә аз-маз өйрәнсәк тә, башыбыз тыныч тормыштан, дөресрәге, юләр балалыктан чыгып бетмәгән әле. Шуңа күрә дөньяны бик аз беләбез, безгә бөтенесе кызык, яңа. Башкасын ни әйтәсең, без Мәскәүне дә кинода гына күргән бит, менә бу көз сулышы йоккан урман да безгә искиткеч кебек, анда тәгәрәп-тәгәрәп уйныйсы, ике кулынны ирен почмакларына китереп куеп, урманны яңгыратканчы: «А-у!» дип кычкырасы килә. Еллар үткән атналарда, айларда үтәргә тиеш булуыбызны уйлап та карамыйбыз.

Мин, ике күземне дүрт итеп, урман арасыннан сузылып киткән юлга карыйм. Юл һаман буп-буш, машина да, атлы да, җәяүле дә күренми анда. Йөренәм, тагын карыйм. Һаман шул күренеш. Башта үземне бик һәйбәт сизгән идем, гомердә күзгә йокы килмәс кук тоелган иде, әмма тора-бара керфекләр авырая башлады, әйтерсең, аларга тимер таккаңнар, күзләр ихтыярсыз йомылалар. «Солдат... аягүрә төш күрә», дип җырлыйлар иде картлар. Дөрес икән, курәсең икән, ләкин йокы тәэсирена биреләсе килми, суны ике якка ерып йөзеп чыккан кебек, йокы елгасыннан чыгасың, башыңны селкеп тирә-ягыңа каранасың, агач төбендә таптанасың. Каһәр суккыры, бераздан тагы йокы баса, менәменә егылып китәрсең дә бер упкынга очарсың кебек. Ләкин ярамый, син постта, дошман якын. Шул йокы батыр Чапаевны да харап иткән бит. Борынга дары исе кергәч, үзгәрәсең, диләр, мөгаен, шулайдыр, әмма безнең чынлап торып дары иснәгәнебез юк, өйрәнүләрдәге дары исләрен исәпкә алмыйсың, анысы аның болай гына, уен гына иде.

Ниһаять, мине постымнан алыштырдылар, ял итәргә куштылар. Түшәк әзер, агач төбенә бөгәрләнеп яттым да йокыга да киттем. Иптәшләр миңа кайнар аш алып кайтканнар, уятып караганнар. Кая ул, күземне дә ачмаганмын. Тик поход колонналарына тезелергә команда булгач кына сикереп тордым.

Мин — озын буйлы, киң җилкәле. Мине тылда ук Абрек дип йөртәләр иде. Хәтерлисездер, ул заманнарда малай халкының төшләренә керә торган «Абрек Заур» дигән кинофильм бар иде. Күрәсең, бу картинаны мин бик тә яратканмын, шуннан үземә кушамат та тагылып калган. Тышкы кыяфәтем дә, холкым да Абрекка бераз туры килгән. Тагын, яшереп торасы юк, бу кушамат минем үземә дә ошый. Дөрес, Кавказ дигән җирләрне белмим, шәһәр малае булгач, атка да атланып йөрмәдем, минем өчен таулы урыннар бары тик шул Казанка буйлары гына, ләкин буйсынмас Абрек буласым килә. Казанка буйлары әле дә мине сагына торгандыр, мин аларны Абрек булып күп айкадым.

Армиягә алгач, безне стройда җырлаталар да иде. Минем тавышым калын, ярыйсы матур, һәрхәлдә, солдат җырларын кычкырып җырлап җибәрсәм, урман яңгырый. Моны никадәр булгандыр тагы, анысын әйтә алмыйм. Фронт янындагы урманнарда исә кычкырып җырлатмыйлар, сүзсез генә барабыз. Бары тик бик күп аяк тавышлары гына дөпелди. Эссе, каскалар астыннан тир ага, урманда җил юк, һава оеган кебек.

Күкне күзәтергә команда булды, кайдадыр дошман самолетлары оча. Мәскәүгә баралармы, әллә гаскәрне эзлиләрме? Баштагы барлык бүтән уйлар очты. Безнең әле авиация һөҗүмен дә күргән юк, әллә нинди куркыныч нәрсә көтәбез. Ул арада юл уң якка таба борыла. Колоннаның башы күренми, артыма карыйм — очы да юк. Без кайдадыр урта бер җирдә. Колонна туктамый, бара да бара.

Кәне буе юлда булдык, арылды, тамак кипте. Бу вакытта урман инде күптән беткән, юл әле игеннәре дә яхшылап җыеп алынмаган кыр буйлап бара, әле ниндидер кешесез авылларны үтәбез. Ашыктыралар. Дошман әлегә безне һавадан борчымаса да, аның турында берсеннән-берсе яманрак хәбәрләр йөри: имеш, ул берничә карамый һаман алга килә, бөтен җирне бомбага тота. Без, чын сугышны күрмәгән яшь солдатлар, моңа артык ышанмыйбыз да, гаҗәпләнәбез дә, нәрсәнедер аңлап та бетермибез. Бар теләгебез тизрәк дошман белән очрашу. Очрашкач, борчулы уйлар да бетәр төсле, чөнки синең алдыңда фашист, ә фашистны нишләтергә кирәк икәнен син беләсең.

Сугышның үз законнары бар, ул мәсьәләне күп билгесезләр белән хәл итә. Сугышка кергәндә була торган табигый курку тойгысы безне читләтеп үтмәстер, пуля, мина, снаряд астында яту күнекмәгән яшь солдатка җиңел булмастыр. Ләкин ул турыда алдан уйлап баш ватасы гына юк, чөнки барыбер очына чыга алмассың. «Солдатка хәрәкәт кирәк, хәрәкәттә ул нишләргә кирәк икәнен белә», ди иде безнең командир хәрби эшкә өйрәткән чагында. Ләкин әлеге дә баягы шул тәҗрибәсезлек: хәрәкәтне дә без үзебезчә генә аңлыйбыз, ягъни туры мәгънәсендә генә күз алдына китерәбез. Баштан үтмәгәч, кыен шул.

Кечрәк кыска ялга туктадык, тамак ялгап алдык. Тирә-ягыбыз ниндидер бер әрәмәлек, инеш буе. Минем яныма бергә уйнап үскән дустым, хәзер шулай ук минем кебек солдат — Мөнир Сәфәров килеп утырды, тәмәке төрә башлады.

— Тартасыңмы?

— Тартасым килми.

Мөнир миңа күз кырыйлары белән астан гына карады. Аның күзләре коңгырт. Берсе көлемсери шикелле, икенчесе бер дә шаярмый кебек. Әгәр Мөнир белән күптән таныш булмасаң, аның белән ничек сөйләшергә дә белмәс идең. Әнә кояшта янган йөзе нинди җитди сыман,

ә пилоткасын кыңгыр салган. Монысында инде егетлек тә, көязлек тә бар. Мөнир — ярыйсы мут егет, кызлар янында аның югалып калганын һич хәтерләмим. Тик хәзер кызлар янына бармыйбыз.

— Бу обмоткалар, малай, старшина шикелле, гел теңкәгә тия, атлаган саен чишелә дә чишелә. Син менә хәйләсен беләсең, ахрысы, синеке бер дә чишелми.

Ул сүтелгән обмоткасын яңадан урый. Мин аңа старшина өйрәткәннәрне игътибарсыз гына кабатлап барам. Егетлек горурлыгы бар бит, әллә нинди шайтан чүпрәкләре турында житди итеп сөйләмәссең инде. Үзем эчемнән әзрәк горурлана да төшәм, син әле ул солдат фәнен белмисең, ә мин инде аны үткән!

Кинәт Мөнир кычкырып көлеп җибәрде.

— Я, Абрек,— диде ул миңа кушаматым белән. Мөнир булмаса, минем кушаматымны армиядә кем белер иде, минем үз исемем дә бар лабаса,— кайчан сугышка керәбез инде? Мин, малай, берәр фрицны теге дөньяга озатмыйча үземне солдат дип исәпли алмыйм.

Мөнирнең кычкырып көлүе аның беренче сугыш турында шактый күп уйлавын, борчылуын күрсәтә иде. Үзе юри шаян тон белән шуны капларга тырыша. Мин моны шунда ук сизеп алып, аз гына көлемсерәп куйдым.

— Алдан белеп булмый бит: әллә син аны озатасың, әллә ул сине.

— Минеме? Теге дөньягамы? — дип сорады Мөнир.— Озатмый торсын!

— Ник? Ул да пуля җибәрә, син дә. Ә пуляга барыбер.

— Абрек, син уйлабрак сөйлә.

— Ә син дустың алдында мактанма. Мин сине бик яхшы беләм.

— Син мине безнең взводтагы теге хәчтерүш солдат дип исәплисеңме? — дип кызды Мөнир.

— Ярар, барып житкәч күрербез, алдан тел талдырасы килми,— дидем мин, сабыр гына.

— Дөрес, хак сүзгә җавап юк, бәрәңгедә сөяк юк, Абрек. Илгә хатлар язасыңмы? — Мөнир, җеп очын яшерергә теләп, сүзне икенчегә борды.

— Башта бераз сугышыйк.

— Ә «сандугач»ка?

— Аңа да рапорт бирергә иртәрәк әле.

— Юк, малай, ул миңа тиеш иде дә, ярый, син игелеген күр, борын кызганыч! — диде Мөнир, тагын кычкырып көлеп.

— Сөйлә, бик теләсәң, борыныңны тагы кулыңа тоттырырмын.

— Рәхмәт, мин аннан тәүбә иттем инде. Син аю ич!

Мин, гадәтемчә, Мөнир белән артык шаяртмыйча сөйләштем. Хәер, ул минем холкымны яхшы белә. «Сандугач» турында сөйләгәндә тавышым әзрәк йомшаграк яңгыравын да, күз карашым бераз үзгәрүен дә ул, һичшиксез, сизгәндер. Мөнирдән бер нәрсәне дә яшереп булмый, мин яшермим дә. Тылда чакта ул минем күп кенә хикмәтләргә турыдан-туры катнашып, миңа булышып йөрде. Үнсигез, унтугызда сөю дә, юләрлек тә муеннан бит. Ул чакта мин Мөслимәне («Сандугачым»ның исеме шулай иде) чынлап ярату-яратмавымны да яхшылап белми идем. Ә хәзер аны һич тә оныта алмыйм, бирәүгә дә бирергә теләмим. Ул гүя күзгә күренмичә минем һәр адымымны күзәтеп тора. Бу миңа яшертен ләззәт бирә, сүз белән булмаса да, минем эшләгән барлык эшләремә кем алдындадыр хисап бирәсем бар кебек. Мөслимә алдында миңа алдашырга да, хәйләләргә дә, мактанырга да ярамый, ул барыбер һәммәсен дә белә. Бәлки безнең кебек унтугыз яшьлек солдатлар гына мәхәббәтне шулай югары күтәрә торгандыр. Ничек кенә булмасын, ул минем авыр солдат тормышымны нурландырып тора.

Безнен янга Панкратов килеп утырды. Балтырында алюмин кашыгы ялтырый. Чәче жирән, йөзе сипкелле, холкы сабыр, яшькә бездән олкәнрәк. Аның дәрәҗәсен күтәрә торган як тагын шунда: ул сугышта булырга, житмәсә яраланырга да өлгергән. Безгә ул Казан госпиталеннән килеп кушылды. Икәүдән икәү сөйләшергә яратса да, лыгырдык түгел, эреләнми, мин инде күпне күргән, дип мактанмый, ничектер сине тиң күреп, синә ышанып сөйли. Әйтүенә караганда, ул Мәскәү егете, кайсыдыр заводта токарь булып эшләгән. Монысы инде армиягә кадәр. Заводтан ул армиягә киткән. Июнь ахырларында сугышка кергән, тик берничә көннән яраланган. Ярасы турында да, сугыш хәлләре турында да сөйләми, тик кайчак кына ачылып китә. «Немец, билгеле, көчле ул,— ди Панкратов, ком өстенә нәрсәләрдер сызгалап,— танклары, авиациясе күп, хәтта безнең бер сугышчы артыннан самолет белән куган чаклары була. Пехотасы да акны-караны карамый, бик эре, кәпрәеп килә. Шулай да фрицларны кыйнарга мөмкин. Безнең егетләр аларны кайбер урыннарда үкертеп-үкертеп кистеләр. Мин үзем күрдем.»

Политрук бер тапкыр Панкратовны политзанятиедә дә сөйләтмәкче булган иде, ләкин Панкратов, гомердә халык алдына чыкканым юк, дип көч-хәл белән котылып калды. Шуннан соң аңа хәтта кайберәүләр кырын карый башладылар, немец алдында шөр җибәргән, ахрысы, үзе житмәсә коммунист әле, дип сөйләнгәләделәр. Миңа калса, Панкратов алдашмый иде. Сугыш башында яралан да мактан, имеш. Шундый хәлгә эләксәм, мин үзем дә тешемне кысар идем. Әнә ул Мөнирләр заводындагы хәчтерүш солдат кына борчак сибәргә ярата. Панкратов күп сөйләшмичә дөрес эшли ул, сүздән ботка пешми, ди торган иде минем әткәй. Сугыш эшен, коралны Панкратов яхшы белә, бу яктан ул миңа да күп булышты. Солдатка коралын белергә кирәк. Пластунча шуышуның да, гранната ташлауның да рәте бар. Мин күбрәк көч белән алдырам, осталык житешми. Панкратовның көче минекеннән кимрәк, ләкин гранатны ул нәкъ сызык турысына ташлый, пластунча шуышканда да жиргә сыенып бара.

Мәктәптә мин яхшы ата идем, хәтта бүләкләр дә алгаладым. Әмма анысы аның кечкенә калибрлы винтовкадан. Солдат винтовкасыннан атканда пуляләр, командир әйтмешли, «сөт эзләргә» киткәлиләр. Аннары мишеньнарга ату — төбендә уен гына бит ул. Син үзеңә бер кемнең дә янамавын беләсең, шуңа күрә аз гына да кабаланмыйсың, каушамыйсың, яхшылап төзисең. Ә сугыш кырында хәл бөтенләй башкача бит. Дошман шыр тиле түгел, син атканны көтеп тормас. Син чакмага басканчы, ул алданрак басса — эшең бетте дигән сүз.

Панкратов бер дә иренми, ун тапкыр сорасаң да җавап бирә, аңлата, сугыш үзе өйрәтер әле, дими.

Панкратовның башкалабыз Мәскәү турында сөйләүләре дә миңа ошый. Әлбәттә, үзем анда булган булсам, күрсәм, урамнарында йөрсәм, авызымны ачып тыңламас идем. Казан турында күпме сөйләсәләр дә, үтә кызык булса да, артык исем китми бит, чөнки барысын да беләм. Дөресен дөрес дим, ә менә бу урында авызыңнан тере саескан очырасың, дим. Ә Мәскәү турында ни генә сөйләсәләр дә ышанам, ялган булмаска тиеш дип карыйм, чөнки Мәскәү белән ялган минем башымда икесе бергә сыешмый, мин аларны берничек тә янәшә куя алмыйм.

Солдат тормышында, бигрәк тә тылда, тын минутлар була. Туйганчы пластунча шуышканнан яки ура кычкыра-кычкыра «атакага» барганнан соң, кайда булса чокыр төбендә яки күләгәдә ятабыз. Шунда Панкратов башкала турында сөйли башлый, кычкырып, мактанып яки рәсми рәвештә түгел, бәлки бераз хыяллана төшеп, якын итеп, әкрен генә гәп кыла. Ышанасыңмы, юкмы — анда аның эше юк, ул сине көчләп ышандырырга тырышмый да. Яки менә син караңгы землянкада ятасың. Син дә, иптәшең дә яңа гына посттан кергәнсез, тышта шыбырдап яңгыр

ява, киемнәрен чыланган, аларны мич янына кибәргә элгәнсен, Панкратов, кулларын баш астына куеп, тагын Мәскәү хәлләрен сөйли. Ахрысы шунардыр, мин, ниһаять, Мәскәү туфрагына аяк баскач та, анын таш урамнарына исем китеп карап бардым. «Бу кай төшләр?» дип Панкратовтан сорадым. Тик ул чакта сөйләшеп булмады, хәзер безгә беркем дә комачауламый. Мин тагын Панкратовтан башкала турында сораштырам.

— Кай төштән узганыбызны мин үзем дә абайламадым,— диде ул.— Бөтенләй ят шәһәрдән үттек шикелле. Караңгы иде шул. Ә мин Мәскәүне бер вакытта да караңгы итеп күрергә күнекмәгәнмен.— Бераздан әрнегән кебек өстәде: — Яктырак булса, кайдан баруыбызны, билгеле, таныган булыр идем.

— Миңа бер тапкыр башнялар күренгән шикелле булды. Кызыл мәйдан тирәсе түгел идеме икән?

— Юк, Кызыл мәйдан Мәскәү елгасы буенда. Без елга кичмәдек.

— Кызыл мәйданны күрәсе иде! — дидем мин.

Панкратов минем ни өчен өзелеп әйтүемне аңлады булса кирәк, үзе дә көрсенеп:

— Минем үземнең дә сугышка керер алдыннан Кызыл мәйданны тагын бер күрәсе, Ленинга баш иясе килгән иде,— диде.

Сафка тезелергә команда булды. Барыбыз да урыннарыбыздан сикереп тордык. Мөнир үз взводына китте. Без, Панкратов белән бер взводта булгач, шунда ук сафка бастык.

Политинформацияләрнең берсендә политрук безгә шаталак Гитлерның коточкыч мактануы турында сөйләде. Ул әйткән икән: герман армиясе көнчыгыш фронтта «генераль» һөҗүмгә күчәргә әзер. Кыш килеп җиткәнче үк Россияне тар-мар итәр өчен бөтен чараларны күрдек, дигән.

Чыннан да, гитлерчыларның Мәскәүгә «генераль» һөҗүме 30 нчы сентябрьдә башланды. «Үзәк» дип аталган армия группасы берләшмәләренең уң канаты безнең Брянск фронты гаскәрләренә китереп сукты, 2 нче октябрьда, таң белән, «Үзәк»кә кергән армиянең яна төркеме Көнбатыш һәм Резерв фронтлары гаскәрләренә каршы һөҗүмгә күчте. Нәкъ сугыш башындагы кебек үк, иң алдан дошманның танк берләшмәләре кузгалды, һавада авиациясе үкерде...

## 2

Казанда Арча кыры дигән борынгы урамны беләсезме? Шул урамда, культура һәм ял паркы турысында бер мәһабәт бина бар. Патша заманында анда духовная академия булган, безнең заманда — совет-партия мәктәбе. Ул таш коймa белән уратып алынган борынгы бакча эчендә утыра. Бинаның өске катларында кеше тормый, ул уку-укыту эшләренә көйләнгән, анда исәпсез-хисапсыз аудиторияләр, клуб, китапханә, спорт залы. Түбәндә, подвалда, дворниклар, җыештыручылар, буфетчылар, истопниклар, шоферлар, тагын әллә кемнәр тора. Подвал коридоры бик озын, керсәң, бер башыннан икенче башы чак күренә. Анда балалар өч тәгәрмәчле велосипедларда йөриләр.

Мин менә шул подвалда үскәнмен. Әткәй — истопник, әнкәй — идәннәр себерүче. Безнең семьяда тагын миннән бер-ике яшь кече сеңелем бар. Ул бала чактан ук укытучы булам дип хыяллана иде. Безнең нибары бер бүлмә, күп булса унбиш-уналты квадрат метр. Ләкин, әнкәй чисталыкны бик яратканга, бүлмә һәрвакыт җыештырылган була. Сеңелем белән мин дә тәртипне бозмаска өйрәнгәнбез: кышын коридорда, җәен ишек алдындагы бакчада уйныйбыз. Монда инде ирек, безнең йөгәнсез башларны беркем дә тыймый.

Безнең подвалда аксөякләр юк, бар да эшле, эти белән әни — мәктәптә, буйга үсеп җиткән яшь-җилкенчәк исә читтә, төрлесе төрле хезмәттә. Бездә, балаларда, кечкенәдән үк хезмәткә тирән хөрмәт тәрбияләнә. Ак эш, кара эш дип сөйләнүләрне белмибез, гомумән без эшнең зурысы-кечкенәсе, яхшысы-яманы, авыры-җиңеле турындагы сүзләрне ишетмәдек. Әнкәй чиләге-чүпрәге турында кайгыртса, эткәй мичен, көрәген, күмерен белде. Мин кече яшьтән үк зур дәрәҗәле кешеләрнең эткәй белән ягулык турында ипләп сөйләшүләрен, еш кына киңәш сорауларын күреп үстем. Әтинең язу-сызу эшендә белеме юк, газетаны да иҗекләп кенә укый, хатны гарәп хәрефләре белән генә яза иде, хәрефләр алмашынгач, чак надан калмады.

— Ну, үз эшемдә мин ни тукмышты зур, безнең школага килеп йөри торган профессор белән бер,— ди торган иде ул, кара мыегын бөтереп.— Пример, ут. Башта аны бала да өреп сүндерә ала. Өф итте, бетте-китте.— Ул бик мәзәк иттереп утка өргәндәй итә, аның мыек очлары селкенеп куя, без, балалар, кычкырып көлеп җибәрәбез.— Көләсез, ачык авызлар. Ә соңыннан? Син аңа ни тукмышты болай, сулышың беткәнче өрсәң, төкерсәң дә ул гөрли генә. Гөрли, чорт возьми, дулый! Әнә нинди дәү йортны җылыта ич ул! Профессор үзе әйткәне бар миңа: рәхмәт, Шәйхулла, син барда бүлмәләр май кебек, ди. Май, белдегезме, май! Ну, йонлы колак булма, йонлы колак булсаң, эшләгәндә авызыңны ачсаң, казанны да шартлатуы, таш бинаның астын өскә китерүе дә мөмкин, ут белән шаярырга ярамый! Ну, без аның режимын беләбез, безгә ул страшно түгел. Эшчегә, балалар, бөтен нәрсә буйсына. Ни тукмышты аерым кеше, дөнья да аның кодрәтенә баш ия. Алла-тәлә бардырмы, юктырмы, белмим, безнең казан янына килгәне юк, ну, эшче үз урынында алла ул, бардыр, бердер!

Әтинең шуңа охшашлырак сүзләрен күп тапкырлар ишеткәнем бар. Билгеле, боларны ул әзрәк тамагын чылаткач сөйли торган иде. Ул әзрәк мактана да, горурлана да. Якасын ычкындырып, такыр башына түбәтәен каплап, ишек алдындагы карт агачлар астында утыра, үзен сырып алган балаларның әле берсен, әле икенчесен коча, башларыннан сыйпый яки, кара мыегын күпертеп, җинелчә кытыклап та куя. Балалар аны яраталар, «Шәйхулла абзый, Шәйхулла абзый!» — дип үлеп торалар. Мондый чакта эткәй гражданнар сугышында катнашуы турында сөйләргә ярата иде. Ул разведчик булган, иләр-иләрне генә башыннан кичермәгән. Кайчагында ул мыегын бөтереп:

— Ышанмыйсыз, Шәйхулла абзый тавыкка да тими дип уйлыйсыз, ә? Рас анысы, тавыкка тимим, ну, мине ачуландырма, сөяләмә басма! — ди иде ул.— Бер вакытны шулай, әле патша армиясендә хезмәт иткәндә, бер генерал зрә теңкәгә тиде, солдатлар прямо нишләргә дә белмиләр. Ну, мин әйтәм, бик җилләнәсең, генерал, без җилләнә башласак, нишләрсең икән? Бер заман революция булды, солдат арасында буталыш китте. Генерал безнең алга килгән, ни тукмышты солдатка җылы сүз әйтергә, элеккедән дә бигрәк бугазын ера. Минем винтовка кулда иде. Күп уйлап тормыйча, строй алдында шалт генералны. Ә сез тавык дисез... Беләсегез килсә, без Совет властен алып кайттык. Менә кем ул Шәйхулла абзагыз!

Айнык чагында эти күп сөйләми, башын ия төшеп йөри, эшләгәндә тәмам корымга бата, кепкасы козырегы белән артка борыла.

Мин этигә яшьтән үк булыша идем, усә төшкәч мичкә күмер дә ташлаштыргалый башладым.

— Вот тәк, физкультура! — ди иде эткәй белән эшләүчеләрдән берсе.— Югыйсә мускуллары нык, таза булсын өчен әнә анда, өстә, тимер алкаларда атыналар. Менә кайда мускуллар үйный ул. Я әле, Малик, беләгеңне күрсәт. О-о, таш кебек! — ди ул, минем беләгемне капшап.

Минем дә моңа кәеф килә, миннән бигрәк эти шатлана.

— Өйрәнсен! — ди ул, әчке бер горурлык белән. — Һөнәр ул кешенең кесәсендә бетми торган мал. Акча ул бүген бар, иртәгә юк. Һөнәрни тукмышты гомер буена житә, кала да. Үскәч, укыгач, кем булыр — анысы башка, — ну, яшьтән эшнең тәмен белсә, әпәйнең дә кадагы күпме торганын чамалый. Ә анысы безгә, рабочий халыкка, бик кирәк.

Әтинең бераз эреләнә төшеп әйткән сүзләре вакыт-вакыт миңа бик үк аңлашылып та бетми, ләкин мич ялкынының кызыл шәүләсе уйнаган йөзе миңа бик-бик якын, хәтта илһамланган төсле тоела. Мин, егетлегемне күрсәтеп, каерылып-каерылып мичкә күмер ташлыйм.

Безнең бүлмәнең тәрәзәләре ишек алдына каравын әйтмәдем бугай. Ишек алды артында да таш койма белән тотылган зур бакча бар. Көндез анда совет-партия мәктәбендә укучылар имтиханнарга хәзерләнәләр, кичләрен бакча малай-шалай иркенә кала.

— Бу дәү агачларны яшь изгеләр — буласы поплар утырткан дип әйтәләр,— ди ишек алдына чыккан әти. Бәйрәм хөрмәтенә ул, үзе әйтмешли, тагын әзрәк тамак чылаткан, шуңа күрә теле чишелгән.— Хәере белән булгач, түбәләре, әнәү, күккә тигән. Карасаң, ни тукмышты башка нәрсә, кәпәч төшәрлек. Менә төште дә, чорт возьми. Әй, ыланнар, кая минем кәпәч? — Әткәй жирне кармалый, без кычкырып көләбез, аннары сиздерми генә кәпәчне әткәйнең башына каплыйбыз.— Әттә генәсе, түбәдә икән, ни тукмышты төшәргә... Һәй, ыбыр-чыбыр, ник көләсез, сезгә карга ояларын гына туздырырга булсын. Малик,— ди ул миңа,— әнәү теге агач башындагы карга оясына менә аласыңмы? — Ул бакчаның аргы башындагы иң биек агачка күрсәтә.— Юк, анда менә алмассың. Баскыч кирәк, әйеме?

Агач башларындагы карга ояларын туздырырга безгә генә куш инде. Минем тирәмә үз йортыбыздан гына түгел, күрше йортлардан да малайлар жыела. Мин аларның үзенә күрә бер башлыклары, атаманнары. Абрек дигән кушаматны да миңа шунда тактылар инде. Тик анысы бераз үсә төшкәч, йөземдә, килбәтемдә, уз-үземне тотышымда шул Абрек чалымнары күренә башлагач булды бугай. Хәтерлим, көч көннән-көн арта бара, аны кая куярга белмисең, шуннан инде төрле шаярулар китә, жен көтүе кебек бөтереләбез. Әле генә ишек алдындагы бакчада идек, инде күр, парк буйлап чабабыз, биек агач башларына менәбез, баш әйләндергеч тизлек белән даган атынабыз.

Мин үзебездән ерак түгел Толстой бакчасы чатындагы унсигезенче татар мәктәбендә укыдым, шунда комсомолга да кердем. Укуым болай ару гына булса да, дисциплина ягы аксады. Әледән-әле үземнең Абреклыгымны күрсәтә идем. Тәнәфес вакытындагы шаярулар еш кына киртәдән чыга. Менмәгән койма башлары да, класста парта өсләреннән чабулар да калмый. Аннары иптәшләрне Казанка буена алып китәм, су керәбез, көймәдә йөрибез, иң хәтәр чоңгылларга чумабыз, чокыр-чакырлардан үтеп, Казанка ягыннан паркка керәбез. Монда текә таулар, тирән ерганаклар, куе чытырманлыклар бихисап. Безгә, көчләрен кая куярга белмәгән Абрекларга, шундый жирләр кирәк тә инде. Шаярабыз, шуышабыз, дөмбәсләшәбез. Кеше йөрми торган чытырманлыклардан ыргылып чыгып, кемнең дә булса өстенә искәрмәстән, юлбарыс кебек сикерәбез... И ул Казанка буендагы уеннар! Сөйләсәң, кеше ышанмаслык нәрсә. Бит-баш та кугәреп чыга, кулмәкләр дә ертыла. Ә икенче көнне кемдер әләкләгән була — укытучылар чакыра, оялталар, әрлиләр, мондый шаярулар мәктәп балаларына, пионерларга бер дә килешми, диләр, әтине, әнине дә мәктәпкә китертәләр. Минем әни — йомшак күңелле кеше, миңа бер вакытта да сукмый, бары елый гына, кеше алдында йөземне кызартасың, ди. Мин аны кызганам, хәтта берничә көн әйбәт кенә йөрим. Аннары барысы яңабаштан башлана. Әти исә күп сөйләшеп тормый.

— Син, әт тырнагы, башкисәрлеккә язылдыңмы әллә? Молокосос Абрек! Мин сиңа бирермен. Марш! — дип, шундый иттереп салып җибәрә, янак төбе берничә көн ялкын кебек кызарып йөри, кешегә күренерлек түгел. Сыер дуласа, аттан яман була дигәндәй, болай бик юаш әткәйнең, кызып киткәч, шулай бер җилләнеп алуы миңа кечкенәдән билгеле, шуңа күрә мин аңардан шактый шүрлим. Давыл үткәнче басынкы гына йөрисең, аннары зилзиләләр онытыла, тагын дөньяның астын өскә китереп шаярасың. Ниһаять, тагын директор бүлмәсе, тагын әти-әни шунда утыралар. Бу юлы инде дәрестән соң өйгә кайтырга да куркасың, әтинең өйдәме-юкмы икәнен белергә Мөнирне җибәрәсең. Соң булса да өйгә кайтмый булмый бит. Әткәй караңгы чырай белән өстәл янында утыра...

Урта мәктәпнең соңгы классларында укыганда мин буйга бик нык үсеп киттем, җилкәләрем дә киңәйде. Күп кенә сабакташларымны узып киттем.

— Әттәгенәсе, нишләтә бу подвал һавасы,— ди иде әткәй, кәефе яхшы булса.— Ни тукмыйшты болай, әнинең чүпрә белән сыйлаcа гына...

Әллә ничек кенә булды, мин шаярулардан туктала төштем, укуга, комсомол эшенә бирелдем. Билгеле инде, бу хәл әллә ничек кенә булмагандыр, укытучыларның да, комсомолның да ярдәме күп тигәндер. Тик без моңа хисап кына бирмибез, бу шулай булырга тиеш дип уйлыйбыз.

Әйткәнемчә, әни мәктәптә җыештыручы булып эшли иде. Кеше булмаганда, кичләрен, әнигә ияреп мин дә спорт залына керәм. Миңа Мөнир тагыла. Әнкәй безне бик нык кисәтә, иплән кенә уйнагыз, ватмагыз, сындырмагыз, ди. Баштарак без үзебез генә уйный торган идек. Соңга таба, кыяфәтебез совет-партия мәктәбе укучыларыныкыннан әллә ни аерылмый башлагач, алар белән дә уйнаштыргаладык. Волейболга да, баскетболга да, гимнастикага да минем сәләт бар. Турникта атынганда башкалардан уздыргалап та җибәргәлим. Әлек, билгеле, спорт залына да киенми-нитми йөри идем. Аннары әнкәйдән үтенеп-үтенеп спорт костюмы сатып алдырдым. Аякка ак тапочкалар да булды.

Бер заман шушы спорт залында нечкә генә гәүдәле, иңнәренә төшкән күе сары чәчле, зәңгәр күзле бер кыз күренә башлады. Бу мәктәпнеке түгел, моны без бик тиз белеп алдык. Аның монда апасымы, җизнәсеме эшли. Кыз физкультурага ярыйсы оста, житез. Турникта хәтта миннән уздыра. Минем базар шактый төште. Кайчакта ул хәтта миңа атап:

— Алай түгел, Малик. Менә карагыз, болай,— дип, алкаларда шундый җиңел атынырга тотына, минем исем китә. Әлбәттә, малай чакта җиңелүеңне тану бик авыр, бу хурлыктан котылу өчен әллә ниләр эшләр идең, ләкин мин кызга чынлап торып ачулана да алмыйм, ул гүя мине сихерләгән. Моны хәтта Мөнир дә сизеп алган иде. Кызның артык игътибар итмәвен күреп, ул җае туры килсә дә, килмәсә дә, мине үрти башлады:

— Я, Абрек, эшең бетте, әлхам-төлхәм аллаһы әкбәр, ботарлады да салды үзеңне кыз бала,— ди.

Минем моңа ачу килә, ләкин түзәм. Әмма йөземнең үзгәрүе, хисләремнең ташуы шул хәтле көчле булган, ахрысы, бер көнне Мөнир шулай шаяртып торган чагында кыз, чак кына кызарып:

— Нинди Абрек булсын ул, аның үз исеме бар. Шулай бит, Малик? — диде.

Ул чакта миңа ничек дәшсәләр дә барыбер иде. Абрек дигәндә мин башкалардан нәрсә беләндер аерылам кебек, анда хәтта ниндидер сер, канатлы романтика бар сыман. Әмма Мөслимә әйткәч, минем үз исемем дә нурланып киткәндәй булды. Ләкин кызык хәл: мин кызга әйе дип тә, юк дип тә әйтә алмадым. Алай гына да түгел, минем аптырауны кыз

ачык сиздә, ахрысы. Йөзен чытып, читкә борылды. Минем югалып кала торган гадәт булмаса да, бу юлы әллә нишләдем. Шул көннән башлап бөзнең арадан, әйтерсең, кара мәче узды. Берничә көн ялгыз-ярым паркта, чокырларда сызгырып йөрдем, хәтта Арча кыры зиратына барып чыккаладым. Шуннан бүтән рәтле нәрсә уйлап таба алмагач (дөресрәге, уйладыммы икән? Башымны иеп сызгырып кына йөрдем-ме?), яңадан спорт залына кайттым. Мөнирнең авызы колакларына житкән, миннән ачыктан-ачык көлә.

— Я, Абрек, парктагы тирән чокырлардан нәрсә таптың? Зираттагы өрәкләр яшь егеткә бирәр киңәш бирмәделәрме?

Ачу бик ташыса да, уч бик кызып торса да, Мөниргә җавап бирмәдем, аның сүзләрен ишетмәмешкә салыштым. Ә Мөслимәнең адым саен тенкәсенә тия башладым. Аның холкы сабыр, минем тилерүләремә каршы ул кычкырып көлә генә.

— Син, Малик, үчекли дә белмисең, сиңа теләсәң дә ачуланып булмый. Син зур бала шикелле. Ахрысы, мине бик ачуландырасың килә, әйеме? Я нәрсәгә шулай гурсаясың, тиле, нигә ачык әйтмисең?

— Әйтер иде дә телен өрәкләр кисеп алган! — дип, утка май салды Мөнир. «Тукта, шайтан сыбызгысы, мин сиңа күрсәтермен әле, ник көлгәнеңне онытырсың!» — дим эчемнән, тешләремне кысып.

— Син зиратта йөрисеңме, Малик? Анда күңелсездер, башка әллә нинди уйлар килә торгандыр? Мин бакчада, халык арасында булыр идем.

— Ә Абрек тирән чокырларда Лермонтовның демоны кебек караңгы чырай белән йөри.

— Лермонтовның демоны чокырларда йөрмәгән инде, Мөнир, юкны сөйләмә.

— Якла, якла, әнә Абрек ничек елмая!

Мөнир юри чәнчеп әйтә, мин елмаймыйм, елмаерга уйламыйм да. Ачу белән тупны идәнгә бәрәм яки аяк белән тибеп очырам. Хәзер инде спорт залындагы башка иптәшләр дә миңа кычкыра:

— Аю, тилермә!

— Абрек, шашынма! — диләр.

Минем чыраем тагын да караңгылана төшә, уеным да усалрак төс ала. Ә Мөслимә, моны күреп, чаялана гына бара кебек. Ул миңа хаким булуын, үзенең өстенлеген аңлый булса кирәк, әйтерсең, ул нечкә генә бер кызчык түгел, ә нииндидер бер мәгърур хан кызы!

Шулай берничә атна вакыт үтеп китте. Мәктәптә чыгарыш имтиханнары якынлашып килә иде. Мин рәтләп хәзерләнә дә алмыйм. Көндез дә шул Мөслимә, күзгә күренмичә, һаман чебен кебек бәйләнә. Дәрес барганда да мин аның көлүен ишетәм кебек. Тәмам уйга бирелеп киттем, ябыктым да. Бер көнне яраткан укытучым дәрестән соң минем бер үземне калдырып:

— Малик, сиңа нәрсә булды, авырмый торгансыңдыр бит? — диде. Хөрмәтле укытучыма мин нәрсә әйтә ала идем? Кызарып, оялып, әллә нәрсә генә мыгырдандым шунда. Ә мәктәптән чыгып, урам буйлап өйгә кайтканда Мөслимәне очраттым. Ак алъяпкычтан, кулында кечкенә генә портфеле бар.

— Малик, син кайда югалдың? Нигә спорт залында бер дә күренмисең? Әллә Мөнирнең көлүеннән куркасыңмы? Ул шаярып кына ич, — диде.

Юк, Мөнирдән куркып түгел, шул Мөслимәне күрмәс өчен соңгы көннәрдә спорт залына бармый башлаган идем. Ничек шуның турысын әйтәсең? Кыз минем ык-мык килүемне аңлады, ахрысы, көлеп җибәрде:

— Шул буең белән миннәнме, җор Мөнирдәнме куркасың, Абрек?

Әллә нәрсә генә әйтәсем килде бу чәнечкеле шөпшәгә. Малай башым белән ниндидер бер кызчыктан куркам, имеш. Минем урам малайлары

белән сугышканым юкмы? Өч-дүрт кешегә каршы бер үзем артыма карамыйча барам, берсен уңга, берсен сулга салып егам. Бөтен тирә-якта алар үзләре миннән калтырап тора. Кайда булса караңгыда таш белән бәрсәләр генә... Монда шул чәнчә бармак белән чиертеп егарлык кыздан курык, имеш. Оятыннан әллә нишләрсең, я парктагы парашют вышкасы башыннан күзләреңне йомып сикерерсең, яки Кабан күленең иң тирән җиренә чумарсың. Шулай да мин... Мөслимәдән курка идем, яшертен рәвештә, бер кемгә дә сиздермичә курка идем. Бу минем мин-минлегемә дә тия, ачуымны да кабарта. Хәер, ул чакта мин үз-үземә җавап бирергә, үз уйларымны, үз хәрәкәтләремне тикшерергә күнекмәгән идем шул әле. Моны миңа берәү дә өйрәтмәде, үзем белмәгәнмен.

Хәзер мин Мөслимәнең минем кебек бер укучы икәнен, тик рус мәктәбендә укуын белә идем. Мәктәпне тәмамлагач, университетның физмат факультетына керергә хыяллануы да миңа сер түгел. Мин үзем дә физика-математиканы яратам, ләкин минем төзүче буласым килә. Яңа йортлар, яңа заводлар, яңа культура сарайлары салырга хыялланам. Эшеңнең нәтиҗәсе бик тиз күзгә күренә, әллә ни күтәргә дә кирәкми.

Мин кызарганнан кызара барам. Үзем шушындагы тәбәнәк чиркәү манарасына карыйм. Ә-ә-ә! Белеп алдым: Мөслимә минем буемны яратмый икән! Моңарчы аның миңа Абрек дип дәшкәне юк иде ич. Абрек — чиркәү... Димәк, ул миннән көлә. Тукта, алай булгач, мин сиңа Абрекнең кем икәнен күрсәтим әле. Минем зур кара күзләрем ялтырый, сулышым ешая. Ләкин шул чакта Мөслимә минем кулыма кагылып, бик йомшак тавыш белән (әллә миңа гына шулай тоелдымы икән?):

— Бүген кичкә спорт залына кил. Килми калма, бергә волейбол уйнарбыз,— диде дә, бик нәфис елмаеп, китеп барды.

Мин дә үз юлыма киттем. Артыма борылып карыйсым килсә дә, тыелдым. Мөслимә борылып карагандырмы, юктырмы,— белмим. Ул көнне мин кичне бик түземсезләнеп көттем, ләкин кич җиткәч... спорт залына кермәдем. Бакчага чыгып, куе агач башына мендем дә шуннан якты зал тәрәзәсенә карап тора башладым. Спорт костюмыннан гына булган Мөслимә (моңарчы киңәгән өр-яңа костюм иде ул) бу юлы миңа бик матур, бик күркәм булып күренде. Ә Мөнир аның янында ничек бөтерелә! Аулак ана, беркем дә комачауламый. Мин бар чакта теле белән генә батыр кылана иде, хәзер, күр, кулына да ирек бирә. Тукта, ерык авыз, кызларга ничек кагылырга кирәк икәнен мин сиңа күрсәтермен әле. Исемеңне дә онытырлык итәрмен.

Мөслимә сәгатенә карый-карый уйнады. Ашыга идеме, кемнедер көтә идеме (мине көтүен башыма да китермәдем). Әгәр берәр егет булса, анысы да бүген нык килгәненә үкенер. Мин шулай дип торганда Мөслимә сәгатенә тагын бер карап алды да залдан чыгып китте. Мөнир бер үзе алкаларда бөтерелде, аннары утны сүндерде. Димәк, кайталар! Миңа агач башыннан төшәр, бакча утын сүндерер өчен бер минут вакыт бик җиткән,— выключательнең кайда икәнен беләм ләбаса. Аннары урамга чыга торган бакча юлы буендагы куе куаклар арасына постым.

— Һай, бүген бакча нинди караңгы. Мөнир, син мине бераз озатасыңмы? — диде Мөслимә. Мөнир бик теләп риза булды. Ләкин кызны култыкларга тотынганда мин аны куаклар эченә сүзсез генә тартып алдым да борынына шундый кундырдым, нәрсәдер чырк итте. Мөнир шунда ук җиргә бөгелде.

Мөслимә, куркып:

— Мөнир...— дип кычкырды. Мөнир җавап бирмәде.

Мин, әзрәк артка кала төшеп, Мөслимә артыннан бардым. Ниятем бер: әгәр аны икенче бер егет каршы ала торган булса, анысының да әттәхиятен укыту. Ләкин, мин күпме көтсәм дә, Мөслимәне бер кем дә каршы алмады. Ул өенә кадәр, тирә-ягына карана-карана, ялгыз кайтты. Ишек алларына йөгерә-йөгерә керде. Курыкты, ахрысы.

Мин урамның икенче ягыннан, куләгәдән, карап тордым. Башта тәрәзәләрендә ут юк иде. Аннары ут кабынды, бүлмә эчендә Мөслимәнең ялгыз шәүләсе күренде. Бер минуттан ул зур тәрәзәне ачып җибәрде, урамга карап тора башлады. Мин әзрәк артка чиктем.

3

Минем юләрләнгән сыман йөрүләрем, тилерүләрем — зур мәхәббәтнең тууы, башы булгандыр, күрәсең. Ничек әйтәләр әле: ул минем җиремне, күгемне каплады диләрме? Мин Мөслимә турында көн-төн уйлый башладым. Ул бер генә минутка да хыялымнан чыкмый. Дәфтәр почмакларына да, китап битләре арасына да, ком өстенә дә аның исемен сызгалыйм, аннары, кеше танымаслык итеп бозам, ә үзем барысын да күрәм, имеш. Билгеле, минем уйларымның да, хыялларымның да атаанасы юк, алар йөгәнсезләр, буталчыклар. Мин бу көннәрдә ни сөйләгәнемне, ни кыланганымны анык кына белмим. Ләкин минем бөтен малайлыкларым, юләрлекләрем артында, уйнап, сикергәләп торган кояш нуры кебек, ниндидер яктылык куләткәсе бар иде шикелле.

— Ну, Абрек, сиңа борын туләргә туры килер, ахрысы, мин милициягә барып әйттем,— диде бер көнне Мөнир, көлеп.— Кара, бөтенләй кәкрәйткәнсең бит. Ә нинди матур, нинди кукрайган борын иде. Тукай язган борыннан бер дә ким түгел иде... Ике көн кеше күзенә күренми, өйдән чыкмый яттым,

— Шәп булган, тик тагын да берне өстисе калган. Аннары кеше кызлары тирәсендә артык иснәнмәс идең, чибәр егет,— дидем мин, коры гына.

— Әттәкәй генә! — диде Мөнир, каш сикертеп.— Белмидер идем, Мөслимә синең кызыңмыни? Соң, шулай булгач, алдан ук әйтеп куялар аны, яхшы дус.

— Менә әйттем ич.

— Әйе, борын хәзрәтләренә. Ул бичара озак хәтерләр, онытмас! — Мөнир мине иңбашымнан кочып алды.— Син кызлар мәсьәләсендә гел шулай сөйләшәсеңмени? Шәп!

Бер ун көннән соң Мөслимә белән дә татулаштык: тагын шул ук Мөнир ярдәмгә килде. Ул ничектер үтә җинел, үтә ваемсыз сөйләшә иде. Мин, аңа карап, хәтта бераз ышанмыйчарак та тордым.

— Менә күрәсеңме, Мөслимә, минем борын агайны? Элек ул барлык адәмнәрнеке төсле туры иде. Менә бу Абрек,— ул бармагы белән миңа төртеп күрсәтте,— кеше кызларына караган өчен аны шулай матурлап куйды. Хәзер чибәр кызлар күрсәм, борылмас җирдән читкә борылам. Ә син бу малай әллә кем булган дип уйлагансыңдыр инде?

Бу тупасрак шаяртуга Мөслимә бик каты ачуланыр дип уйлаган идем. Ә ул, зәңгәр күзләрен зур ачып, бер ваемсыз басып торган Мөниргә, бер кызарып, башын аска иеп торган мин фәкыйрьгә карап алды да кинәт тыелгысыз рәвештә көлә башлады.

— Әйе, син көләсең, сиңа кызык, ә минем бердәнбер күлмәгем харап булды, житмәсә, әнкәйдән дә эләкте,— диде Мөнир, хәтере калган булып. Үзе миңа күз кысып алды. Шунда мин аның чын дус икәнен тагын бер кат ышандым. Ул бакчадагы тилелегем өчен мине бер дә әрләмәде, кимсетмәде, әлбәттә, милициягә дә бармаган, гомумән бу турыда, Мөслимәдән башка, беркемгә дә сөйләмәгән. Ә хәзер бераз көлә төшеп такылдаулары үзенең егетлек дәрәҗәсен кызлар алдында бөтенләй ук төшермәс өчен кирәк булгандыр, ахры. Мөслимәгә ул үзенең мөнәсәбәтен соңыннан да әйтмәде. Бу турыда сүз чыкса, уен-көлкегә салышты. Һәрхәлдә, дуслыкка бер генә дә хыянәт итмәде ул. Монысын ачык әйтә алам.

Ул көнне без спорт залыннан иртәрәк чыктык. Чәчәк исе белән тулы бик җылы июнь киче иде. Безнең тыныч тормышта, исерткеч яшьлек гамьсезлегендә соңгы кичләребез булганлыгын кем белгән ул чакта? Һәрвакыттагы кебек, урамнарда трамвайлар күңелле шылтырап үтәләр, кешеләр көлешә-көлешә каядыр ашыгалар. Тимер рәшәткә буенда башлары тигез итеп кыркылган сәрви куаклары чәчәк атып утыра. Кызыл флаглар җилфердәп торган парк капкасы башындагы радио күңелле музыка уйный. Бөтен җирдә рәхәт талгынлык. Эштән әзрәк арып кайткан, хәзер капка төпләренә, ишек алларына, бакчаларга хәл җыярга чыгып утырган өлкән кешеләр моны тагын да тирәнрәк хис итә торганнардыр. Безнең ише бөтен дөньялары түгәрәк, ару-талуның нәрсә икәнен дә белмәгән, бөтен яшәү матурлыгын шул тиңдәшсез матурлык көенчә генә кабул иткән яшьләргә ни! Җитмәсә, беренче әйтелмәгән мәхәббәттән әзрәк исерә төшкән, хәтта чак кына юләрләнә дә төшкән уйсыгез-уйтугыз яшьлек егет-кызларга күктән йолдызлар чүпләп алырга мөмкиндер кебек тоела. Башкасын без уйлап та карамыйбыз. Элек мин әкиятләрдә яшь егетнең күкрәгендә йөгәнле чаптар бар дигәнне ишетсәм дә, аңламый торган идем. Хәзер беләм: коштай җитез атмы, башка бер нәрсәме, ләкин нәрсәдер бар егет йөрәгендә!

— Әйдәгез паркка! — дидем мин.

Мөнир борынын капшап карады.

— Барыгыз!— диде ул, көлеп.— Белеп булмый, я тагын берәр бәлагә тарырмын шунда.

— Я инде, Мөнир, әллә нәрсәләр сөйләмә,— диде Мөслимә, чак кына кызарып.— Без бераз гына йөрибез дә кайтабыз. Шулай бит, Малик?

Мин Мөнирнең көлеп торган коңгырт күзләрен күрдем. Алар монда өченче кеше артык дип әйтәләр иде шикелле. Дөрес сизенгән шул, шельма! Каян аңа шундый тәҗрибә килгәндер, белмим. Безнең яшьтә кыз алдында үзеңнең егетлегеңне аклар өчен генә дә әллә нәрсәләр эшләргә әзерсең бит.

Мин дә көлеп;

— Әнисеннән курка ул,— дидем.

— Дөрес, өстенә бастың, Абрек. Ярый, сез паркны әйләнә торыгыз, ара-тирә зәңгәр йолдызларга карап алыгыз, файдасы була аның. Ә мин өйгә кайтам. Ауфвидерзейн!

Мөнир, кулын болгап, китеп барды. Без, Мөслимә белән, урам аша чыгып, паркка юнәлдек. Парк юлында Мөслимәне бик култыклыйсым килгән иде дә, кая андый батырлыкка җөрьәт итәргә! Мөслимәгә болай чак кына орынып китсәм дә, тәнемнән электр тогы үткәндәй була. Мөслимә дә, бераз уңайсызланган шикелле, ялтырап торган зәңгәр күзләрен юри миннән еракка ракк яшерә. Башта, шул үзара уңайсызлануны басар өчен булса кирәк, җыен юк-бар нәрсә турында сөйләшеп, сәбәпсез-нисез көлеп бардык. Күбрәк икебезгә дә якын мәктәп тормышы турында сөйләштек. Аларда да, бездә дә кайнар көннәр — имтиханнар башлана. Мин, кыз алдында әзрәк мактанасым килеп, имтиханнардан бер дә курыкмыйм, дидем. Мөслимә аска карап, әкрен генә:

— Мин куркам,— диде.— Болай барысын да беләм шикелле, шулай да куркам. Кызлар гомумән куркак була торганнардыр инде, шулай бит, Малик?

Миңа калса, Мөслимә дөресен сөйләми, ул юри үзен көчсез итеп күрсәтә. Минем карашымча, Мөслимә — бер нәрсәдән дә курыкмый торган кыз. Бу инде минем аңа азмы-күпме табына башлавым булгандыр. Андый чакта бит син кешене җирдән аерасың, аны үзеңчә бер фәрештә, алла итәсең, ул сиңа кешеләргә хас барлык йомшаклыклардан буй җитмәс кадәр өстен тора кебек тоела. Мөслимә буе-сыны, кашы-күзе, киеме-салымы белән башкалардан бер дә аерылмаса да, миңа аның сары чәче дә, зәңгәр күзләре дә (бу вакытта зәңгәр күзләр турындагы

жыр бик модада, гүя аны Мөслимә турында чыгарганнар), озын муены да, нечкә билен буган киң путасы да, ак тапочкалары да, гомумән, барысы да, барысы да килешле, мондый камиллек, мондый килешле кием бүтән бер кызда да юк кебек тоела. Сөйгән күзгә бар да асыл күренә дип әйтәләрме? Шул инде бу. Мөслимә — һәр яфракчыгы килгән илаһи бер чәчәк.

Паркта кеше бик күп. Ләкин ямь-яшел куе агачлар арасында тын алулары кичектер жинел, кеше күплеге күзгә дә күренми. Аннары бераздан без кешеләрдән читкәрәк тә киттек, безнең табигать кочагында икәүдән икәү каласыбыз килә иде. Менә инде без биек нарат төбендә текә ярда, Казанка елгасына карап утырабыз. Аста Подлужная урамы, йортлар бер-ике катлы, күбесе агачтан, һәр җирдә бакчалар. Бакчалар артында — елга. Ул батып барган кояш яктысында ялт-йолт итеп тора.

— Малик,— ди Мөслимә уйчан гына һәм елга өстеннән йөзеп барган ак җилкәнле көймәгә карап ала,— теге көнне син чыннан да Мөниргә суктыңмы? Син шундый, Отелло шикелле, көнчеме? Әгәр ул сина үпкәләсә? Ул синең дустың ич! Минемчә, дуслыкның кадерен белергә кирәк.

Җавап бирүдән элек минем башымнан нинди генә уйлар үтмәде. Ләкин Мөслимә үзе үк минем барлык шикле уйларымны алып ташлый, юкка чыгара. Мин Мөслимәгә шикләремне бөтенләй әйтмәдем. Күлеп, күңелемдә аз гына да кер сакламыйча, бер нәрсә дә яшермичә:

— Мөнир миңа үпкәләми,— дидем.

— Ник, ул шундый яхшымы?

— Әһә.

— Нәрсә ул «әһә»? Ә ни өчен син аңа суктың? Тагын башка кешегә дә сугарсыңмы?

Әйе, мин Мөниргә генә түгел, әгәр Мөслимәгә кагыла калсалар, башкаларга да үземнең Абрек икәнемне күрсәтергә теге вакытта агач башында ант иткәнемне, Мөслимә артыннан аның өенә хәтле яшеренеп күзәтә барганымны уйлап алып, астыртын гына елмаеп куйдым. «Мин сине бирәүгә дә бирмим!» дип әйтәсем килде Мөслимәгә. Ләкин ничек әйтәсең?! Сугышырга булса, мин әзер, уйлап та тормыйм, мине бер нәрсә дә туктата алмаячак, әмма сер ачарга... Юк, монысы булмый.

— Тимәсеннәр! — дидем мин, үзсүзләнеп. «Нигә бишәү, унау түгел, барыбер мин аларга сине бирмим», дип әйтүем булгандыр инде. Шул томан эчендә дә Мөслимә мине аңлады, үтә йомшак көлеп, шул ук вакытта бераз горурланып та:

— Тиле син, Абрек син,— диде.

Мин эчтән бик тә, бик тә сөендем. Соң шулай булмыйча! Мине ярты сүздән аңлыйлар! Мин үз каршымда үзем үсеп киткәндәй булдым, әллә кая биеккә күтәрелдем шикелле.

Инде караңгы да төште. Мөслимә минем янымда гына утыра. Мин аның сулышын, тән җылысын тоям. Күкрәккә кысып, шашып-шашып үбәсе иде үзен, әллә нинди вәгъдәләр пышылдыйсы иде үзенә! Ләкин мин аңа кагылырга да кыймыйм. Без шулай ярым сәер телдә бик озак сөйләшәбез. Безгә инде кузгалырга да вакыт. Күптән инде ай калыкты, йолдызлар җемелди. Мин, егет кеше, беренче булып җәһәт кенә урынымнан торам.

— Ой, мин тора алмыйм, аякларым оеган,— диде Мөслимә, көлә-көлә.— Бир кулыңны.

Мин кулымны суздым. Мөслимә минем кулга тотынды да урыныннан сикереп торды. Ләкин шуннан соң ул кулымны ычкындырмады. Без култыклашып түгел, бер-беребезнең бармак очларыннан тоткан килеш кайттык. Бу вакытта паркта халык тагын да күбәйгән, җанлылык арткан, ләкин без үз сүзебез белән генә мәшгуль, бүтән бер тавышны да ишетмәдек. Мин кич буе каян гына сүз чыгарамдыр, төрле мәзәкләрне чәчәм генә. Өч тиен биреп сөйләтеп, биш тиен биреп туктатып булмый

торган юләргә әверелдем. Ә Мөслимә минем тузга язмаган сүзләремне чын ихластан кабул итә, эче катып көлә. Өенә кайтып җиткәнче көлде ул, капкадан да көлә-көлә кереп китте. Мин дә үземне асыл кош тоткан кебек хис иттем.

Утлары бар, тәрәзәләре ачык, Мөслимә дә тәрәзәдән күренер дип көттем. Дөрес, сүз куешмадык. Ләкин сөйгән күңел кайчан алдана? Мөслимә, ишектән керүенә, ачык тәрәзә янына килде дә, пәрдәне рәтләргә булгандыр инде, ләкин үзе сиздерми генә миңа кул болгап алды. Миңа тагын ни кирәк?

Эчке шатлыктан исерә торган шундый көннәр бик озак дәвам итсен дип теләгән идем мин. Ләкин булмады, озакламыйча Бөек Ватан сугышы башланды. Ул безнең, яшьләрнең, мөнәсәбәтләренә дә үзенең коточкыч кара күләгәсен төшерде. Сугышның беренче атнасында ук әти фронтка китте. Без бөтен семьябыз белән аны җыелу пунктына кадәр озата бардык. Шунда ул безне, без аны соңгы тапкыр күргәнбез. Ләкин ул чакта, аерылышу бик авыр булса да, әтине соңгы тапкыр күрүебезне, бер айдан соң ук аның Ватан өчен гомерен бирүе турында авыр хәбәр алачагыбызны кем башына китергән? Әнкәй сабыр гына елады, сеңелкәш тә елады, мин, малай кеше, андый йомшаклыкны күрсәтмәдем күрсәтүен, ләкин миңа да җиңел түгел иде. Миңа калса, тыныч чакта утның серен белгән, аны үз ихтыярына буйсындыра алган әткәй сугыш кырында да уттан курыкмас, аны үзенә баш идерер кебек тоелган иде. Бу турыда аның сугышчан иптәшләре безгә җибәргән хатларында да яздылар, әткәй беренче булып сугыш утына керә торган булган, көн-төн ут эчендә йөрегән, һич курыкмаган, ут һәм тимер аны читләтеп үткән, гүя аңа якын килергә батырчылык итмәгән, ә бер көнне...

Мин әткәй турында күп уйладым. Иптәшләре аның хакында: чын батыр иде, дип язганнар. Ничек була торгандыр инде ул? Әткәй бит гади бер истопник иде, бар белгәне кешеләргә җылы өләшү. Ул берәүгә дә, хәтта наян балаларга да кычкырмады, сукмады, кешене хаксызга рәнҗетүне иң зур хаксызлык дип саный иде. Әзрәк тамак чылатып алгач мактангаласа да, мин аны сугыш эшендә обозга гына ярый торгандыр дип уйлый идем. Аннары аның яше дә шактый олы иде бит. Шундый кешенең искитәрлек батырлык күрсәтүе... Әллә туган җирне яклаучы кеше туган җирдән җиңелмәс көч аламы? Әллә нәфрәт тойгысы кешене шулай үзгәртәме?

Мин әткәйне күз алдына китерәм. Ул чакта, җыелу пунктында, ул бик сабыр иде. Әле дә аның сүзләрен онытасым юк. ул, уйланып кына, бик төпле итеп әйтте:

— Мин кайчандыр армиядә хезмәт иткән кеше, бераз корал тота беләм. Аннары безнең рабочий кешегә кайда да эш — эш инде ул. Сугыш ул бик авыр эш. Минем өчен ут йотмагыз. Башлар исән булса, дошманны җиңгәч, илгә әйләнеп кайтырбыз. Шатлык белән күрешергә насыйп булсын. Син, анасы, балаларны яхшы кара, алар киләчәктә яшисе кешеләр. Азмасыннар, тузмасыннар. Сугыш авырлыкларыннан кайсыбер кешеләр җебеп төшә, ярамаган эшләр эшлиләр. Сугыш бит мәңге булмас. Җирдә эш-хезмәт кенә мәңгелек.

Ихтимал, күп яшәгән, күп күргән булсам, бу сүзләрнең мәгънәсен тирәнрәк аңлаган булыр идем. Шулай да мин әткәй сүзләрен онытмадым, тылда чакта да, соңыннан солдат булгач та шул турыда күп уйландым. Моның өчен күп вакыт кирәкми бит. Секундның бер өлеше дә синең бөтен эчке дөньяңны актарырга җитә кала.

Әткәйне озаткан көнне мин әле тыныч тормыштан аерылып җитмәгән идем. Бер вакыт халык арасында Мөслимәнең кемнедер култыклап җыелу пунктына килүен күргәч, бер секунд эчендә кара тиргә баттым. Күз ачып йомганчы юан бер агач артына постым да Мөслимәләрне күзәтә башладым. Мөслимә елаган, ахрысы, күзләре кызарган. Хәзер

бераз келгән була, ләкин баш өстендә кайдадыр кайгы йөзә кебек. Мөслимә утызлар тирәсендәге бер ирне култыклаган. Шул ук кешенең икенче кулына чәче агара башлаган олы яшьләрдәге бер хатынябышкан. Ул әледән-әле кулъяулыгы белән күз яшен сөртә. Бу — кияүенең анасы булса кирәк. Бер үнлап кеше аларны озатып килә, арада өч-дүрт ир дә бар. Башка төркемнәрдә гармун уйныйлар, ара-тирә җырлаштыргалыйлар да, исерекләр дә күренгәли. Ә боларның берсе дә исерек түгел. Ләкин минем эчтә мәчеләр тырмаша башлаган иде. Башка чак булса, берни белән дә исәпләшмичә, хәтта моның яхшымы-түгелме икәнен уйлап та карамастан, Мөслимәне ул егеттән тартып алган, аңлатуын сораган булыр идем. Бу олы кайгы көнендә ничектер тыелып калдым. Аннары китүчеләргә ишек алдына керергә куштылар. Мин әткәй янына йөгердем.

Клуб капкасы төбендә халык галәмәт күп. Әткәй, безнең белән саубуллашып, көч-хәл белән генә эчкә кереп китте. Без капка төбендә калдык. Мин тирә-ягыма каранып алдым. Мөслимәләр беркайда да күренмәде. Хәер, бу кадәр халык диңгезе эчендә берәүне дә тиз генә абайлый алмассың.

Сеңелем әкрен генә елап торган әнкәйне култыклаган. Мин аларны капка төбеннән бераз читкәрәк алып киттем. Олы кеше булып, бик сабыр гына:

— Хәзер кайтсагыз да ярый, әткәйне барыбер артык күрә алмыйсыз. Аларны инде яңадан монда чыгармыйлар, безне анда кертмиләр,— дидем.

— Бераз торыйк әле, улым,— диде әнкәй, нәрсәдер өмет итеп. Мин бәхәсләшмәдем, алайса шунда торып торыгыз, мин койма башына менеп карыйм, әткәй күренмәсме, дидем.

— Һай, улым, койма башына менәргә ярамый торгандыр, күрсәләр — әрләрләр үзеңне,— диде әнкәй.

Мин аны кочтым да, борчылма дип, койма буена киттем. Үзем Мөслимә күренмәсме дип як-ягыма каранам. Юк, күренми. Халык бик күп шул, бар да әсәрләнгән, нәрсәдер кычкырып-кычкырып сөйлиләр. Яшьләр койма башына менәргә маташалар, ләкин булдыра алмыйлар, койма биек, каерылган такталар юк, әйтерсең, юри шулай нык итеп ясаганнар. Ә койма ярыгыннан карап нәрсә күрә аласың. Мин, җайлы урын эзләп, койманың буеннан буена үттем. Бер урында бер егет ниндидер могҗиза белән койма башына менгән иде. Мин аңардан:

— Күренәме? — дип сорадым.

— Юк, алар әнә анда булса кирәк. Моннан берән-сәрән кешеләр генә үтеп китә,— диде ул.

Мин ул күрсәткән тирәгәрәк бардым, ләкин йөреп-йөреп тә бер нәрсә чыгара алмагач, үзем кебек бер таза егет белән сөйләшеп:

— Әйдә минем җилкәгә бас та коймага үрмәлә, аннары — мин,— дидем.

— Давай,— диде егет.

Күз ачып йомганчы ул минем җилкәгә басты, аннары ялт итеп койма башына үрмәләде. Егетнең эзләгән кешесе койма тирәсендә йөрергә икән. Бик тиз сөйләшеп алдылар. Шуннан соң ул койма башыннан сикереп төште дә:

— Давай тизрәк, ату мин ашыгам,— диде.

Миңа егетнең җилкәсенә басарга, аннары койма башына атланырга күп вакыт кирәкмәде. Клуб ишек алдында халык бихисап. Байтак караштыргач кына әткәйне күрдем. Сөйләшеп алдык. Ул арада әнкәйләр дә минем янга килделәр. Әткәй белән әнкәй койманың ике ягында булсалар да, минем аша, бик әйбәт сөйләштеләр. Сеңелкәш тә үз сүзләрен кыстыргалады. Шул ук вакытта мин, ихтыярсыз рәвештә, бая Мөслимә озаткан кешене халык арасыннан эзләдем. Карый торгач, ул минем

күземә чалынды. Әллә инде йөзенә яктылык башкача төшкәнгәме, әллә үземнең күзләрем кинрәк ачылгангамы, бу кешене таныдым: бу — совет-партия мәктәбе укытучысы, Мөслимәнең жизнәсе Ләбаса! Аның чәче куе, сары бөдрә чәч иде. Киемен алмаштырып, чәчен алдырганга гына бая танымаганмын!

Мин койма башыннан төшкәч, әнкәй:

— Кайтыйк, улым,— диде,— бәлки кичрәк тагын бер кагылырсың, әтиенә кайнар аш китерерсең.

— Ярый, әнкәй, сез кайта торыгыз, мин хәзер сезне куып җитәм,— дидем, үзем Мөслимәне эзләргә йөгердем.

Алар капканың икенче ягында басып торалар иде. Мөслимә ак чәчле карчыкны култыклаган, башка озатучылары яннарында күренми, кайтып киткәннәр булса кирәк.

— Жизнәгезне күрдем,— дидем мин Мөслимәгә.

— Кайда? — дип тиз генә сорады карчык.

— Ул ишек алдында, мин койма башына менгән идем.

Карчык ишек алдында ниләр барын, анда нишләүләрен төпченеп-төпченеп сорашты. Әйтерсең, ишек алды әллә кайда, ә мин шуннан кайтканмын. Аннары Мөслимә, миңа күз кысып:

— Ә син монда нишләп йөрисең, Малик? — дип сорады. Мин аның мине бая ук күрүен, пошынуын, ләкин боларны карчыкка сиздерергә теләмәвен аңладым.

— Әткәйне озата килгән идек,— дидем мин, башымны түбән иеп.

— Әтиегезне алдылармыни? — диде карчык.— Аерылуы бик авыр булгандыр инде аңа. Безнең киленнең менә киявен озата да алмады, роддомда ята. Бәбине әтисенә тәрәзәдән генә күрсәткәннәр. Нишлисең бит, ходай бәндәләренә сабырлык бирсен инде.

Мөслимә миңа күзләрен тутырып карап торды. Күзләре яшь белән мөлдерәмә тулы. Ләкин ул, үзенең ут йотканын сиздермәс өчен, миннән артык сорашмады. Ә карчык:

— Ә син, улым, безнең Мөслимә белән укыйсыңмыни? — дип сорагач, Мөслимә тагын миңа күз кысып алды.

— Әйе, апа, бергә укыйбыз,— дидем.

— Муены астына килгере Гитлер явызның, никадәр сабый яшьләрне сөекле әтиләреннән аера, никадәр газиз балаларны бичара аналарыннан тартып ала. Дөнья-ахирәттә, ходаем, игелек бирмә шул бәдбәхеткә! — диде карчык, яшькә тыгылып.

## 4

Менә мин үзем дә фронтта инде. Әллә ничек кенә булды бу, өйрәнергә, күнегергә вакыт та юк иде, моның кирәген дә артык сизмәдек, гүя мин пилотка, шинель киеп туганмын, армия теле, командирлар теле минем үз ана телем шикелле. Сапер-минер эшенә дә бик тиз күнектем — без минерлар идек. Ихтимал, чынлыкта бераз башкачарак та булгандыр, тик мин генә сизмәгәнмендер. Яшьлекнең шундый бер ягы бар икән: син чын тормышны башка бер яктылыкта күрәсең, барысына да хисап бирмисең, чын сугыш тормышында үзеңне кайчандыр үткәрелгән комсомол осоавиахим уеннарындагы кебек тоясың. Хәлбуки мин инде ике-өч атна буена Мәскәү янындагы сугышларда көн-төн катнашам. Вакыт исәбен дә югалттык, кайчан ашаганбыздыр, кайчан ял иткәнбездер — белмим, һаман атыш, һаман ура кычкырабыз, алга барабыз, чигенәбез, урман яна, агачлар чәрдәкләнә, тупләре белән суырылып җиргә ава, һавага туфрак, балчык актарылып оча.

Бигрәк тә шәһәрләрне, авылларны калдырырга туры килгәндә авыр. Шәһәрләр, авыллар күз алдында яна, ишелә, гитлерчыларның танк

тараннары, гүя үткен хәнҗәр кебек, безнең оборонаны вак-вак кисәкләргә турыйлар. Без үзебез чигенә торган барлык юлларга миналар куябыз. Кайчак анда танклар, автомашиналар шартлый, кайчак алар әллә кайдан гына әйләнеп үтәләр. Сугыш көннән көн кыза, катырак төс ала.

Газета укырга вакыт юк. Ләкин 12 нче, 13 нче октябрьда «Правда»ның баш мәкаләләре турыдан туры безгә, сугышчыларга, мөрәҗәгать ителгән булган. Политруклар, агитаторлар, вакыт табып, аларны укыдылар. Бездән изге антыбызны ахыргача үтәү сорала. Кычкырып әйтү юк, ә эчемнән изге антымны үтәрмен, дип кабатлыйм. Бер генә көнгә, бер генә сәгатькә булса да дошманны баскан җиребездә тоткарлап торсак та илгә файда икән.

Октябрь урталарында Калинин фронты төзелде. Бу безнең Көнбатыш фронтның хәлен беркадәр җиңеләйтте, төп көчләребезне ин куркыныч урыннарга — Волоколамск, Можайск, Малоярославец һәм Калуга юнәлешләрендә тупларга мөмкинлек алдык. Күп тә үтмәде, монда искиткеч каты сугышлар башланып китте.

16 нчы армия Волоколамск юнәлешен саклый иде. Фашистлар безне килү уңаена гына сытып китәргә тырышсалар да, уңышка ирешә алмадылар. Җиде көн эчендә безнең частьлар дошманның сиксәнгә якын танкысын, бик күп пехотасын юк итте. Бары тик дошман бик зур өстәмә көчләр китереп сугышка керткәч кенә Волоколамсктан чигендек. Анныры тагын, караңгыда, гамьсез йолдызларга карап ала-ала, алгы кырыйга миналар куйдык, траншеялар казыдык. Тамак бик кипкән иде, старшина китергән ашны ашамыйча, башта су сорадык. Нинди тәмле икән салкын су! Ул чакта салкын су түгел, гүя котелок кырыеннан тамчылар тамыза-тамыза зәмзәм эчеп сусауны бастык!

Шуннан соңгы көннәрдә сугыш киеренкелеге кимемәде, киресенчә, бермә-бер артты гына, ләкин без үзебез үзгәрдек. Сугышка күнектек дип әйтә алмыйм, сугышка, мөгаен, күнегеп булмый торгандыр, әле генә бергә атакага барган, дошманны пыран-заран китерешеп йөргән турылыклы иптәшең, сугышчан дусларың инде җансыз килеш җирне кочып ята, әнә сызгырып килә торган мина тагын кемнедер мәңгегә алып китәргә тиеш. Яки алгы кырыйда без куйган миналарда дошман танклары, дошман солдатлары шартлый яки күкләргә һавага оча,— без үзебезнең эшне күреп эчтән канәгатьләнәбез, ләкин шул ук вакытта безгә куркыныч та. Миңер эшенең шундый дәһшәтле икәнен кем уйлаган. Еш кына әтинең зур мичендә дөрләгән ялкын күз алдыма килеп баса. Әнә ул ирекә чыккач ничек котыра икән.

Мин ниндидер күләмдә үземне сугыш утыннан өстен куярга өйрәнә башладым. Хәтта кайчак үз алдыма елмаям: политрук та, командир да мине мактап телгә алалар, карагыз, безнең сугышчылар ничек тиз үсә, әле кайчан гына Газыймов «яшел» солдат иде, инде бер нәрсәдән дә курыкмый торган сугышчыга әверелде, диләр. Бигрәк тә яна килгән солдатларга мине үрнәк итәләр. Мин үзем моңа бик үк ышанмаган да булыр идем, ләкин күп тә үтмәде, мине, Панкратовны, Мөнирне һәм тагын берничә кешене аерым сапер батальонының разведкасына күчерделәр. Разведка инде ул, нинди частьта гына булмасын, бөтенләй башка эш, анда тикмәгә генә алмыйлар, бигрәк тә сугышлар барышында.

Вакыт-вакыт, каты сугышлардан соң, берничә йөз метрга яки берникe километрга артка чигенәбез, дошман бик көчле басым ясый. Ләкин никадәр авыр, никадәр кан коешлы булса да, шуннан артык чигенергә безнең хакыбыз юк: безнең артта — Мәскәү! Дошман аны үзенен ике колагын күрә алмаган кебек күрмәскә тиеш. Бу — безнең, совет сугышчыларының, ил алдындагы изге антыбыз. Мәскәү безнең һәрберебезнең күңеленә җуелмаслык итеп язып, уеп куелган. Әгәр бер көн, бик каты сугыштан соң, бераз чигенсәк, икенче көнне, яисә төнлә үк дошман тап-

таган жирне кайтарып алу өчен тешебез-тырнагыбыз белән тырышабыз, мөмкин булмастайны да эшлибез. Бер үк урыннар кулдан-кулга дүртәр-бишәр тапкыр, хәтта артыграк та күчәләр. Кечкенә бер үр, жимерелеп яндырылып беткән авыл ул көннәрдә гүя дөньяның кендеге, аны алу бөтен нәрсәне хәл итә кебек тоела иде.

Әле сугышка беренче кергән көннәрдә үк мин шул исәпсез контр-атакаларның берсендә табан ялтыратучы фрицны үз күзем белән күрдем. Дошман кача! Жиңелүне белмәгән, гел алга ыргылучы тәкәббер фашист кача! Ул танклар артында гына батыр икән, танклардан аерылгач... Бәлки бу минем качып баручы гитлерчыны беренче күрүем булганга шулай истә калгандыр.

— Алаймы, табан ялтыратмакчы буласыңмы? Юк, ялтыратмый тор, башта минә таптап йөргән туфракны яхшы гына үбеп гафу үтен! — дидем һәм аягүрә килеш атып жибәрдем. Фриц кинәт туктады, кулындагы автоматы төшеп китте, аннары киерелгән шикелле бер итте дә жиргә йөз түбән капланды. Ә мин үземдә канатлар тоеп алга йөгердем.

Сугышлар кызганнан кыза, рәхимсезләнгәннән рәхимсезләнә барды. Разведчикларга төнлә дә тынгылык юк. Хәер, безгә генә түгел, безнең подразделениеләр дә төнге атакаларга торган саен кыюрак рәвештә күчә башладылар. Күп вакытта гитлерчылар ул ярсулы төнге атакаларга чыдый алмыйлар. Көндез әле алар киләләр, каты сугышалар, артиллерияләре, танклары бик күп, вакыт-вакыт безнең хәлебез чамасыз авырлаша, кыл өстендә калгандай булабыз, ә төнлә без өстенлек итәбез. Мәскәү янында без күп нәрсәгә өйрәндек, бигрәк тә сугышырга. Танклардан курыкмый башладык.

Октябрь бәйрәме якынлашуга, сугыш ярсуы тагын да арта төште. Дошман суык кыш башланганчы Мәскәүне алырга алга ыргыла, югалтулар белән һич санашмый. Аның каравы без дә бик нык үчләндек. Юләрләнеп йөргән малайларны хәзер бер кем дә танымас. Киләчәк буыннар да аларга бу кадәр ныклык каян килгән дип гажәпләнер. Ирен почмакларына тирән сызыклар ятты, күз карашларыбыз кырысланды, бер секунд эчендә атакага күтәреләбез, дошман белән актык тамчы каныбызга кадәр якалашабыз.

Бүген безгә «тел» алырга куштылар. Бурыч куйганда: дошманның оборонасын ачыкларга кирәк, диделәр. Бу участокта без инде берничә көн торабыз, башта гитлерчылар бик каты атака ясап карадылар, чигендерә алмагач, оборонага күчтеләр, хәзер траншеялар казыйлар. Кем бу турыда тулы мәгълүмат бирә ала? Әлбәттә, немецларның саперы. Без инде аларның кая урнашканлыкларын да беләидек.

Дүртәү барырга булдык: мин, Панкратов, Мөнир һәм тагын бер иптәш. Сиздерми генә дошман тылына үтеп, саперлар урнашкан өйләр каршына — чокырга яттык. Алда, минем янымда, Панкратов. Егерме-утыз адымда немец часовое йөренә, ун адымнар читкә китә дә, борылып, елга буена карый. Анда, бер урында, куаклар бар, гитлерчыны шул борчый, ахрысы. Ләкин ай яктысында куаклар гына түгел, уймакланып киткән елга өсте дә ап-ачык күренә. Без исә айны каһәрлибез. Ай — гашыйкларның юлдашы, диләр. Мөслимә белән ай яктысында йөремәдек, белмим. Мөмкин булса, бүген ул айны мушкага гына утыртыр идем. Штабта, төн караңгы булыр, хәтта бераз яңгыр да явар, дигәннәр иде, ә монда син теләгәннең нәкъ киресе. Болай булгач, кире дә кайта алмассың әле, елга буена төшеп житкәнче үк гитлерчы, күреп алып, автоматыннан тырылдатып кисеп салыр. Юк, алай булганчы башта гитлерчының үзен бетерәбез, аннары ни булса, шул булыр. Мин автоматымны жайлый башлаган идем, Панкратов, минем ниятне сизеп алып булса кирәк, кулын автоматым өстенә куйды: юләрләнмә, янәсе!

Миңа үз хәлемнең өметсез булуыннан бигрәк, явыз дошманның туган туфрагыбызны бер дә тартынмыйча таптавы авыр иде. Әнә нинди

тәкәббер басып йөри бит ул килмешәк, әйтерсең, монда мәңгегә килгән, бер нәрсәдән дә курыкмый, имеш. Менә бер төчкертсәм, кан җылап, ник килгәненә үкенерсең әле. Шулай да Панкратовның кисәтүе минем ярсуымны баса төште: анда «тел» алып кайтканны түземсезлек белән көтәләр. «Без сезгә ышанабыз», дигән иде штаб начальнигы. Мин тешемне кысып түзәм.

Гитлерчы һаман йөренә. «Ярый, кабахәт, иртә белән яки берничә көннән эшең барыбер бетәр, гадел пуләдан кача алмассың!» — дим эчемнән.

Менә постларын алмаштырып йөриләр. Сәгатемә карый алмадым, ләкин бу вакытта төнге өчләр-дүртләр булгандыр. Аннары күктә каяндыр болытлар чыкты. Менә монысы ярый, монысы безнең өчен уңай.

Бу сакчы сул аягына бераз аксый төшә, күрәсең, яраланган булган. Әнә яндырылып бетә язган авылга ничек өстән карый. Кара, кара, кабахәт, хисап бирер көнең алда. И-и, баскан урынында йокымсырый лабаса! Менә куркып уянды, башын күтәреп, тирә-ягына карана. Ул-бу булмагач, тагын йөренә, бераздан тагын йокымсырый башлады, ахрысы, баскан җирендә чайкала.

Панкратов белән күзгә күз карашып алабыз. Вакыт! Ай да болыт астына яшеренгән, фриц та безгә арты белән баскан. Бик яхшы, ләкин йөрәк котырып тибә, аның тавышын фриц ишетер кебек.

Шуышабыз, аннары мин сикереп торам, икенче секундта немецның авызын учым белән каплап, аяктан егам. Панкратов автоматын тартып ала. Фриц тыпырчына, кычкырмакчы, кулымны тешләмәкче була, ләкин бугазына хәнҗәр терәгәч, эшнең нәрсәдә икәнен сизеп, тынып кала. Без аның авызына чүпрәк тыгабыз, кулларын артка бәйлибез. Болар бар да яшен тизлеге белән эшләнә, аннары, немецның коралын эләктереп, күздән югалабыз. Хәзер, безне каплап, арттан Мөнирләр бара. Ул-бу булса, алар дошманны тоткарларга тиеш.

Инеш буена җитәрәк, бераз тыңлап тордык,— куаклар янында дошман яшеренгән булуы мөмкин. Дөрес, бая анда бер кем дә юк иде, ләкин аннан соң ничә сәгать үтте. Арырак автоматтан аталар, ракета чөяләр, ләкин бу гадәттәге сугыш төне. Без сак кына инешне кичәбез, көймәфәләп кирәкми, иң тирән җире — тездән. Үзебезнең якка чыккач, эчкә җылы йөгерә.

Дошман ягында да тынлык, димәк, ни булганын алар әле белмиләр. Траншеяларыбызга ашыгабыз. Әнә ай болытлар астыннан чыгып килә. Айны оныткан идек, тизрәк яшеренергә кирәк.

Әсирнең тыны капты булса кирәк, ике тапкыр егылды. Күп уйлап торырга вакыт юк, ике яктан эләктерәбез дә йөгерәбез. Бераздан траншеяга сикердек. Анда разведка лейтенанты белән штаб начальнигы. Мин аңа заданиенең үтәлүе турында рапорт бирәм, ул арада Мөнирләр дә килеп җитә. Шул чакта дошман ягында, әле күптән түгел генә без булган урында, атыш куба, күрәсең, часовойның юкка чыгуын сизделәр. Ярый, хәзер атыгыз, эзләгез!

Штаб начальнигы андагы хәлләр турында әзрәк сораштыра да, лейтенантка фрицны алып китәргә куша. Тегенең коты очкан, калтырана. Аңа каравы да җирәнгеч.

Без үз өйләребезгә кайтабыз, сәкегә сузылып ятабыз. Бик арылган, күзне йому белән йоклап та китәрбез кебек, ләкин нервылар әле тынычланмаган. Ничектер күз алдында үзеннән-үзе Мөслимә калка. Мин аның турында рәхәтләнеп уйлый башлыйм. Шундый авыр көннәрдә Мөслимәнең дөньяда булуы минем өчен нинди бәхет, моннан, ут эченнән, аңа карап торулары нинди сөенеч. Әгәр ул булмаса, мин үземне дөньяда рухи бик фәкыйрь итеп сизәр идем. Ш кына ул минем хыялымда Ватан образы белән тоташа, мин, туган ил белән сөйләшкән кебек, Мөслимә белән күңелемнән сөйләшәм, дошманны аяусыз кырырга аның

алдында ант итәм, аның исеме белән сугышка керәм, аның исеме белән сугыштан чыгам. Әгәр бәрелешебез уңышлы булса, Мөслимәнең зәңгәр күзләренә карап елмаям, әгәр уңышсыз булса — сугышта андый хәлләр дә еш була — Мөслимәнең күнелдәге сурәтенә карамаска тырышам. Ләкин икенче бәрелештә ачулырак, аяусызрак сугышам, явыз дошманга бер дә шәфкать күрсәтмим. Мактанып әйтмим, ләкин алар мине һәрхәлдә хәтерләргә тиешләр, «тел» алырга кирәк булмаса, мин аларның берсен дә кызганып тормыйм, әле әткәй өчен дим, әле туганнар, әле сугышчан дуслар өчен дим. Үзәм дә салам, изге нәфрәт!

Мин йоклап киткәнмен һәм шунда ук төш күрә дә башлаганмын. Барысы да ачык, барысы да нәкъ өндәге шикелле. Имеш, мин Казанда әле. Бүгенме, иртәгәме фронтка китәм, шатланган да, борчылган да чак. Йөгереп барып, Мөслимәнең тәрәзәсе каршына басам. Мөслимә шуны гына көтеп торган диярсең, тәрәзәне каерып ача. Мин аңа урамга чык, әйтәсе сүзем бар, дип кулым белән ишарә ясыйм. Мөслимә шунда ук урамга чыга, мин аңа каршы йөгереп барам, имеш, һәм сулыш та алмыйча:

— Мөслимә, мин армиягә китәм! — дим.

Ул сискәнә, күзләрен зур ачып миңа карый. Мин гүя барысын да тизрәк әйтеп калырга ашыгам.

— Син курыкма, Мөнир дә минем белән. Безгә берни дә булмас, ә фашистларның кирәкләрен бирербез, чын менә.

— Зинһар, юкны сөйләмә, Малик. Сугыш бит... Әнә нихәтле яралылар безнең шәһәр госпитальләренә килә. Аларга карасам, йөрәгем өзелгәндәй була, мин аларны бик кызганам,— ди Мөслимә.

Мин үземнекен уйлыйм: Мөслимә минем сүзләремә ышанмый, боларны мин юри шапырынып өчен генә сөйлим, дип исәпли, ахрысы. Ни әйтергә, ничек ышандырырга?

— Юк, мин чыннан да китәм, синең белән... саубуллашырга килдем,— дим әкрен генә.

Ниһаять, ул аңлады, ахрысы.

— Кайчан? — дип сорады калтыранган тавыш белән.

Шунда Мөслимә мине беренче мәртәбә култыклап ала, без якындагы бакчага барып утырабыз. Казанда урам утлары яна әле, якты, халык байтак. Мөслимә күз яшьләрен сөртеп ала.

— Кирәкми, Мөслимә, жылама,— дим мин.— Дошман кан-яшь түксен.

Мөслимә яшьле күзләрен тутырып миңа карый, гүя явыз дошманны җиңәргә миннән вәгъдә ала. Мин ул зур, изге вәгъдәне бирәм. Ә бит монарчы мин зур сүзләрнең, изге вәгъдәләрнең нәрсә икәнен яхшы гына белми идем, гомумән сүзне үлчәп, мәгънәсен тикшереп сөйләми идем. Бу тын бакчада, күләгә эчендә Мөслимә белән утырганда, мин нинди зур, монарчы һич тә билгеле булмаган нәрсәләрне төшенә башладым шикелле. Дөресрәге, мин боларны сизә, тоя башлаганмындыр, чөнки боларны төшенер өчен сугыш утларына керергә кирәк булган.

Бу кичтә мин Мөслимәнең миңа тирәнтен ышануын, миннән бөртек тә курыкмавын, шикләнмәвен аңладым — бусы инде төштә түгел, өндә иде. Мин әле аның кулына кагылырга да куркам, аның кулы миңа тотарга ярамый торган ниндидер утә пакь бер нәрсә кебек тоела. Ихтимал, тыштан бераз тупасрак күренгән шундый дәү егетнең шундый нечкәлеге бераз көлкедер, кызны аю кебек кочып алмаса, егет егетмени ул, дип уйлый торганнардыр кайберәүләр. Мин аларга жирәнеп карыйм, алар чын сөюне белмиләр булса кирәк, ә Мөслимә — минем өчен изге бер фәрештә.

Ул кичне без Мөслимә белән озак утырдык, күп нәрсә турында сөйләшкәнбездер, яшьлек хыяллары да калмагандыр. Ул чакта мин үземнең иртәгә сугышка китәсемне тәмам онытгым, бөтен нәрсә миңа әүвәл-

гечә алсу тәстә күренә иде. Ә иң рәхәте — Мөслимә минем янымда утыра, йомшак кулларын минем кулларыма куйган — үзе куйган, тартып алмый, ә мин ул кулларны катырак кысарга да батырчылык итмим, бары тик аларның җылысына гына исерәм...

## 5

Минерлар тормышында бу көндәлек вакыйга иде: без дошман тылына үтеп кереп, гитлерчыларның ягулык складларын шартлаттык. Кара төндә күккә бик зур ялкын ургылды, тирә-як ял-якты булып китте. Шул чакта безгә дошман пулеметы атты. Күреп аттылармы, әллә куркудан гына идеме — озакламыйча ату тынды, ләкин безнең командирыбыз яраланган иде. Мин аның ыңгырашып җиргә авуын күреп, тиз генә аның янына килдем. Лейтенант гырылдый иде. Мин плащ-палаткамны салдым, яныма килеп җиткән минерларга:

— Тотыгыз дүрт читеннән! — дип кычкырдым. Лейтенантны плащ-палаткага салып күтәрдек тә якындагы куаклыкка йөгердек. Шунда мин командирның ярасын бәйләдем. Аның күкрәге яраланган иде. Үз ягыбызга кайтып җиткәнче түзәрме-юкмы? Нәрсәдер әйтә, ләкин сүзен аңлап булмый. Хәзер мин өлкән командир булып калдым, иптәшләр миңа карый. Безгә урман буйлап бер ун чакрым юл үтәргә кирәк. Күккә үрелгән ялкынны башка гитлерчылар да, һичшиксез, күрәләрдер. Бөтен юлларга аларның эзәрлекләү группалары чыгар, безгә бер минутны да югалтырга ярамый.

— Панкратов, алга! — дим. Дүрт минер плащ-палатканың дүрт почмагыннан тотып, аның артыннан юнәләбез. Минем белән янәшә Мөнир атлый, урман эче булса да ерактагы ялкын яктысында мин аның йөзен күрәм: Мөнирнең күзләре ялтырый, үзе тирә-ягына карана. Юлдан бармыйбыз, алдагы кешене күздән югалту бик җиңел. Аннары, яралыны күтәреп, дүрт кеше теләсә кайдан үтә дә алмый. Минем бөтен ышаныч Панкратовта, бу җирләрне ул беләм дигән иде. Хәзер сугышлар Мәскәүдән урыны-урыны белән сиксән-йөз километрда гына бара. Мәскәүлеләр өчен бу урыннар — дача җирләре инде.

Хәлдән таеп беттек, яралыны күтәреп баручы иптәшләр әледән-әле алмашынып торды, мин генә алмашынмадым. Урмандагы һәр тавышка колак салабыз, ул-бу булса, коралга тотынырга әзербез. Ярый әле, эзәрлекләмиләр, күрәсең, башка юнәлешкә киттеләр. Ә лейтенант тәмам тынды. Үлдеме әллә? Без аны барыбер калдырмыйбыз. Яхшы, батыр кеше иде. Мин, күзләремне зур ачып, алга карыйм, күктә һаман янгын шәүләсе. Ансы күңелне сөендерә, ялкын гүя безнең үч тойгысы булып бии.

Ниһаять, үз батальоныбызга исән-сау кайтып җиттек. Лейтенантны санитарларга тапшырдык. Мин, штабка кереп, заданиенең уңышлы үтәлүен әйттем.

Шуннан соң без берничә көн бер кая да бармадык. Яраланган лейтенант урынына икенче командир килде. Ул үзебезнең батальоннан ук иде, утыз биш яшьләр булыр, аз сүзле, аксыл чәчле, кешеләргә ничектер бераз өстәнрәк карый сыман. Бу миңа бик үк ошамады, ләкин сугышта кешене заданиегә бармыйча белеп булмый.

Тын минутларның берсе иде. Алгы кырыйда траншеяда утырабыз. Мөнирнең сырмасын иңбашыннан «тешләп» алганнар, мамыклары чыгып тора. Мин кулым белән капшап карыйм.

— Син нәрсә, Абрек,— ди Мөнир көлеп,— шөрепләрең бушый башладымы әллә? Бу мин үзем булам,— капша, капшама.

— Башыңа эләксә, ә? — дим.

— Үлгәнче шайтаным да булмый, чөнки корыч каскам бар!

Мөнир миннән яшь ярымнар чамасы олырак, әмма бу аерма хәзер бер дә калмаган кебек, иптәшләр хәтта мине үземне олырак дип әйтәләр. Мөнир, уң күзен кысып, күрденме, абый кеше, дип куя.

— Син, өлкән сержант, Мөнирне түгел, әнә фрицны,— Панкратов башы белән дошман ягына изәп ала,— чеметеп кара. Безнең шөрепләр нык, ә менә фрицныкы ничегрәк икән? — Панкратов аягүрә басып дошман ягына карый.— Баядан бирле бер хәчтрүшенең башы траншеяларыннан һаман-һаман калкып күренә. Ниндидер кызык нәрсә бар, ахрысы.

Автоматтан алай еракка тидереп булмый. Мин траншея төбендә утырган бер солдатның винтовкасын алам да, ашыкмыйча гына төзәп, шул килмешәккә атып җибәрәм. Моны гүя игътибарсыз гына эшлим. Фриц башы шунда ук күздән югала, яңадан күтәрелми, күрәсең, эше вәссәлам.

— Менә бу яраган! — ди Панкратов, минем иңбашыма кулын куеп.

Икенче көнне коеп яуган янгыр астында төне буе дошман тылын айкап йөредек. Бу юлы безнең задание махсус: барысын да карарга, күрергә. Н. авылында бер укытучы бар, шуның белән сөйләшми кайтмаска куштылар.

Н. авылы фронт сызыгыннан унбиш-егерме километрларда. Авиаразведка һәм партизаннарның хәбәрләренә караганда, дошман фронтка яңа өстәмә көчләр китерә икән. Безгә үз участогыбызда менә шуны ачыкларга кирәк. Эшнең артык ашыгыч булуы — безгә бүген үк кайтырга кушылган иде — командованиенең аңа никадәр әһәмият бирүен күрсәтә. Үзебезне мөмкин кадәр сиздермәскә, бәрелешләргә катнашмаска кирәген кисәтеп әйттеләр.

Бу юлы яңа лейтенант та бар. Ләкин бездән башка аны беркем дә белми, барыбыз да сырма, плащпалаткалардан, бер төрле дә хәрби тамгаларыбыз юк. Корал — автомат та гранаталар гына.

Төн бик караңгы иде. Командир башта ук мине үз янына дәшеп алды да:

— Син төнлә мәче кебек күрәсең. Әйдә алдан бар, тик сак бул, янгырга да, караңгыга да артык ышанма,— диде, аннары юнәлешне ачыклады.

Караңгы төн — разведчикларның юлдашы, моны яхшы беләбез, ләкин үзеңә дә ике күзеңне дүрт итәргә кирәк. Лейтенантның кисәтүе әнә шул турыда иде.

Разведкада аеруча алгы кырыйны үтүе кыен, дошман бертуктаусыз ракеталар чөя, автомат, пулеметлардан ата, яктырткыч пулялар кулланa. Кара күктә аларның яшелле-кызыллы эзләре ап-ачык күренә. Безгә дә моның яхшы ягы бар: син алгы кырыйны уңга да, сулга да бик яхшы абайлыйсың. Ләкин үлем утларының нәкъ синең каршыңда да кабынуы мөмкин. Шуңа күрә без бик сак шуышырга тырышабыз. Уйлап та куясың: безгә үз җиребездә дә куркыныч, ә дошман ничек икән? Мөгаен, аның кара җаны табаннарына шуа торгандыр.

Ниһаять, алгы кырый артта кала, без аякка басабыз, тәпиләп китәбез. Әлбәттә, юлдан бармыйбыз, азмы-күпме таныш булган авылларга да кермибез. Юллардан немец автомашиналары узып тора, бар да алгы кырыйга ашыгалар. Ләкин нәрсә төягәннәр: азык-төлекме, сугыш припасларымы яки солдатлар утыртканнармы?

Бер уйсулыкта чак кына танкларга барып төртелмәдек. Менә кайда икән аларның оясы! Артиллерия яки авиация һөҗүме өчен бик шәп урын. Без аны күңелебездән билгеләп үтәбез.

Юлыбызны дәвам итеп, чама белән тагын алты-җиде километр киттек. Юлда инде автомашиналар күренми, тавышлары да ишетелми.

Ниһаять, ике сәгатьләр вакыт узгач, авыл күренә башлады, караңгыда аңа тәмам якын килгәнбез. Беркадәр читкәрәк китеп, калкурак

урынга яттык. Бераз күзәтеп тордык. Безгә кирәкле укытучы шул авылда, мәктәптән бик ерак тормый дигәннәр иде. Ләкин бу карангыда табып кара син ул мәктәпне! Лейтенант — мәктәпне дә, укытучы йортын да, укытучының үзен дә белгән кеше. Бөтен өмет шунда. Тик лейтенант — яңа кеше, шунысы бераз эчне тырный.

Лейтенант, мине ияртеп, авылга алып китте, башкаларга безне шунда көтәргә кушты. Ул-бу була калса, нишләргә кирәклеге турында сүз куештык.

Менә без икәү генә инде. Авылда дошман булырга тиеш. Бер тавыш чыгармаска тырышып сак кына атлыйбыз. Этләр генә өрә күрмәсен. Ләкин, бәхеткә каршы, анда бер тавыш та ишетелми.

Хәзер лейтенант алдан бара. Укытучының өе бераз читтәрәк икән. Авылның бу башы бик үк зарарланмаган, күрәсең, артиллерия уты монда уйнамаган. Элекке мәгълүмат буенча, авылда ир-ат калмаган, хатын-кызлар да бала-чагалар гына. Кызлар да юк, я безнең якка чигенгәннәр, я партизаннарга киткәннәр.

Лейтенант бер өйгә бармагы белән төртеп күрсәтте, мин аңладым: укытучы өе шушы икән. Бераз тыңлап тордык. Шылт иткән тавыш та юк. Аннары иелеп кенә алга үтеп, стена буена сыенабыз, тирә-ягыбызга каранабыз. Шикле нәрсә булмагач, лейтенант тәрәзәгә якын килә, пыялага өч тапкыр әкрен генә чиертә. Бераз торгач, тагын өч тапкыр кага, тагын җавап юк. Бер минуттан яңадан өч тапкыр чиертә. Бу юлы тәрәзәгә корган юрганның бер чите чак кына күтәрелә. Мин өй почмагыннан урамны күзәтәм. Лейтенант, ниндидер билгеләр күрсәтеп, ишеккә юнәлә. Хәзер тышта мин бер үзем, уңга да, сулга да каранам. Кайчагында янган өйләр турында торып калган морҗалар минем янга йөгереп килүче гитлерчылар булып күренә. Карый-карый хәтта күзләрем авырта башлый.

Алгы кырыйны үтеп киткәч тә яңгыр туктаган иде, баш турысыннан, айны, йолдызларны каплап, салкын болытлар гына ага иде. Хәзер тагын шыбырдап яңгыр ява. Юлда тәмам тирләгән идем, стенага сөялеп торатора әчкә суык та үтте. Әмма кинәт күз алдыма Мөслимә килеп баскач, бер секундта җылынып киткәндәй булдым. Гүя, хәлемә кереп, бик кыенмы? — дип сорый. Мин разведчик гадәтен белдем, теләсә нинди очракта да тавыш чыгарырга ярамый, елмаям гына. Шуннан Мөслимә кул болгый-болгый юкка чыга. Ләкин миңа инде җиңелрәк, шыбырдап яуган яңгыр аша авылга таба кыюрак карыйм. Җил дә кузгала төшкән икән. Әллә өй ышыгында булганга мин элек сизмәгәнмен, әллә ул, чыннан да, яңарак кына кузгалган инде. Чү, кайдадыр автомашиналармы, танкларммы гүли. Аларны авыл кырыена калган иптәшләр яхшырак ишетә, хәтта күрә дә торганнардыр бәлки, аннан юл якынрак бит. Бераздан мин дә ачыграк белә төштем: бу танклар гүләве түгел, бу — автомашиналар. Нәрсә алып баралар икән? Хәер, Панкратов белешми калмас.

Автомашиналар тавышы бөтенләй тынды. Ул арада лейтенант та өйдән чыкты. Мин аңа юлда машиналар тавышы ишетелүен әйттем. Лейтенант башын иеп алды. Шуннан иптәшләр янына киттек. Җил шактый шәбәйгән икән, яңгыр басыла төшкән. Мин чокыр-чакырларны, өем-үрләрне, агач-куакларны хәтеремә яхшы сеңдергән идем, шуңа күрә иптәшләр янына туп-туры килеп чыктык.

— Утызга якын автомашина үтте. Солдатлар,— диде Панкратов командирга.

— Яхшы,— диде лейтенант, өстәмә сораулар бирмичә.— Хәзер тизрәк өйгә. Малик, алга!

Күрәсең, укытучы командирга бик мөһим мәгълүматлар биргән, юлдагы машиналар тавышы аның әйткәннәрен раслаган. Мин шул турыда уйлый-уйлый ин алдан барам. Яңгыр тагын көчәеп китте, аяк-

лар лычкылдый, итекләргә балчык ябыша, аяк атлавы кыен. Кием дә чыланып беткән, әмма без суыкны тоймадык, киресенчә, бара торгач тирләп чыктык. Берничә минут утырып ял итү ни рәхәт булыр иде, ләкин без бер генә минутка да туктамыйбыз. Тик дошман танклары урнашкан уйсулык янында гына лейтенант, безне бераз туктатып, үзе Панкратов белән алгарак китте. Алар күп булса унбиш-егерме минут югалып тордылар. Аннары, уйсулыкны урап, юлыбызны тагын дәвам иттердек.

Кайтканда юл кыскарак була, ди. Чын, ахрысы, барганда бик озак тоелган иде, кайтканда очып кайттык шикелле. Әнә фронт сызыгы өстендә ракеталар, яктырткыч пулялар өере күренә инде. Ракеталар яңгыр эчендә атлан май кисәге кебек эрегәндәй юк булалар, пуляларның эзе бик азга булса да ачык сызыла.

Алгы кырыйга житәрәк, жиргә ятып тынлап тордык, хәвеф-хәтәр сизелмәгәч, шуыша башладык. Яктырткыч пулялар ара-тирә безнең өстән дә сызгырып үтте. Ләкин болар адашкан пулялар гына иде. Ниһаять, без үзебезнең якка чыктык, без инде үз траншеяларыбызда. Өстән, әйтерсең, тау төште.

— Панкратов, минем белән, калганнарга, кайтып, яхшылап ял итәргә,— диде лейтенант.

Мин лейтенантка карадым. «Сезгә хәзер ышанам!» дип әйтергәме? Юк, сүз кирәкми, ләкин күңелдә ышаныч булуы зур нәрсә.

Разведчиклар өендә сукыр лампа яна иде. Заданиегә бармаган иптәшләр изрәп йоклыйлар. Без шаулашып, күтәренке күңел белән кайтып кердек. Көн саен хат көтә торган бер иптәшебез, өстәл янына узып, анда яткан конвертны алып карарга да өлгерде.

— Әй, Абрек, сиңа хат бар,— диде.— Кешегә бәхет өелеп торса тора икән. Миңа күпме көтеп тә бер хат юк.

Мин, хатка исем китмәгән кебек, баштa өстемне чишендем, плащ-палаткамны, гимнастерка-чалбарымны мич буена кибәргә элдем. Чолгаулар да тәмам чыланган иде, аларны да кибәргә куйдым. Шуннан артыкка көчем житмәде, ялан тәпи белән идәнгә баса-баса, өстәл янына килдем. Хат, мөгаен, Мөслимәдәндер дип уйладым. Анардан хат алу миңа бер рәхәт була торган иде. Ашыкмый гына аның хатын уку, аннары ятып хыяллану үзе ни тора! Житмәсә, бүген заданиене уңышлы үтәп кайттык. Мин, шул яшерен шатлыкны бераз сузарга теләп, бер минут чамасы хатка кагылмадым. Ләкин бу хат Мөслимәдән түгел, хат әнкәйләрдән иде. Мин конвертны кулыма алу белән үк сеңелкәшнең әре, ачык язуын танырдым. Башта ул гадәт буенча әнкәйдән, үзеннән, аннары ыру-кардәшләрдән сәлам язган, барысының да исән-саулыкларын белдергән. Мөниргә дә күп итеп сәлам куйган. Шуннан соң әткәйнең үлүе турында рәсми язу килгәнлеген әйткән.

Без инде әткәйнең үлгән хәбәрен тылда ук ишеткән, иптәшләреннән хат та алган идек. Ләкин рәсми язу юк иде әле. Кеше бит авыр хәбәргә берьюлы ук ышанмаска тырыша, юк өметне бар итә. Без дә, рәсми язу булмагач, шулай өметләнгән идек. Инде өмет тә калмады. Мин әнкәйнең сабыр гына жылавын, сеңелкәшнең үксүен ишетәм кебек. Тылда чакта, әллә үлемнең нәрсә икәнен яхшылап белмәгәнгә, әллә гамьсезлек аркасында бу хәбәрне ничектер жиңелрәк кичергән идем. Хәзер бугазыма нәрсәдер килеп ябышты сыман. Күз алдыма әле күптән түгел генә булган караңгы авыл килеп басты. Менә шул караңгылык, шул шыксыз, кайгы-хәсрәтле жил минем жанымны өшетә. Фашизм безгә бары тик шуны гына китерә бит. Шулай да, көн саен ут эчендә булсам да, сау-таза ирләрнең сәгать саен жансыз гәүдәләрен күрсәм дә, әткәйнең үлүенә ышанасым килмәде. Юк, бу алай булмаска тиеш, монда ниндидер хата бардыр. Ләкин күңел шомлана, иптәшләре дә язган иде бит, рәсми хат шул фажигане дөресли генә. Мин күзләремне чытырда-

тып йомам. Шунда ук эткәйнең ялкын улаган дәү мичен күрәм. Бу мичтә бөтен дошманнарның кара оясын яндырырлык ялкын бар кебек. Әнә ул ничек дөрли, әнә ул ничек үкерә, сикерә, айкала.

Панкратов кайтып керде. Иптәшләр йоклый иде инде, ә мин һаман өстәл янында утырып торам. Иптәшләр минем яныма килгәндер, нәрсәләрдер әйткәннәрдер бәлки. Бездә бит кайгыны күрмәмешкә салынмыйлар, аннары без аны алай тирән яшерә дә белмибез. Ләкин мин үзем аларга җавап бирмәгәнмендер. Панкратов, плащ-палаткасын салып, минем яныма килеп утырды, кулын иңемә салды. Шулай берничә минут сүзсез генә утырдык. Ул, күзләре белән өстәлдәге конвертка ымлап:

— Күңелсез хәбәрме? — диде.

— Әйе, эткәйнең сугышта үлгәнлеген раслаганнар. Инде бер өмет тә калмады.

Панкратов: сугыш заманы бит, хәзер бөтен илгә шундый хәбәрләр бара, сабыр итәргә кирәк дигән гади юату сүзләрен әйтмәде, чөнки бу сүзләр минем кайгымны җиңеләйтмәвен белә иде. Солдат үзенең бөтен нәфрәтен автоматка корып, дошманга атмыйча торып бушана алмый. Солдат ярсуы дошман башына пуля булып яуса гына ничектер җиңелрәк була кебек.

Панкратов белән янәшә яттык, ләкин ул да, мин дә тиз генә йокыга китә алмадык. Мин һаман эткәйнең тыйнак йөзен, мичендә айкалган ялкынын күрдем. Йөзләрчә кешеләр, көн саен май кебек җылыга кергәндә, эткәй турында, гади истопник турында уйлаганнардырмы? Ул күзгә күренмичә, үз эшен зурга куймыйча, кешеләргә җылы өләшеп торды, моның өчен үзенә бер нәрсә дә сорамады.

Ничектер йоклап киткәнмен, коточкыч арганлык, ахырысы, үзенекен иткән. Ләкин мин күземне йомарга да өлгермәдем шикелле, кемнендер дулкынланган тавышны ишетелде:

— Тревога!

Бер ротага якын гитлерчылар безнең тылга үтеп кергәннәр, батальон штабын чолгап алганнар. Бөтен писарьлар, штаб кешеләре, каравылда торучылар һәм шул тирәдәге сугышчылар дошманга каршы сугыша башлаган. Разведчикларны да шунда алып бардылар. Ләкин батальон штабына үтәргә мөмкин түгел иде.

— Минем арттан! — дип кычкырдым мин иптәшләргә. Берничә минутта без гитлерчыларның тылына төштек. Бу вакытта алгы кырыйда да атыш кузгалган иде. Күрәсең, дошман үзенең тылга үтеп кергән солдатларына ярдәмгә килергә маташа, танклары да үкерә. Берничәсен безнең пехотачылар яндырып та өлгергәннәр, аларның кара төтеннәре иртәнге тонык яктылыкта ап-ачык күренә.

Мин хәлнең чиктән тыш авыр, катлаулы икәнен аңладым. Ләкин тәвәккәл таш яра. Без дошман өстенә давыл булып ябырылдык. Дошманның моңарчы нинди дә булса тәртип булган тылында буталыш китте. Ә без, алар арасына бәреп кереп, уңга да, сулга да кисә башладык, плен алып тормадык. Ул арада штаб ягыннан да безнең иптәшләр атакага күтәрелде. Белмим, бәрелеш күпме дәвам иткәндер, ниһаять, тылга үтеп кергән гитлерчылар каршылык күрсәтүдән туктадылар. Дөресрәге, яраланган берничә немецтан башкасы барысы да дөмектерелгән иде. Соңыннан яраланып исән калган бер немец капралы:

— Сезнең арада ниндидер бер пәһлеван солдат бар иде. Ул сугыш кырында кара яшен кебек айкалды. Бер үзе безнең дисталәгән солдатны кырды,— дигән.

Иптәшләр миңа шул турыда әйткәч:

— Кызганыч, минем күзгә чалынмады, мин аңа кара яшенне күрсәтер идем,— дидем. Тик бер нәрсәне белмәгәнмен: мин гитлерчылар өстенә ташланган чагында, Панкратов мине һәрвакыт саклап торган, миңа янаган һәр куркынычны вакытында юк итәргә тырышкан. Ләкин

үзе бу турыда соңыннан да берни әйтмәде. Ә башкаларның бу турыда сөйләүләрен ишеткәч:

— Без үз кешеләр, исәпләшербез әле,— диде. Мин бары тик аның елмаеп торган күзләрен генә күрдем.

## 6

Мәскәү янындагы сугышларның бераз йомшара төшүе вакытлы гына бер күренеш булды. Гитлер командованиесе үзенең көчләрен янадан укмаштыра, резервларын якынрак китерә башлады. Димәк, янадан һөҗүм. «Җинелмәс» дигән даннарын кайтару өчен гитлерчылар теләсә ничек булса да Мәскәүне алырга ниятләгәннәр. Бу аларның актыккы көчәнүләре. Алар картага бөтен нәрсәләрен куярга әзер.

Без бу ударга да каршы торырга тиеш идек. 7 нче ноябрьда Мәскәүдә Кызыл мәйданда бик зур парад булган. Шул ук көнне бу турыда безгә политруклар сөйләделәр.

Дошман безне актык сулышыбызны алабыз дип уйлый, имеш. Кызыл мәйдандагы парад турында ишеткәч нишләр, шартларга житешердер. Ул бетте дип санаган Кызыл Армия парад үткәрә, фашист урдаларын кырып бетерергә ант итә!

«Үзәккә» караган армияләр группасының штабында Гитлер — калай әтәч — болай дигән икән: янәсе, Мәскәүне шулай урап алырга кирәк ки, аннан бер совет солдаты да, бер совет кешесе дә — ирме ул, хатынкызмы яки бала-чагамы — чыгып китә алмасын. Аннары, бик зур корылмалар ясап, Мәскәүне һәм аның әйләнә-тирәсен суга батырырга. Хәзер Мәскәү тора торган урында бик зур диңгез булырга, ул рус халкының башкаласын цивилизацияле дөнья күзеннән мәңгегә яшерергә тиеш икән.

Бу кадәр явыз, кара уйларның бары тик ата фашист башында гына тууы мөмкин. Бу саташкан, котырган кешенең уйлары. Без тешләребезне кыстык.

Немец-фашист гаскәрләренең Мәскәүгә икенче «генераль» һөҗүме ноябрь уртасында башланды. 16 ноябрьда гитлерчылар Волоколамск юнәлешендә торган 16 нчы армия частьларына да һөҗүм иттеләр. Совет сугышчылары бик каты каршылык күрсәтте. Шул ук көнне безнең армиянең уң канаты гитлерчыларга каршы контрһөҗүмгә күчте.

Шушы өзлексез сугышлар беразга тынган арада, разведкадан кайтканда, урман читендә бер карчыкны очраттык. Ул кай ягы беләндер минем әнкәйгә охшаган иде. Үзе дә гел миңа карап сөйләде.

— Төпчегем нәкъ менә синең шикелле эре сөякле иде. Кырыгынчы елны Кызыл Армиягә алдылар. Хатлары гел килеп тора иде, сугыш башлангач өзелде. Хәзер исәндерме-юктырмы, белмим. Монда ничек газап чигүебезне белми торгандыр инде, белсә түзмәс иде. Бик акыллы егет иде, бер дә курыкмас җан иде,— диде.

Менә шул кара шәлле карчыкның җыерчыклы битләре буйлап аккан күз яшьләре минем күз алдымнан һич китмәде. Мин ямансулый башладым. Хәзер менә бер үзем өйдә утырам, ниләшләрнең кайсы чыккан, кайсы ял итә. Моңсу гына уйлап та, җырлап та алам. Сугышка чаклы гармун уйнарга бик дәртем бар иде. Уйнарга өйрәнергә дә йөрдем, булмады. Әнкәй әйтә торган иде: «Күңел бирмисең, форсун син. Көзге алдында бу хәтле басып торганчы, гармун уйнасаң, өйрәнмәс идеңме? Аю энә биергә дә өйрәнә ич!» — ди иде. Әйе, аю биергә дә өйрәнә, ә мин менә гармун уйнарга да өйрәнә алмадым. Кайтсам, өйрәнер идем... Кайтсам... Бу мөмкинме?

Үз алдыма әкрен генә җырлап җибәрәм:

Әнкәй мине тапкачтын
Ак бәйләүгә бәйләгән;
Ак бәйләүләргә бәйләгән,
Бәхете булсын дигән.

Ак бидерә, чын бидерә,
Сулары тамып тора.
Бергә чакта берни түгел,
Аерылгач сагындыра.

Мөнир дә ара-тирә җырлаштыргалый, башка татар солдатлары да моңланган чакларында туган җырны сузалар. Әллә нәрсәләр искә төшә, әллә нәрсәләр сагындыра.

Кинәт самолет тавышлары ишетелә, ул да булмый — дошман безнең тирәне бомбага тота башлый. Каһәр суккыры, нәкъ безнең өскә яудыра бит. Күз ачып йомганчы өйдән чыгып, якындагы «ярыкларга» сикерәбез. Әйтерсең, җир тетри — бомбалар сызгырып ярыла, өскә туфрак коела. Авызны зур ачып, җиргә төртелеп торасың. Аннары тына, без әле кетәбез, башны күтәрмибез. Ниһаять, җир астыннан башны калкытабыз. Күр инде! Әле генә без ял итеп торган өй юк инде, тетелеп яна. Минем биштәрем дә юкка чыккан. Биштәр төбендә Мөслимәнең хатлары ята иде, мин аларның барысын җыя барган идем бит. Менә шулар бик кызганыч булды.

Бер көнне, каты сугышлардан соң, безнең подразделениеләр Истра елгасы аръягына чигенде, алда фәкать заслоннар гына калды.

— Точка! Моннан ары безгә артка таба бер адым да юл юк. Кузгалсак, алга таба гына кузгалырбыз. Ә хәзер, күп сөйләп тормыйча, эшкә керешик, егетләр. Вакытның кадерен үзегез дә беләсез,— диде пехота командиры үзенең солдатларына.

Караңгы төшеп килә. Тирә-як ачык диярлек, тик су буенда гына куаклар һәм ялгыз-ярым агачлар бар. Алда — күпер. Заслоннар кайткач, аны шартлатырлар. Сугышчылар ял да итмичә эшкә керештеләр, кайсылары траншея, окоп, ячейка казый, кайсылары пулеметлары, минометлары өчен ут позицияләре булдыра. Безнең саперлар берничә көн инде монда эшлиләр. Тик разведчиклар гына пехотачыларга урын күрсәтергә билгеләнгән. Менә тагын бер тәмәке тартып алгач, алга, заслоннар янына китәбез.

Күперне чыктык. Күпер нык, таштан. Ләкин озакламый аны шартлатырга туры киләчәк. Мин көрсенеп алам, гомеремдә бер күпер дә салганым юк, гел җимерәбез генә. Әгәр сугыштан исән кайтсам, төзүче булыр идем.

Минем белән янәшә Панкратов, Мөнир һәм тагын берничә кеше атлый. Монда болай беркадәр тыныч — тиле снарядлар гына ара-тирә килеп төшеп ярыла яки күзгә күренмәгән пулялар выж итеп үтеп китә. Алда атыш һич туктамый, ракеталар өзлексез чөелә. Анда эшләр бик кызу икәнен беләбез. Төп көчләр китте бит. Дошман әгәр бу хәлне белеп алса, тынгылык күрсәтмәячәк. Без ашыгабыз. Әлбәттә, биш-алты кеше мәсьәләне бер якка да хәл итә алмаячак, ләкин кыен чакта анысы да ярап куя. Бер-ике фашистны тончыктырсаң да файда. Кайда булса окоп төбендә яки урман аланында бик кыска итеп үткәрелгән комсомол җыелышларында да, тәмәке тарткан арада алып барылган агитатор әңгәмәсендә дә гел шул нәрсә әйтелә. Башта да шул гына.

Батальон комиссары заслоннар белән калган иде. Аны эзләп табып, үзебезнең килгәнлекне әйтәбез. Комиссар частьнең билгеләнгән урынга ничек барып җитүе, нишләп калуы турында сораша. Ләкин яхшылап җавап бирергә дә өлгермибез, кызу атышлар башланып китә, барыбыз да коралга тотынабыз.

Ул төнне заслоннарны алырга мөмкинлек булмады. Немецлар бездәге үзгәрешләрне белепме, әллә болай гына тынычсызланганнармы, төне буе тынгылык бирмәделәр. Яктыргач, безнең траншеялар өстендә аларның самолетлары үкерә башлады. Сәгать уннарда һәм унберләрдә ике тапкыр рәттән безнең позицияләргә һөҗүм ясап карадылар. Беренче бәрелеш бик каты булды, алгы кырый каршында аларның берничә

танкысын безнең сугышчылар яндырып та өлгерде. Заслонда җиңел туплар гына. Авыр туплар безгә Истра аръягыннан ярдәм итеп тордылар. Гитлерчылар, бик күп солдатларын югалткач, чигенергә мәҗбүр булдылар. Бер сәгатьтән соң тагын һөҗүм итеп карадылар, ләкин бу юлы аларның басымы артык көчле булмады. Аның каравы, без дә актык көчебез белән тора идек. Шуның өстенә авыр яралылар да күбәйде. Аларны кич җитмичә эвакуацияләп тә булмый.

Караңгы төшкәч, башта яралыларны озаттык, аннары берәм-берәм заслоннар кузгала башлады. Комиссар белән без, разведчиклар, окопларда актык чиккәчә калдык, траншеялар буйлап йөреп, әле автоматлардан, әле кул пулеметыннан аттык, әле ракеталар чөйдек. Кыскасы, оборонаның бар икәнен күрсәтергә тырыштык. Ярты төн үткәч, ниһаять, без дә кузгалдык. Комиссар янында нибары биш кеше калган идек. Башка разведчиклар алдан юл күрсәтә киттеләр.

Күп тә үтмәде, артта танклар гүләвен, каты шартлау тавышларын ишеттек, ә күпергә җитәрәк безгә автомат һәм пулеметлардан көчле ут ачтылар. Болар немецлар идеме, үзебезнекеләр идеме, караңгыда белеп булмады. Күперне шартлаткан тавыш та ишетелмәде. Без, сулгарак китеп, күпердән байтак читтәрәк, су буена төштек. Тыңлап тордык. Атышлар — күпер тирәсендә, монда тавыш-фәлән ишетелми. Истра елгасының бу тирәдәге суын элек үк тикшергән идек, урыны-урыны белән аны көймәсез дә кичеп була. Ләкин хәзер су бик тирән сыман, үзе кара, аргы як яр тоныкк кына шәйләнә. Анда үзебезнекеләр булырга тиеш. Ләкин яр буенда миналар бар. Нишләргә? Таңга кадәр көтәргә ярамый. Көндезен бу тирәләргә дошман тулар. Ни булса да хәзер тәвәккәлләргә кирәк. Үзара киңәштек тә суга кердек. Иң алдан мин киттем. Башта су бик үк тирән түгел иде, аннары тиздән, билдән, хәтта муеннан була башлады. Шул вакытта, бер дә көтмәгәндә, ике яктан да ут ачтылар. Безнең эш бик мөшкелләнде. Артка китсәк тә вай, алга китсәк тә вай. Алга бардык, тик, үзенә әйтмичә генә, комиссарны уртага алдык. Ярый әле, пулялар кайдадыр читтәрәк сызгыралар.

Миндә, автоматтан тыш, кул пулеметы да бар. Аларны чылатмас өчен, баш өстенә куеп барам. Үзем уйлыйм: шулай ук немецлар елга буена килеп җиттеләрме икән? Күперне дә алдыларммы? Шартлау тавышы ишетелмәде бит. Әгәр гитлерчылар, елганы кичеп, плацдарм алсалар, безнең гаскәрләрнең хәле бик кискенләшә. Ә су минем муеннан. Мөнир белән комиссар минем буе, Панкратов һәм тагын бер иптәш миннән тәбәнәгрәк. Аларга инде йөзәргә туры килә торгандыр. Пулялар бөтенләй якында ук оча башлады. Һәр минут саен ракета кабынуын көтәбез. Аннары эшләр харап дигән сүз.

Шул вакыт минем күз алдыма Мөслимә килде. Миңа берьюлы җиңел булып китте. Су да аз гына саега төште. Артка борылып карадым: комиссар минем янымда ук, Мөнир белән Панкратов уңнан һәм сулдан киләләр, дүртенче иптәш арттан. Берәү дә калышмаган.

Елганың уртасын үттек бугай. Бер минут чамасы тын алдык та тагын алга юнәлдек. Ул арада атышлар да әкрен-әкрен басылды. Ләкин туңдыра башлады, безнең бит каска астындагы баш киемнәребез генә коры калган.

Яр буйларына үзебез миналар куйган идек. Мин аларның кайда икәнен белә кебек. Караңгыда ялгышсаң? Бик зур саклык белән генә ярга чыктык. Хәзер барыбыз диярлек бер эзгә басып барабыз. Чак кына читкә китсәң дә — төзәлмәс үкенеч булуы мөмкин.

Кинәт безне туктаттылар. Болар үзебезнең часть солдатлары иде. Бик тиз аңлаштык. Комиссар безне рота командиры янына илтергә кушты.

— Сез... елга төбеннәнме әллә? — дип сорады рота командиры

безнең су тамып торган киемнәргә карап.— Ничек... миналарга элэкмәдегез?

— Ә болар кемнәр? — дип көлемсерәде комиссар, безгә таба күрсәтеп.— Минер үзе куйган минада үзе шартламый.

Комиссар өлкән командирлар белән телефон аша сөйләшеп алды. Заслоннар барысы да үз ягыбызга чыккан, тик комиссар группасы гына булмаган, безне үлгәнгә санаганнар. Гитлерчыларның алгы группасы күпер алдына ук килеп җиткән. Күрәсең, алар безнең киткәнне сизеп алганнар...

Берничә көн үткәч, безнең төнге «сәяхәт» турында дивизия газетасында да язганнар икән. Мин үзем укый алмадым, заданиедә булып калдым. Минем турыда аерым әйткәннәр, ди. Нәрсә әйттеләр икән? Мөнирдән сораган идем, ул да газетаны күрми калган. Рәтле язганнар булса, Мөслимәгә җибәрергә исәп бар.

Шул көннәрдә мин аңардан хат та алдым. Нинди җылы, нинди мәхәббәтле хат иде ул! Мин аны бер дә укыдым, ике дә укыдым. Заданиедән кайткач, тагын рәхәтләнеп кулыма алдым. Иптәшләр хатта шаярталар:

— Ну бу кызый! Гвардия өлкән сержантын ничек бөтереп алган, әйләнә дә хат укый, әйләнә дә хат укый! — диләр.

Әйе, укыган саен Мөслимәнең хатында яңа бер мәгънә ачам. Кәгазе дә гади генә — шакмаклы дәфтәр бите, сүзләре дә гади генә, ә мәгънәләре нинди тирән! Мин гомумән болай язарга — бигрәк тә хатта — һич мөмкин түгелдер дип уйлый идем.

«...Мин синең өчен бик тә, бик тә борчылам, Малик. Син үзең турында, ничек сугышуың турында бер дә язмыйсың, әйтерсең, ял йортында ятасың. Без газеталардан укып та Мәскәү янында нинди каты сугышлар барганын беләбез. Син бит әллә кая читтә түгел. Нигә язмыйсың? Бер көнне сеңелең Әминәне урамда очраттым. Абыйны «Батырлык өчен» медале белән бүләкләгәннәр, диде. Белсәң иде ничек шатланганымны, сөенгәнемне? Медальнең исеме үк ни өчен биргәннәрен әйтеп тора. Сине башкача күз алдыма да китерми идем. Мин үз сөюем белән горурланам, сиңа тиң булырга тырышам, Малик. Кайчагында бергә булган урыннарга барам, сине уйлыйм, исемеңне кабатлыйм. Үпкәм дә бар, Малик. Шундый зур шатлыгың турында миңа нигәдер язмыйсың. Моны ничек аңларга? Тыйнаклыкмы, әллә... игътибарсызлыкмы? Мине андый хәбәргә шатланмас дип уйлыйсыңмы? Синең турыңдагы кечкенә генә хәбәр дә кадерле бит миңа, Малик бәгырем...»

Мөслимә минем күңелемдә көннән көн күбрәк, тулырак урын ала бара. Тәмәке тартканда, окоп төбендә берничә минут утырганда, бөгәрләнеп йокыга ятканда яки разведкага барганда яки миналар, шартлаткычлар куйганда сөйгәнең кинәт исеңә төшсә, сиңа ничектер җиңелрәк булып китә, караңгылык та, куркыныч та артка чигә кебек, гүя син җиңелмәс бер көчкә әвереләсең. Күпме татыдым мин моны сугыш уты эчендә!

Бу көннәрдә безнең юнәлештә дошман берничә тапкыр Истра елгасын кичәргә маташып карады. Уңышка аңа юл да ачык кебек: күперне нигәдер шартлаттырмадылар. Дөрес, күпер миналанган, аны теләсә кайсы минутта һавага очыртып була. Гитлерчылар күпергә таба якынлаша башласа, безнекеләр пулеметлардан давыллы ут ача, без кузгалсак, алар юл бирми.

Бер көнне гитлерчыларның басымы аерата көчәйде, аларның күпер аша чыгу куркынычы туды. Безнең командование күперне шартлатырга хәзерләнергә боерык биргән. Син ашыкканда ул кабалана дигәндәй, дошман миналары күпер астындагы шартлаткычка тоташтырылган шнурны өзгән. Ялгарга дип шуышып киткән сугышчыларның берсе дә әйләнеп кайтмады. Ә командование күперне шартлатырга минут

саен эзер булуны талэп итэ. Шуннан яңа минерлар линиягэ китэ, лэкин алар да боерыкны үти алмый.

Батальон командирына бик каты приказ булган. Безнең янга килгэндэ аның йөзендэ кан эсэре калмаган иде.

— Иптэш комбат, миңа рөхсэт итегез, мин барам,— дидем мин. Командир башта рөхсэт итмэде, аннары миңа туры карап алгач, барыгыз, диде. Үзенең киңэшлэрен эйтте. Мин, Панкратовның авызындагы тэмэкесен алып, берничэ суырдым да, автоматымны асып, траншеядан сикереп чыктым. Безнең артиллерия һэм минометлар, мине каплап, дошман өстенэ көчле ут ачтылар. Башта мин ярыйсы җиңел шуыштым, миңа турыдан туры атмадылар. Аннары мине күреп алдылар бугай, дошман пулялары нэкъ минем тирэдэ чыелдый башлады. Миннэн алда киткэн иптэшлэрнең үле гэүдэлэре дэ нэкъ шул турыда ята иде. Мин тэмам тиргэ баттым, һэлак булган иптэшнең аркасыннан телефонны көч-хэл белэн алып, юл буендагы канауга таба шуыштым. Менэ беренче өзек урын. Шнурның бер башын тиз таптым, э икенче башы бөтенлэй күренми дэ. Канаудан чыксаң да, канау буйлап кузгалсаң да — аталар. Шулай да кузгалырга кирэк. Минер кеше — салкын канлы булырга күнеккэнмен. Эмма аркадан тир чыга. Тешемне кысып шуышам, пулялар баш өстемдэ генэ чик-чик итэ. Э шнур башы эллэ кая очкан. Чак таптым. Кулыма тотып кире шуышсам, житми, ялгап булмый. Ярый эле: кесэмдэ шнур кисэге бар. Ялгый башлаган идем, ике тапкыр тузан туздырып янымда гына жиргэ пуля кадалды. Күзлэремэ ком тулды. Аннары каскама нэрсэдер бэрелде, башым чаң итеп китте, күзлэремнэн утлар чэчрэде. Шулай да шнурның ике башын ялгадым. Хэзер тагын алга шуышырга кирэк, бэлки алда да өзелгэн урыннар бардыр. Канауга сикерүем булды, атудан туктадылар. Нэрсэ бу? Моннан күренмиме, эллэ үтердек дип торалармы? Канау буйлап аз гына шуышкан идем, баш өстемдэ пуля баягыдан да көчлерэк сызгыра башлады. Нэкъ шунда безнең тагын бер минерны үтергэннэр. Күрэсең, бу жир аларга бик яхшы күренэ. Ярый эле: безнең минометлар дошман пулеметын тынарга мэжбүр иттелэр. Шуннан файдаланып, мин куркыныч араны үттем.

Ничэ жирдэн ялгаганмындыр — белмим. Ниһаять, күпер янына ук барып життем. Биредэ атмыйлар, өзек урыннар да күренми. Жиңел сулап, аркамдагы телефонымны алдым да бер минут кичекмичэ күперне шартлатуларын үтендем.

Трубкада комбат тавышы ишетелде:

— Газимов, рэхмэт. Хэзер кайт, ишетэсеңме, кайт!

— Шартлатыгыз!

— Газимов, кайт, приказ!

— Шартлатыгыз! Вакытны эрэм итмэгез. Мин барысын да уйладым!

Комбат риза булмады, тагын приказын кабатлады. Шуннан соң мин кайтырга булдым. Кайту — бару түгел, дилэр. Чыннан да миңа ул күп тапкырлар жиңелрэк булып тоелды.

Траншеяда мине комбат каршы алды. Кулымны чигэгэ күтэреп рапорт биргэч, ул мине кочаклап үпте дэ:

— Рэхмэт, туган, рэхмэт,— диде.

Шуннан комбат телефонга ябышты, заданиенең үтэлүен, минерның исэн килеш кайтуын эйтте. Күперне шартлатырга рөхсэт сорады. Лэкин анда... сабыр итэргэ куштылар.

Приказны тикшереп тормыйлар. Сугыш кырында бөтен нэрсэнең бик тиз үзгэрүе мөмкин. Эле генэ үлем куркынычы белэн исэплэшмичэ эшлэнгэн эшнең хэзер нэкъ киресен үтэргэ туры килэ икэн, бер дэ гажэп түгел! Лэкин аңа карап, сугыштан эшнең асылы үзгэрми, батырлык батырлык булып кала бирэ. Приказның вакытында үтэлүе мөһим. Батырлыкның микъдары шул.

Ниһаять! Ниһаять, без һөҗүм итәбез. Бер сәгать түгел, бер көн түгел, бер атна, ике атна, хәтта артыграк та! Юл буенда без кадаклаган фанер кисәкләре кала: «Юлның ике ягы да миналардан әрчелде...» Уннарча авылларны, Истра, Волоколамск шәһәрләрен алдык. Мин, билгеле, үз юнәлешебезне генә күздә тотам. Ә Мәскәү янында, гаять зур фронтта, бөтен гаскәрләр һөҗүмгә күчкән. Макталган, күккә чөелгән Гитлер армияләре кача! Яралыларын, коралларын, сугыш припасларын, складларын ташлап кача. Әйе, бу, хәрби максаттан чыгып, планлы рәвештә чигенү түгел, бу чын мәгънәсендә качу. Каткан, туңган, өтәләнгән сугыш чукмарлары ничек табан ялтыраталар! Юл буйлары ватылган, җимерелгән, ташлап калдырылган танклар, автомашиналар, туплар белән тулган. Җылы өйләрдән декабрь салкыннарына куып чыгарылгач, фашистлар кая посарга белмиләр. Әледән-әле безнең солдатлар йөзләгән, меңләгән әсирләрне тылга озаталар. Совет кешеләренең барлык җәфалары, кайгы-хәсрәтләре өчен автоматның дискысы бушаганчы үч аласы иде ул бәдбәхетләрдән. Ләкин без, тешләребезне кысып булса да, аларга тимибез. Коралын ташлаган, кулын күтәргән, җиңүче мәрхәмәтенә бирелгән дошман — ул инде каршы якның гаскәре булудан туктый. Җае туры килгәндә гитлерчылар бик каты сугышалар, актык чиккәчә каршылык күрсәтәләр, күрәсең, эшләгән явызлыклары өчен җавап бирергә туры килүдән куркалар. Андыйлар белән корал сөйләшә, ә аның теле бер: берәүгә дә шәфкать юк.

Бик нык арыла, көненә уннарча километр китәбез. Ләкин бу ару башка, солдатны һөҗүм, ул никадәр авыр булса да, канатландыра гына, туган җирне азат итү көннәрен тизрәк күрәсе килә. Берничәшәр көн ял итмичә, йокламыйча дошманны куабыз.

Кичә шундый бер хәл булды. Гитлерчылар бер авылда алдан хәзерләнгән позицияләрдә бик нык каршылык күрсәттеләр. Без авылга ике тапкыр һөҗүм итеп карадык, булмады, бары тик әллә ничә сугышчыбызны гына югалттык. Караңгы төшкәч, командирдан мине авылга җибәрүен үтендем. Отделение үтә алмаячак, ә бер кеше ничек тә булса юлын табар. Әлбәттә, тәвәккәллек бик зур, күреп алсалар — бер пуля белән эшеңне бетерәчәкләр. Ләкин боларны мин соңыннан гына уйладым. Ә ул чакта бөтен уй — дошманның оборонасын таркату турында гына иде. Командир да кыю кеше булып чыкты, бер дә икеләнеп тормыйча:

— Әйдә, уңыш телим,— диде.— Дзотны шартлатсаң, без хәзер атакага күтәреләбез.

Ничек шуышуымны, авылга ничек керүемне, дзотка тылдан ничек якынлашуымны бәйнә-бәйнә сөйләп тормыйм. Билгеле, җиңел булмады, тирләргә туры килде. Аның каравы, дзотка якынлаштым, танкка каршы куллана торган гранаталар белән аны актарып ташладым. Ул арада безнең пехота атакага күтәрелде, мин автоматым белән гитлерчыларның тылыннан һөҗүм иттем. Караңгыда ничә автомат атканын, кайдан атканын тиз генә чамалап кара менә. Ә безнең бөтен һөҗүм тизлеккә, көтелмәгәнлеккә корылган иде. Авылга бәреп кергәч, сугышчылар бик күп гитлерчыларны күренгән бер җирдә егып салдылар, бары тик кулларын күтәргәннәре генә исән калды.

Минер-разведчикның сугышта үз бурычлары бар. Бер өйдә ике немец офицерын плен алгач һәм өстәлдә авылның ут схемасын күргәч, бик шатландым. Хәзер үк кайда миналар куелганын белештем, аннары әсирләрне пехотачыларга тапшырып, үзебезнең разведка лейтенантын эзләп киттем. Авылда инде безнең солдатлар тулган, әле аннан, әле моннан яшеренгән фашистларны эзләп табып чыгаралар. Аерым атышлар ишетелә иде.

Лейтенантны авыл кырыенда очраттым. Ана немецлардан алган ут схемасын бирдем, мина кырларының кайда икәнен кулым белән урында күрсәттем.

— Монысы яхшы булган, безнең бер отделение монда калыр, ә безгә хәзер үк юлга чыгарга кирәк. Пехота разведкасы дошманны эзәрлекләп китте инде,— диде лейтенант.

Безнең взводтан ике кеше яраланган, бер кеше үлгән, башкалар барысы да монда. Лейтенант беразга авылда калды, ә без, чаңгылар киеп, кырга чыгып киттек. Кышкы айлы төн, һава бик салкын түгел, чаңгы һәйбәт шуа, күңел дә күтәренке, тагын бер авыл азат...

Берничә көннән соң безнең подразделениеләрне ялга туктаттылар. Үз-үзебезне тәртипкә китерәсе, сугыш припаслары аласы бар иде. Бер карчыкның өенә урнаштык. Йокларга ятканчы мин әнкәйләргә хат язарга булдым. Мөслимәгә хат язган идем инде, ә менә әнкәйләргә — юк. Әнкәйне дә, сеңелкәшне дә бик сагындым. Нишлиләр икән хәзер алар, ничек торалар? Зарланып язмыйлар, ләкин тормышлары кыен булса кирәк. Сеңелкәш укытырга кергән. Ир укытучыларның бик күбесе фронтка киткән, ди, алар урынына бөтенләй тәҗрибәсе булмаган яшь-яшь кызлар калган. Сорамасаң да, аларга никадәр кыен икәне билгеле. Әнкәй һаман шунда мәктәптә җыештыручы булып эшли. Тик анда хәзер мәктәпме, әллә госпитальмы? Нигәдер бер дә язмыйлар.

Мин кесәмнән концентрат төрә торган кәгазь алам, биредә башка кәгазь юк. Ләкин тиз генә язып китеп булмый, хыялланам. Спорт залы күз алдыма килә. Мөслимә дә шунда. Алкаларда мәтәлчек атынабыз. Берәребез булдыра алмаса, көләбез. Мөслимәнең тавышы аеруча чыңлый. Кызык, мин күп вакытта күн итек киеп йөри идем, хәтта спорт залына да күн итектән менәм. Монысы, әнкәй әйтмешли, форсун өчендер инде. Итек кунычында еш кына дәфтәрем була. Сәлперәеп беткән, кешегә, бигрәк тә Мөслимәгә күрсәтерлек түгел. Язган чакта тагын әшәке гадәтем бар: карандаш башын чәйни-чәйни язам. Әнкәйләр дә, укытучылар да мине бу гадәтемнән биздерергә тырыштылар, әмма начар гадәт бер ябышса, ябыша икән ул, соңыннан һич ташлый алмыйсың. Тагын көзге алдында бик бөтерелергә ярата идем. Бигрәк тә Мөслимә янына барасым булса. Яңа чыга башлаган мыегымны сыпырам, юләр. Минем, билгеле, рәтле костюмым юк, шуңа күрә җәй көннәрендә күбрәк күлмәкчән йөрим. Билгә каеш буам, өстә — ачык якалы күлмәк. Кепкафәлән кимим, чәч куе, һәйбәт, подполька төзәттергән. Акча булса, одеколон да бөркетәм әле. Әнкәй белән сеңелкәш көләләр, әткәй дә мыек астыннан гына елмая.

— Малай фасонны тота! — ди ул, мәгънәле итеп.— Ничү марканы төшерергә, кем малае дисәләр, Шәйхулла малае булыр.

— Галәмәт инде,— ди әнкәй, авызын яулык чите белән каплап,— өстенә бер бидерә хушбуй аударткан да, Арча кыры юләре кебек, койма башына менеп кикерику кычкыра.

Әткәй белән әнкәйнең тавышларын да, көлүләрен дә ишетәм кебек. Хәлбуки, әти юк инде, ул күңелдә генә. Күрсенәм. Хыял дөньясыннан чын тормышка кайтам, өй эченә күзләремне йөртәм. Шәп-шәрә. Әле күптән түгел генә монда гитлерчылар торган, мич кырыенда берсенең пычрак чолгаулары да калган, кадакта керле күлмәге эленеп тора. Мин аларны алып мич астына ташлыйм. Аннары тагын өстәл янына утырам. Иске гадәтем буенча карандаш башын чәйнәргә тотынам. Бераздан хат яза башлыйм.

«Кадерле әнкәй, кадерле сеңелем Әминә!

Сезгә чуктан чук, күптән күп сәламнәремне күндерәм, исән-сау булуыгызны телим.

Кадерле әнкәй, иң элек шуны әйтергә телим: бу хатны язганда исәнмен, сау-сәламәтмен. Мине үлгән инде бу дип санамагыз. Дошман

тончыксың! Безнең хәзер шатлыгыбыз бик зур, кызу һөҗүм итеп барабыз. Гитлерчыларны рәхимсез кырабыз, исән калганнары тилереп чаба.

Кадерле әнкәем, безнең полк беренче булып Истра шәһәрен алды, аннары гитлерчыларны Волоколамск шәһәреннән бәреп чыгардык. Хәзер һәр җирдә урап алып, бәдбәхетләрнең җаннарын җәһәннәмгә җибәрәбез. Әгәр Н-че гвардия дивизиясе турында газеталардан укысагыз, без шунда булырбыз. Улыгыз Малик шунда сугыша.

Хәзер мин гитлерчылардан сугышып алган бер өйдә утырам. Әнкәй, фашистларның монда нинди кабахәтлекләр эшләүләрен язсам, ышанмассыз. Бөтен авылны диярлек яндырып, талап бетергәннәр, бу як тылда калган совет кешеләрен ачлыктан интектергәннәр, күбесен атканнар, яшьрәкләрне куып алып киткәннәр. Истра шәһәрендә бөтен кыйммәтле тарихи һәйкәлләрне җимергәннәр. Яндырылган, таланган Волоколамск шәһәре читендә сигез партизанны асканнар. Без кергәндә дә алар дарга асылган килеш торалар иде...

Әнкәй, нигә озак хат язмыйсыз? Мин бик көтәм, сездән хат алсам, миңа бәйрәм кебек була. Әнкәй, дошман кача. Тиздән без ул әшәкеләрне җир йөзеннән себереп түгеп, җиңүчеләр булып өйгә кайтырбыз.

Сәламәт булыгыз. Барыгызны да каты итеп үбәм.

Улыгыз Малик.

Хәрәкәттәге армия. Декабрь, 1941 ел.»

Хатны өч почмак итеп бөкләдем дә өстәлгә куйдым. Аннары йокларга яттым. Немецлар өйдә ике катлы сәкеләр эшләгән булганнар. Иптәшләр миңа өске катта урын калдырган. Башымны биштәремә куюым булды, йоклап та киттем. Ләкин йокы тыныч булмады, разведчик йокысы бик сак бит ул. Кемдер кыштырдый башлагач, сикереп тордым. Панкратов икән.

— Нишләп ятмыйсың, җен? — дидем мин аңа.

— Яман ис килә, фриц исе. Бая шунда чолгаулары тора иде, — диде Панкратов.

— Пычагыма кирәк икән шул фриц чолгаулары, йокларга бирмисен. Әнә мич астыннан кара.

Өй эчендә сукыр лампа гына яна. Панкратовның стенада шыксыз озын күләгәсе күренә. Ул, иелеп, мич астыннан фрицның чолгаулары белән күлмәген тартып чыгара да, ишекне ачып, аларны тышка бәрә. Аннары сәкегә менеп ята.

...Икенче көнне тагын алга киттек. Безнең өстә жылы тун, ак комбинезон, башта малахай бүрек, каска, аякта киез итекләр. Иң шатландырганы — яңа чаңгылар. Мин ирексездән үзебезнең Казанка буйларын хәтерлим. Төрле төстәге кәгазь тасмалардан башка таҗ киеп, биек таудан чаңгыда очулар малайларга рәхәт. Булдыра алган кадәрле егетлегенне күрсәт, трамплиннардан сикер, ә башыңдагы төрле төстәге тасмалар сиңа кинофильмнарда гына була торган романтик төс бирә, син гомердә күрмәгән булсаң да, үзеңне легендар герой итеп хисаплыйсың. Менә кайчан ярап куйды ул безнең чаңгылар!

Зур бер авыл кырыена килеп чыккач, безгә пулеметтан ата башладылар. Авыл юл өстендә тора, аны алмыйча ярамый, ләкин үнга да, сулга да китеп карадык — барыбер көчле ут яудыралар.

Ул арада пехота да килеп җитеп, авыл читендәге уйсулыкка урнаша барды. Озакламыйча танклар да килделәр. Күрәсең, дошман безнең хәзерлекне сизде, артиллериясе үзәнлеккә төбәп, давыллы ут ачты.

— Нервылары уйный,— диде Панкратов, шул якка ымлап.— Күрдеңме кая салалар.

Снарядлар үзәнлекнең теге ягында ярыла иде. Берничә минуттан аларның мондарак та ярылулары мөмкин. Димәк, ашыгырга кирәк. Әмма пехота командиры пошынмый, гомуми атака ун сәгать ун минутка билгеләнгән. Хәзер әле ун да юк.

Кар эченә ятып, авылны күзәтәбез. Янybызга лейтенант килә. Безнең саперлар инде алгы кырыйны миналардан әрчи башлаганнар. Безгә, разведчикларга, уң һәм сул фланглар буйлап барырга приказ бирелгән. Атака башлану белән, мөмкин кадәр тизрәк, авылның икенче башына барып чыгарга, пехота отделениеләре белән бергә дошманның чигенү юлларын кисәргә кирәк.

Мин бер төркем разведчиклар белән бергә уң флангка киттем, лейтенант үзе сулга китте. Пехота командиры приказны белә икән. Миңа аның подразделениесен дә, фамилиясен дә әйтте лейтенант.

Үзәнлектә төтен айкала. Кояш та күренми. Без, нелеп, уң флангка күчендек. Подразделениеләр дошманның артиллерия утыннан әллә ни зыян күрмиләр икән. Мин взвод командирын эзләп таптым, ул безгә ярдәмгә отделениеләр билгеләде, сержант белән таныштырды. Алар батыр, куркусыз егетләр шикелле күренәләр.

Үзәнлек төтен эчендә. Гитлерчылар русларның һөҗүмнәрен өздек дип уйлый торганнардыр. Тукта, без чынлап һөҗүм итә башлагач, ни әйтерсез икән?! Мин сәгатькә карыйм, тагын биш минут калып бара. Хәзер безнең артиллерия «сайрый» башлар. Минутлар үткән саен киеренкелек арта бара. Сугышта гел шулай инде, көтү, тик яту авыр, хәрәкәт итә башлагач, барысы да бүтән төс ала.

Ниһаять, җир тетрәтеп, безнең артиллерия залп бирде. Беренчесенә икенчесе, өченчесе кушылды. Артиллерия давылы тәгәл унөч минут дәвам итте. Ул арада безнең саперлар алгы кырыйда эшләрен бетерделәр. Аннары кызу барышлый ата-ата, танкларыбыз узып китте. Көчле ташкын булып пехота кузгалды. Без дә күтәрелдек.

Башта безгә атмадылар, әллә күрмиләр иде, әллә безнең артиллерия ут ноктаcларын җимергән. Зур каршылыкка очрамыйча һаман алга ыргылдык. Хәзер тоткарланмаска гына кирәк.

Без ашыгабыз. Авылга турыдан һөҗүм итүчеләр нигәдер артка калды, анда хәзер бик кызу атышлар гына ишетелә, танклар да нигәдер күренми. Мине безгә атмаулары борчый башлады, берәр капкынга очрамасак ярый. Әнә авылны икегә бүлгән тирән чокыр. Кинәт көчле шартлау яңгырады. Алдан баручы разведчик карга егылды. Шуның артыннан ук безгә пулеметтан көчле ут ачтылар. Мин, ятарга команда биреп, үзем дә карга аудым. Димәк, без мина кырында! Инде нишләргә? Мин башымны чак кына күтәрәм. Карыйм. Пулемет тынды. Унда чокыррак җир. Яралыны шунда сөйрәргә ниятлим. Иптәшләргә кузгалмаска кушып, үзем яралы янына шуышам. Үлгән. Мин: «Монда миналар бар», дигән билге куям да артка шуышам, аннары иптәшләрне уйсурак җирдән алып китәм. Хәзер аяк атлаган саен шартлау көтәсең. Мин бер нәрсә ишетмим, бөтен игътибарым җирдә. Авылны шактый урап, тирән чокырның икенче ягына чыгабыз. Бераз суына төшәм. Мина кыры читтә калды булса кирәк. Безгә атмыйлар, ә авылның аргы башында бик көчле атыш. Әнә чиркәү, манарасында пулеметчы булса кирәк. Бая безгә шуннан атмадылармы икән? Вакыт-вакыт анда машиналар гүли. Әллә авылны калдырырга җыеналармы? Хәзер юлны тизрәк ияләргә кирәк. Бу юлы без миналар куячакбыз.

Тизрәк юлга чыгарга ашыгабыз. Менә актыкќы өйләр. Шул чакта авыл уртасында ялкын күтәрелде. Күрәсең, гитлерчылар авылга ут төрттеләр. Ә безнең танклар һаман күренми. Аларны авыл башында ук сафтан чыгардылармы? Шулай уйлавыбыз да булды, кар тузаны туздырып килгән бер танкны да күрдек. Без, ура кычкырып, танкка каршы йөгердек. Танк, безнең турыга җиткәч, туктады. Аннары, кире борылып, без күрсәткән урынга — чиркәү янына китте.

Гитлерчыларның язмышы хәл ителгән иде инде. Без соңгы штурмга күтәрелдек. Ике ут арасында калган дошман озак каршылык күрсәтә алмады.

Дошман артиллериясе утыннан гариплэнеп беткэн урман аланында сакланып калган берничэ йортка минер-разведчиклар урнашкан иде. Мин, үзебезнең тора торган өйдән чыгып, өзлексез һөҗүм сугышларыннан соң бераз сәер тоелган тынлыкка колак салдым. Сугыш шау-шуына күнеккән күңел нәрсәдер көтә. Ләкин бер минут үтте, ике минут — тынлыкны бозучы юк. Мин елмаеп куйдым. Дошманның хәзер һөҗүм итәрлек җегәре юк, аңа позицияләрен саклап калу турында кайгыртырга кирәк, ә безнекеләр, Мәскәү янында фашист урдаларын тар-мар иткәч, барлык гаскәри частьларны китереп җиткерү, тылларны тарту, аралашу юлларын рәтләр өчен алгы частьларның һөҗүмнәрен берничә көнгә генә туктаттылар. Разведчикларга исә анда да ял юк, бу көннәр алдагы кайнар бәрелешләргә хәзерләнү белән үтте. Тик бүген генә өйрәнүләргә чыкмадык. Әмма бер кая да китмәскә куштылар.

Соңгы атнада көннәр болай да шактый салкын торды, төннәрен тагын да суытты. Кар шактый, хәтта ачык урыннарда да жил карны очырып бетерерлек түгел.

Артта ниләр барлыгын яхшы белмибез, чөнки артка атлаган юк, безгә алга гына юл ачык. Тылдан килүче сугышчылар күңелне күтәрә торган хәбәрләр әйтә: янәсе, арттан болыт кебек гаскәр килә, барлык урманнар, авыллар гаскәр белән тулы, барысы да тизрәк фронтка, дошман белән якалашырга ашкыналар. Юллардагы ватылган, җимерелгән, яндырылган дошман техникасын күргәч, күпләр баш кына селки. Шул ук вакытта яңа килүчеләрнең күзләрендә борчулы бер сорау бар: сугышта бик хәтәрме? Билгеле, моны ачыктан ачык сорарга батырчылык итмиләр, берәүнең дә куркак дигән хурлыклы исем аласы килми, ләкин сөйли башласаң, авызына ук керергә торалар. Без, күпне күргән сугышчылар, көлемсерибез генә. Беренче сугышлардан соң ук яшел йоннарыгыз очар әле, дибез.

Мин тәмәкемне тартып бетердем дә күршедә Мөнирләр урнашкан өйгә киттем. Кинәт шып туктыйм: Мөнирләр өеннән... матур, моңлы музыка ишетелә! Их, күптән инде музыка тыңлаганым юк минем. Шуңа күрә, исем китеп, бәс сарган агачларга карыйм. Бу музыка өй эченнән килми, әлеге шул бәс сарган ап-ак каеннардан чыга сыман. Мондый нечкә моңны моңарчы тыңлаганым да юк иде. Сугышка бит нечкә моңнар түгел, аңлашылмас какофония хас. Синең алдында бөтен нәрсә үкерә, ыңгыраша, бөтен нәрсәнең асты өскә килә, ишелә, убыла. Ә бу юлы каеннардан нечкә моң сибелә. Аннары тагын бер яңа нәрсә ачылды миңа: мин үземне күптән инде чын музыканы аңламас дәрәҗәдә чукракланганмын дип йөри идем. Баксаң, бик нык ялгышканмын икән: музыканы тыңлый да, тоя да алам әле. Тагын да гаҗәбрәге: мондый моңнар дөньяда яши икән. Минем өчен бу илаһи бер могҗиза иде. Күпме тырышып та, яндырып, җимереп тә гитлерчылар ул моңнарны юкка чыгара алмаганнар. Күр, ул ничек тантана итә, тынып калган урманга ничек җәелә, кояшка таба ничек сирпелә, яшәү дәртен ничек чала.

Мөнир соңгы көннәрдә бераз авырыбрак торды, ләкин медсанбатка барырга теләмәде. Хәзер дә әле тәмам терелеп беткәне юк, шуңа күрә аны заданиегә дә билгеләмәгәннәр. Хәзер мин аның хәлен белә килдем. Ни әйтсәң дә, без аның белән бала чактан дуслар бит, фронтта бу дуслык тагын да ныгыды, үсте.

Мин ишекне ачтым. Мөнир ике катлы сәкенең аскы катында кырын яткан да патефон уйната. Йөзе уйчан, агарган, суырылган. Өйдә артык беркем дә юк, өйрәнүләрдә булсалар кирәк. Мине күргәч, Мөнирнең йөзе яктырып китте.

— Алгы кырыйда шулай кәеф-сафа чигәрсең дип уйламаган идем. Ничек соң, терелеп буламы, дус кеше? — дип сорадым мин, тавышыма юри шаян төс биреп.

— Әйдүк, Абрек. Мин сине баядан бирле көтәм. Менә сез юлга хәзерләнәсез дип ишеттем, ә мин, ялкау Сарбай шикелле, йомшак түшәктә ятып калам,— диде ул елмаеп һәм әрнеп.

— Терел, аннары сиңа да эш житәрлек булыр. Каян бу музыканы таптың? — дидем, Мөнирне күңелсез уйлардан аерырга тырышып. Мин аны бик яхшы аңлыйм, үзем шундый хәлдә булсам, белмим, нишләр идем икән.— Моңы, малай, прямо йөрәкне чеметә.

— Белмим, синең йөрәгеңне уйнатырмы икән музыка, Абрек. Син таш күңелле ич.— Мөнир көлемсерәде.— Мин авыргач, иптәшләр каяндыр хозвзводтан табып китерделәр.

— Ә татарча пластинкалары юкмы? Нигәдер татарча бер жыр тыңлыйсы килеп китте.

— Әттә гензэм! — диде Мөнир, уң кашын сикертеп.— «Сандугач» искә төштеме әллә? Ә минем әле дә кайчак борын авыртып куя. Тәмам борып ташлый яздың бит ул чакны. Күрәсең, үзеннең дә йөрәгеңә шырпы нык кадалган булган. Югыйсә мин мескенне бераз гына жәлләгән булыр идең.

— Гафу ит,— дидем мин, елмаеп.— Кечтеки генә капшап алган идем югыйсә.

— Менә мин сине дә граната белән шулай кечтеки генә итеп капшап алыйм әле, аннары әйтерсең.— Мөнир уң кашын сикертеп, тагын ачусыз гына көлеп алды. Ул минем керүемә шат иде. Томанлы уйлары тарала төште.

— Соң ничек, сәлам хатлары килеп торамы үзеннән? Безгә бит хәзер шуннан артыгы эләкми инде.

— Килгәли,— дидем мин, канәгать икәнемне бер дә яшермичә. Хәер, моны яшерергә мөмкин дә түгелдер шикелле. Кычкырып тора.

— Син бәхетле шул, Малик. Ни әйтсәң дә, кызның асылын эләктерден. Ә мин менә, юләр, вакытында тапмадым.— Мөнирнең йөзенә тагын сагыш күләгәсе йөгерде.— Болай, син беләсең, кызлар белән дус идем, ләкин йөрәкне кульяулыкка төреп алып калганы булмады. Тагын син гаепле, мәкерле Абрек! Һаман шул мескен борын турында уйладым. Бер чибәр кызны «Швейцария»дә култыклап йөри башласам, караңгыда куаклар арасына тартып алып кереп, борын төпкә утыртырлар шикелле тоела иде. Шуннан гел як-якка карыйсың...

— Сакланганны ходай саклармын дигән. Ләкин бу турыда күп сөйләмә, югыйсә минер-разведчик икәнеңә ышанмый башларлар.

— Анысына кайгырмыйм, тик «сандугач» кына юк менә.

— Кайгырма, сиңа дигәне беркая да китмәс. Без сугышта йөргән арада менә дигәннәре үсәр әле.

— Үсүен үсәр дә, хәзергесе авыр, малай. Менә синнән Мөслимәне тартып ал әле, аннары сиңа нәрсә калыр? Күп нәрсә калмас бит. Минемчә, мондый сугышта кешене чын мәхәббәт кенә кеше итеп саклап алып кала ала. Күрдеңме, нинди фәлсәфүн булды абзаң? Сиңа гына фәлсәфәгә бирелергә димәгән шул. Ул фәнне без дә беләбез. Бигрәк тә авырып ятканда.

— Әйе, тирән сукалыйсың. Ләкин минем сорауга жавап бирмәдең бит. Татарча пластинкаң бармы, юкмы?

— Эчеңне тырныймы? Менә тыңла,— дип, Мөнир патефонны борды да яңа пластинка куйды. Бераздан атаклы «Сагыну» көенең нәфис моңнары агыла башлады. Сагыну! Сагынмыйбызмы соң! Бу көй бит йөрәкләрне актара, күңелләрне талый, бигрәк тә якыннардан аерылгач.

Бу пластинканы өч-дүрт тапкыр әйләндердек. Әйләндергән саен ниндидер яңа бер ягы ачыла кебек. Бу кадәр тирән ләззәтләнү белән

моңарчы бер җырны да тыңлаганым юк иде шикелле. Әллә каян, күкләрдән төшкән бәхет булды бу. Каядыр биеккә күтәрде кебек үземне!..

Шул чакта өйгә бер сугышчы ашыгып керде дә, миңа мөрәҗәгать итеп, карлыга төшкән тавыш белән:

— Гвардия өлкән сержанты, сезне хәзер үк командир чакыра! — диде.

Мин урынымнан тордым, Мөнир белән кочаклашып саубуллаштык, аннары, мине чакыра килгән сугышчы белән бергә өйдән чыгып, командир янына киттек. Ялгышмадым, задание бирергә чакырган иде.

Караңгы төшкәч, юлга чыгып киттек. Уналты кеше. Барыбыз да ак комбинезоннардан. Чаңгыда барабыз. Аркаларыбызда авыр капчыклар; танкларга һәм пехотага каршы кулланыла торган миналар, шартлаткычлар тутырылган. Йомшак кар өстеннән, куаклар арасыннан бер-бер артлы тезелеп дошман оборонасы ягына таба юл алабыз. Бурыч ачык: дошманның чигенү юлларын миналарга, күперләрен шартлатырга кирәк. Иртәнгә кадәр барысы да эшләнеп беткән булырга тиеш, чөнки нәкъ җидедә безнең һөҗүм башлана.

Алгы кырыйда траншеяда тыңлап тордык. Немецлар сирәк-сирәк автоматлардан аталар, ракеталар чөяләр. Болар барысы да бездән ундарак, ә сул якта — тып-тын. Һава шактый салкынайткан, күктә йолдызлар чекерәеп күренә, аяк астында кар шыгырдый. Безгә ярый, безнең кием җылы, ә фриц туңгандыр, аякларына чүпрәк, башларына иске шәл урап йөриләр бит алар. Бәлки, тәмам катмаганлыкларын белдерер өчен генә шулай ата торганнардыр. Әйдә, атсыннар. Без траншеялардан чыгабыз, чаңгыларга басабыз һәм кара төнгә кереп китәбез.

Бу җирләр азмы-күпме таныш диярлек, безнең инде монда разведка ясаганыбыз бар. Ун минут, егерме минут, утыз минут вакыт үтә. Дошман ягыннан ату тавышлары ишетелми. Тагын ярты сәгать үткәч кенә эчкә җылы керә. Димәк, дошманның алгы кырыен хәвеф-хәтәрсез үттек.

Кар сибәли башлады. Моңа бик шатландык, буран безнең эзләрне каплый. Аннары инде тап син разведчикларны!

Кайда пехотага каршы, кайда танкларга каршы миналар куеласы алдан чама белән билгеләнгән, шартлатасы күперләрнең кайда икәне дә безгә мәгълүм. Юл да тыныч, һичбер хәрәкәт юк. Кабаланмыйча гына пехотага каршы миналар куйдык, аннары, бераз китеп, бер тар рак җирдә танкларга каршы миналар куя башладык. Анысы да тыныч кына үтте. Хәзер безгә өч күперне шартлатырга кирәк. Икесе янәшә диярлек, берсенә шактый барасы бар. Якынрак күперләргә Панкратов җитәкчелегендә бер төркем минерны калдырдым, үзем ерагына киттем. Эшне бетергәч, урман авызында очрашырга булдык.

Яңа яуган кар өстеннән чаңгылар бик җиңел шуа. Әлбәттә, төн әле озын, ләкин вакытны әрәм итәсе килми. Алда ни буласын белеп булмый. Бүген болай барысы да уңай бара шикелле. Бер сәгать чамасы киткәч, ниһаять, күпер янына җиттек. Бу күпернең алдагы ике күпердән зуррак икәне, аны саклаулары безгә билгеле. Ләкин күзәтү монда сакчы фәлән булуын тапмады. Күпер өсте буп-буш. Нәрсә бу, сакчыларның салкыннан җылыга посуымы, әллә бер-бер хәйләме? Тагын бераз күзәткәч, берничә иптәшне яшерен сакка куеп, үзебез күпер астына төшеп киттек. Тын, андый-мондый шикле тавыш бер дә ишетелми кебек. Менә без күпер астында инде. Иләп кенә шартлаткычларны куябыз, запалларны тоташтырабыз. Күпер ярты сәгатьтән соң шартларга тиеш. Күпер астыннан чыккач, иркен сулыш алабыз. Ләкин бер нәрсә борчый: гитлерчылар кая киткәннәр? Дошман ул хәтле үк юләр булмаска тиеш, күпер хәтле күперне саксыз калдырмас.

Без урман кырыена туктыйбыз. Бик күп вакыт үтте шикелле, ә күпер шартламый. Бу ни хәл бу? Әллә ашыгу сәбәпле караңгыда берәр нәр-

сәне буташтырдыкмы? Мин төнлә дә яктырта торган сәгатемә карыйм. Әле биш минут вакыт бар икән.

Моннан күпер чак-чак кына шәйләнә. Анда һаман тыныч.

— Гвардия өлкән сержанты, кара! — дип пышылдый бер разведчик шул чакта.— Сакчы бугай.

Хәзер мин дә ачык шәйлим. Әнә ул күпергә ашыкмый гына якынлаша. Безнең эзләрне генә күрмәсен. Житмәсә, буран да туктады.

Һәм кинәт, тирә-якны янгыратып, күпер шартлады. Без күккә сикергән ялкынга бераз карап тордык та бер-беребезне кочарга, үбәргә, тәбрикләргә тотындык. Аннары кузгалдык. Хәзер капчыклар юк инде, кош кебек очабыз. Күңел күтәренке, кычкырып җырлыйсы килә. Урман үзе дә җырлый кебек. Җыры бик таныш сыман. Чү, бу «Сагыну» ич! Елмаеп күз алдына Мөслимә килә. Миңа тагын да рәхәт булып китә. Шулай рәхәт кичереп, иптәшләр янына да килеп җитәбез. Алар шартлау тавышын ишеткәннәр, безне тәбрикләргә тотыналар, ә мин:

— Ә сездә эшләр ничек? — дип сорыйм. Җавап урынына бер-бер артлы ике шартлау ишетелә. Барысы да ачык. Мин иптәшләрнең кулларын кысам.

Тагын кар сибәли башлады. Һава да бераз җылынып китте кебек. Әллә кызу килгәнгә шулай тоеламы икән?

Күңел тынычлана барды. Ләкин разведкага кайдан, ничек куркыныч янавын белеп дә алдан белми шул. Үзәнлек буйлап барганда безгә кинәт ут ачтылар. Үзәнлекнең көнбатыш битендә ниндидер бер кечкенә авыл күренә. Анда да гитлерчылар тревога күтәрделәр, тәртипсез атышлар башланды. Безне урап алдылар. Башка чара булмагач, түгәрәк оборона корып, без дә дошманга ут ачтык. Мин көчләрнең тигез түгеллеген күрдем. Ләкин иртә белән безнең частьлар һөҗүмгә күчәргә тиеш. Берничә сәгать тора алсак, шул җитә.

Ак кар өстендә гитлерчылар ап-ачык күренә. Алар берничә йөз кеше, без уналты! Калтырап төштекме? Юк! Ярты сәгать эчендә егерме-утыз дошманны кырып салдык. Ләкин гитлерчылар, үзләренең өстенлекләрен сизеп, безне терелә́й алмакчылар бугай. Юк, алмый торыгыз әле! Панкратов аларның шактый якынлашып килгән төркеменә гранаталар томыра башлады, мин автоматтан чүплим. Башка иптәшләр дә тик ятмыйлар.

Булмады, мине яраладылар. Актык минутта мин Панкратовның тезмә буенча команда бирүен ишеттем: ул минем яраланганымны әйтте, булдыра алган яралыларга үзәнлек буенча түбән таба шуышырга кушты. Шуннан соң ни булганын, сугыш күпме дәвам иткәнен белмим.

Аңыма килгәндә мин ниндидер авыл өендә идәндә ята идем. Күрәсең, инде таң атып килә, тәрәзә пыялалары зәңгәрләнгән. Янымда — Панкратов. Башта кем икәнен белмәдем, бары тик соңыннан, тавышын ишеткәч кенә таныдым. Өстәлдә керосин лампасы. Ләкин без үзебез кайда — анысын рәтләп төшенмим. Әле аңым ачыклана, әле тагын караңгы упкынга очып, онытылам.

— Гут, гут,— диде немец офицеры, минем өстемә иелеп.— Без сезнең нәрсә эшләп йөрүегезне беләбез... Совет гаскәрләре кайчан һөҗүм итә башлый? Безнең алга тагын нинди частьлар килде?

Мин дәшмәдем. Өстәлдә әллә нинди шешәләр тора. Күрәсең, мине аңга китерер өчен күп тырышканнар. Панкратовны да бик күп газаплаган булсалар кирәк, ыңгырашуы авыр.

— Иптәшегез барысын да сөйләде,— диде гитлерчы йомшак тавыш белән.— Сез аның әйткәннәрен расларга телисезме? Үйлагыз, исән калырга теләсәгез, барысын да сөйләгез.

— Без илебезне сатмыйбыз,— диде кинәт Панкратов.

— Нәрсә, нәрсә әйттегез? — гитлерчы идәндә яткан Панкратовка иелде.

Панкратов артык дәшмәде, ул тагын аңын югалткан иде бугай. Ләкин мин шул кадәресенә дә шатландым. Панкратов дошманга бер нәрсә дә әйтмәгән! Мин аңардан башканы көтмәгән дә идем.

— Без илебезгә турылыклы! — дидем мин дә.

Мин уйлыйм, Панкратов моны чиксез авыр хәлендә дә ишеткәндер, аңлагандыр дип. Ул кыймылдап куйгандай булды.

— Руслар кайчан һөҗүм итә башлыйлар, сәгате? Я, тиз бул?

Гитлерчының бу соравын мин кайдандыр, кара томан эченнән генә ишеттем. Мин аңа җавап бирмәдем. Мине кызган шомпол белән җәзалый башладылар. Үзләре һаман җикеренәләр, кычкырыналар, сүгенәләр. Аңым җуяр минутта минем колагыма «Сагыну» моны ишетелде, күз алдыма Мөслимә килеп басты. Аның йөзе хәсрәтле. Мин аны юатыр өчен нидер әйтә башлаган идем, күз алларым караңгыланып китте, тәнемне тагын кызган шомпол белән көйдереп алдылар.

Гитлерчы үзенең соравын кабатлады, алар ашыгалар иде булса кирәк. Һаман-һаман сәгатьләренә карыйлар. Карагыз, кара, кабахәтләр, актык сәгатьләрегез җитә.

Панкратов тәмам тынды.

— Әйтәсезме, юкмы? Югыйсә утка ташлыйбыз! — дип чыелдады фашист.

Җәзалап та, кыйнап та сөйләтә алмагач, безне тышка сөйрәп чыгардылар. Монда зур учак яна иде.

— Я, соңгы мәртәбә сорыйбыз...

Мин эндәшмәдем. Мин тагын Мөслимә белән идем. «Бәгырем Малик, мин сиңа ышанам»! диде ул. Әйе, әйе, ышан, Мөслимә! Мин алдамам, мин илемә турылыклы булып калырмын!

Мин шыпырт кына гитлерчыны дәшеп алдым.

— Миңа сөйләве авыр, иелә төшегез, әйтәм,— дидем.

Фашист тиз генә минем өстемә иелде. Мин аның кабахәт йөзенә лачт итеп төкердем дә:

— Эт! — дидем.

Гитлерчы ачуыннан шартларга житте, пистолетын суырып алды да миңа таба атып җибәрде. Ләкин мин һаман үлмәгән идем әле. Еракта безнең артиллерия үкерә башлавын ишеттем. Аның гөрелтесе тоташ бер тантанага әверелде. Гитлерчылар барысын да аңладылар булса кирәк, ашыгыч команда булды. Безне, ике совет кешесен, ялкыны күккә сикереп торган зур учакка ташладылар...

Без инде Мәскәү янындагы тиңдәшсез һөҗүмнең калган өлешен дә, миналанган җирләрдә гитлерчыларның солдатлары, танклары, автомашиналары шартлавын да, безнең бер яралы разведчикны күрше часть солдатлары очратуын да, без сугышкан җирдә дошманның иллеләп үле гәүдәсе ятып калуын да, безнең янган гәүдәләр янында комиссарның башын иеп басып торуын да, ниһаять, безнең батыр гаскәрләрнең фашизмның оясы Берлинны штурмлавын да күрмәдек. Без инде үлемсезлеккә атлаган идек.

Үтәр еллар, бик күп еллар үтәрләр, җирдә бөтен халыкларның тантанасы — коммунизм яшәр, ә без һаман унтугызда булырбыз. Без азат халыкларның яңа яшьлеген, туганлыгын, дуслыгын котларбыз. Бик күп буыннар безнең мәңгелек һәйкәлләргә карап:

— Алар фашизмга каршы көрәштә гомерләрен кызганмаганнар, алар халыкларны коллыктан коткарганнар,— диярләр.

Безгә башка дан кирәкми.

1968 ел, июнь.

## Рәшит Әхмәтҗанов

# Бәйрәм

Без мәңгегә, без мәңгегә монда!
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәребезнең
Кыңгыраулар таккан атлары.
Чәчте-урды халкым,
Горур булды,
Үз язмышын ятка бирмәде.
Кешеләрнең бүген туган җирдән
Үлемсезлек алган көннәре.
Алар күргән авыр кайгыларны
Онытырмын димә тиз генә.
...Килгән дошман халкым сөягеннән
Һәйкәл куяр өчен үзенә.
Мин туганмын җиргә шул елларда,
Озак яшәремне ил белгән.
Мин туганмын,
Илем дошманнары
Нәкъ мин туган җиргә күмелгән.
Рәхмәт, илем!
Гомер биргәнсең син,
Йөрәк янган: сүнми, югалмый.
Туган җирдә дошман каберләре...
Каберләрдән ирләр үч алмый.
Шундыйларны,
Шундый кешеләрне
Дошман яуда җиңәлмыйни!
Шундый кешеләрнең нәфрәтләре —
Аны ерак җибәрмәмени!
Без мәңгегә, без мәңгегә монда!
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәребезнең
Кыңгыраулар таккан атлары.

1966

●

Ташлар белән үтә танышлык бар,
Мин аларга күптән бирелдем.
Күп шакыдым ташка,
Дөньяга мин
Ниндилеген әйтеп хәлемнең.

Ташлар ярып чыга агым сулар,
Ташны ярып үсә имәннәр.
Башны ташка бәреп,
Ташны күптән
Бабаларым вата белгәннәр.

Ташлар белән үтә танышлык бар,
Берәүләрнең карап күзенә,
Сөйлим әле ташлар ярып тапкан
Дөреслекне салып сүземә:

Туган туфрак яшәү көче миңа,
Һәр граммы яшәү запасы.
Таулар биек диеп уфтанганның
Килми микән ташларватасы!!

Иңнәремдә үзем тоеп белəм —
Көчле итә ирне туган җир.
Әй, җир, синнән үлем сорасалар,
Кешеләргә үлемсезлек бир!

1967

## Рәхимҗан күпере

Күпме еллар узган,
Ишелеп төшкән,
Субайпары тора су ярып,
Шикләндерә,
Яңа күпер салсаң —
Ташкын җимерер төсле кузгалып.
Онытылмый, өзек урыннарны
Ялгый-ялгый узган гомерләр.
Авыр еллар авырлыгын озак
Күтәрәлми икән күперләр.

...Халык сөйли һаман.
Сукыраеп,
Сугышларда янып яртылаш,
Таягына таянып кайтып кергән,
Изүләре ачык... яланбаш.
Шул Рәхимҗан танып туган якны,
Бер елаган җиргә егылып.
Йөрәк сау бит,
Бары күзләр генә,
Күзләр генә калган йомылып.
Авыл йөгереп арыш басуыннан
Күрергә дип килгән баласын.

...Ярсу елга күперенә җиткәч,
Туктаган ул... кемнәр аңласын!!.
Хатлар аша аңа җиткергәннәр
Бу күперне Айдар салганын.
Шул күпер бу...
Суга сала алмас —
Җанындадыр пычрак ялганы.

Дошман чолгаган дә өч батырны,
Айдар артка качкан куркудан...

— Сукыр килеш тә мин атламамын
Хыянәтче белән бер юлдан,
Һәм сикергән суга,
Йөзеп киткән,
Агып киткән... халык өлгергән.
Суга акса аккан,
Юк, кичмәгән
Хыянәтче салган күпердән.
Шул көннән соң халык йөрмәгән, ди, —
Ул күперне халык җимергән.

Рәхимҗаннар яңа күпер салган
Субайларын кагып тимердән.
Күпме еллар узган.
Ишелеп төшкән,
Субайлары тора су ярып.

Халык бүген яңа күпер сала,
Рәхимҗанын үзенең искә алып.
Онытылмый,
Өзек урыннарны
Ялгый-ялгый узган гомерләр.
Авыр еллар авырлыгын озак
Күтәрәлми икән күперләр.

1967.

●

Абыем Камил истәлегенә

Сөрелгән җир кап-кара,
Җир өстендә ап-ак ат...
Шулай төштең исемә
И, малкаем, ничә кат.

Агым, минем ап-агым,
Бергә сөрдек басулар.
Чапсак җилне узарлык,
Икебез дә ярсулар.

Чабып кайттык без шулай
Киң басудан авылга,
Икебез дә еладык,
Авыр хәбәр алуга.

Абый үлгән сугышта.
Әйди безне нәфрәтләр.
Ашаган-эчкәнебез
Күз яшә дә хәсрәтләр.

Синең ап-ак тесеңне
Бәхетем дия башладым.
Кара итеп кырларны
Кайгы сөрә башладым.

...Җиңү көткән елларның
Күзге кара төнендә,
Тагын икәү еладык,
Кайгың авыр синең дә.

Матур иде... ак иде...
Йөрегәндә тышаудан,
Кыр юлында ач бүре
Колыныңны ашаган.

Сөрелгән җир кап-кара,
Җир өстендә ап-ак ат.
Шулай төштең исемә
И, малкаем, ничә кат.

1968.

●

Сөюем борчый җанымны,
Чыңлый, кыңгырау кага.
Җиремне күзлим...
Мин түгәм
Күз нурымны дөньяга.

Гелләргә ява чиләкләп
Җәемнең яңгырлары.
Яшен ташларын күзләдем,
Эзләдем — табылмады.

Әйтсен, кем күбрәк бүген
Нур җыйган күңеленә,
Ике якта яр булырбыз
Салават күперенә.

Сөюем борчый җанымны,
Тагын кыңгырау кага.
Әйтергә оялып торам
Хәсрәтемне дөньяга.

Минем юлдашым шикелле
Әйләнә җир, әйләнә.
Сездермичә генә шаян
Язмышыма бәйләнә.

Кара төннәрдә югалтсам
Әгәр шул юлдашымны,
Ал миннән, тартып ал, язмыш,
Таң аткач Кояшымны.

1965.

●

Сорыйсың: — Я, туган, исәнме,
Хәлләрең ничек соң, бер сөйлә!
— Яшәве күңелле һәм авыр,
Бу тормыш тоташтан зилзәлә.

Яратам дөньяны.
Җир бирде
Үземә карамны, агымны.
Дөньядан яшереп кайчакта
Сагынам гөнаһсыз чагымны.

Җиремдә каеннар — ак бишек,
Кошларның баласы ояда.
Чәчәкле көннәрем китмәгән,
Әйтерсең китәргә ояла.

Агыла болытлар күгемдә,
Китә күк җанның бер кисәге.
Йөрәкнең мәңгегә югалмый,
Бу җирдә яшәргә исәбе.

Йөрәккә кагыла салкын сүз,
Җылы кул, салкын таш, җылы җил.
Барысы да тарала, югала —
Кала тик туган ил, туган җир.

1967.

●

Бер кычкырдым бөркет канатының
Курайлары калган кыядан.
Кайтаваздан куркып яшь кошчыклар
Күтәрелде күккә оядан.

Күз талганчы карап озатып калдым,
Биштәремне җиргә куйдым да.
Йөрәккәем ташка уелса да,
Юк, куркыныч түгел бу дөнья.

1968.

●

Таш өстендә гөлләр...
Гөл өстенә
Соңгы йотым суны коясың.
Һәм, актарып ташны, таш астыннан
Тапканым бар елан оясын.

1968.

## Фатих Хөсни

# ПОП КЫЗЫ ӘХСӘНӘ

хикәя

### I



Моннан күпмедер еллар элек, Мәскәүдә татар әдәбияты атналыгы уздырып йөргәндә, мондыйрак бер хәл булды: завод клубында очрашуда катнашып, кичен соң гына гостиницага кайтсам, этаж дежурные миңа пакет китереп тоттырды. Зәңгәр конвертка тигез пөхтә хәрефләр белән исем-фамилиям язылган һәм артык бер сүз дә юк иде. Әлбәттә, беркадәр аптырабрак калдым, конвертны ачмыйча, почеркыннан, кемнеке булса да берәр таныш кул түгелме, дип, чамаларга тырышып карадым. Шул арада күңел дигәнең әллә ниләр уйлап та бетерде, янәсе, берәр соңга калган романтика түгелме? Көнбатыш беллетристикасында кайбер хәл-әхвәлләр шулай башланып китә ич.

Алай булмады. Конверт эченнән чыккан кечерәк кенә язуда Ишмаев фамилияле бер мәскәүле, һич белмәгән, ишетмәгән адәм, ничек тә булса бер мөмкинлек табып, иртәгә кичкә үзләренә кунакка килеп чыгуымны үтенгән, бик ачык итеп, хәтта нинди транспорт белән килергә, кайсы тукталышта төшәргә икәнлеген дә әйтеп, адресын күрсәткән. Болар белән генә чикләнмичә, аска, «постскриптум» аша түбәндәге сүзләрне дә өстәп куйган иде: «Бу, конечно, беркадәр церемониясызрак килеп чыга, чөнки Сез мине белмисез. Ләкин мин Сезне беләм. Кайбер язганнарыгызны да укыганым бар. Бигрәк тә шунысын беләм: без сезнең белән якташ, мин укыган биографиягызга караганда, без күрше авыллар ук, вообщем, бер сөйләшеп утырырга иде исәп.

**Г. И.».**

Конверт эчендәге язу конверт тышындагы кебек нык кул белән язылмаган, хәрефләр авыш-тәвешрәк, арада латин хәрефләре дә кысылган, урынлы-урынсыз кергән рус сүзләре дә бар, күренеп тора: иптәш ничек тә татарча «сукаларга» тырышкан, булдыра алган чаклы «сукалаган», аннары тагын шунысы да күренеп тора: «күрше авыл» дигәне бик үк яшь кеше булмаса кирәк. Кыскасы, юкка иләсләнмә, күңел, алда сине бернинди романтика да көтми, көтсә тик бер-ике стакан чәй һәм чәй янында берсен башлап, икенчесен ташлап, авыл хәлләрен сорашырга җыенучы склерозлы карт көтә булыр. Дөресен әйтим, бер мәлгә мин аптырабрак та калдым: чөнки авылда, туган якларда үземнең дә күптән булганым юк, көткәнен бирә алырмынмы икән ул якташымның?

Ничек кенә булмасын, икенче көнне кичкә таба, чакырылган вакытка чамалап, киттем. Кызык бит ул тормыш дигәнең: мине, билгесез бер

очыну белән, иләсләнеп көткәнем дә түгел, шул ук вакытта мин ясаган проза дип тә әйтмәс идем, әгәр әйтергә яраса, шуларның ике арасы, бик ук куккә дә чөймәслек, әмма тыныч кына калдырып та булмый торган бер кич каршы алды. Кыскасы, уникe катлы шөкәтсез зур өйнең дүртенче катындагы өч бүлмәле, хәзерге заман мебеле белән җиһазланган, ләкин әйбер басмаган, иркен һавалы чиста квартирада мәһабәт зур гәүдәле, чал чәчле, килгән кунагыннан — ягъни миннән, бер ярым озын, шуннан ничектер уңайсызланган кебек, бөкрәя төшебрәк йөрүче һәм өйне тутырып яңгыратучы калын тавышлы өлкән ир һәм шулай ук олы яшьләрдәге, ләкин мөлаемлыгы һәм безнең якныкы икәнлеге әллә кайдан кычкырып торган сөйкемле ханым каршылады мине.

Ни хикмәттер — хәзергә кадәр һич шуны үземә аңлата алганым юк — бусаганы атлау, кул биреп күрешү белән үк диярлек, безнең арада ничектер бик якын, һич тартынусыз, әллә кайчангы танышларча самими мөнәсәбәт урнашып калды.

— «Килә» дип әйттем бит, Әхсәнә Герасимовна, как же килмәсен. Карт башым белән үзем барып чакырыйм да, имештер, килми калсын,— дип, өйне тутырып, бер гөрләп куйды Гаптелмөлек агай. (Ишмаев карт, исемен шулай әйтеп, үзе белән таныштырып өлгергән иде инде.)

— Тукта, чү... Син үзеңнең карт башыңа артык йөк аласың түгелме, этисе? — Ханым әдәпле генә итеп иренен җиңенә кагылып куйды.— Бераз гына кунакка да калдыр сүзне.

Ләкин агайны тыеп торырлык түгел, ул, хатынының кисәтүенә әллә ни игътибар итмәстән, гөрли бирде:

— Кунакка да җитәр, үзебез дә авыз йомып утырмабыз, кич безнеке, Әхсәнә Герасимовна, — диде ул, үзенекен дөресләп. Шундук уйныйкөлә өстәп тә куйды.— Син, әнисе, ишекне ике бигенә дә бикләп куй. Хуҗалардан команда булмыйча, бу кадерле кунагыбыз бездән качып китәргә уйламасын.

Ханым бу юлы миңа карап бер елмаеп кына куйды. «Менә шундый кеше инде ул минем карт җүләрем, нишләтәсең аны, табигате шулай булгач», дигән кебек иде аның бу карашы. Һәм шунда чак кына ачылган авызыннан ап-ак булып тешләре күренеп калды. Үзе олы яшьләрдә булуга карамастан, — ни хикмәттер — аның саф үз тешләре шулай сакланып калган иде. Килеп, әле рәтләп сүз дә ялганып китә алганы юк, бу сөйкемле ханым мине, менә икенче мәртәбә инде, эчемнән генә аптырап калырга мәҗбүр итте: беренчедән, танышу ыгы-зыгысында ук игътибар иттем: ничек аңларга бу «Әхсәнә Герасимовна» дип эндәшүне? Исеме саф татарныкы һәм бик борынгы исем. Әтисенең исеме саф русныкы, шулай ук бик табигый, шәп яңгырый. Икенчедән, ничек бу кадәр саф килеш сакланган аның ул тешләре? Шул хәтле гомер кичереп, бер дә тешкә тия торган борчу күрмәдеме икәнни?

Бу сорауларны бирергә, әлбәттә, әлегә иртәрәк, без әле танышып кына торабыз. Хәтта тормыйбыз да, Әхсәнә Герасимовна өстәл әзерләгән арада, Гаптелмөлек агай мине, картларча күп сөйли-сөйли, бүлмәләре, бай гына китапханәләре, стенадагы портретлары буенча балалары белән таныштыра йөрде, үзе юк-юкта бер үк сүзләрне тәкърарлап: «Борыны бозга катып үскән малайлар Мәскәү үзәгендә менә шулай торабыз инде!» дип мактанып та куйгалый иде. Дөресен әйтим, бу танышу сәгатьләрендә мин аның бөтен сүзләреннән, кыланышларыннан, хатыны ишетмәсен өчен кайбер сүзләрне тавышын кысып, пышылдап кына әйтүләреннән һәм алай пышылдаган чакларында, сул күзен муттларча кысып, нәрсәгәдер ымлауларыннан, барыннан да элек, үз тормышыннан бик тә канәгать икәнлеген, хатыны ишетмәгәндә генә борчак сибәргә дә яратканлыгын, гомумән алганда, олы яшькә җиткәнче гел сабый күңелле, үен-көлкеле, әгәр форсат чыкса, ирен чылатып алудан да бер дә качмый торган бер адәм икәнлеген чамалап алдым. Кем бел-

гән, бәлки мине дә ул якташ итеп кенә түгел, каләм кыштырдатучы адәм алдында бер мактанып аласы килүдән һәм шул унайдан ирен чылатырга сылтау булсын дип чакыргандыр. Хәер, бу чаклысы мин уйлап чыгарган юрау гына, алай түгел икән, гөнаһысын үз өстемә алам.

Бер караганда, мактанырлыгы да бар икән шул Гаптелмөлек агайның. Төрле зат-зат нигъмәтләр белән тулы түгәрәк табын янында, анңары тагы әллә нидә бер әрмән коньягы белән иреннәрне чылаткалап, озак кына сөйләшеп утыра торгач, мин агаемның зур гына тормыш күргән, башыннан күпне кичергән хөрмәткә лаек бер кеше икәнлеген белеп алдым. Соңгы егерме еллап гомерен ул Мәскәүнең Кожкомбинатында техник-сортировщик булып эшләгән, шуннан пенсиягә киткән, бигрәк тә һәм кайта-кайта ул минем игътибарымны бер нәрсәгә юнәлтергә тырышты: «Балалар без картлардан уздырды, брат — берсе әнә чит телләр буенча китте, белмәгән теле юк, тегеннән-моннан кунак килсә, машина җибәреп, чакыртып алалар, кунак үз телендә сөйли, ә бу, минем кыз, панимаешь, кунакның әйткән сүзләрен үзебезнең русчага әйләндереп, безнең хуҗаларга җиткезеп тора. Ә малайга килсәк, аңысы икенче юл белән китте: архитектор. Йортлар салдыра. Мәскәүдәге иң шәп йортлар — барысы да минем малай салдырган йортлар».

Карт үзенең арттырыбрак җибәргәнен үзе дә сизә, мин аның сизгәнлеген күзләреннән үк күреп торам, хәйләкәр ут яна күзләрендә. «Син ышансаң ышан, ышанмасаң ышанма, анда минем эшем юк, ә мин барыбер сөйлим. Ник дисәң, минекеләр бит алар, мин үстергән балалар. Миңа алар турында сөйләү рәхәт», дигән төсле аның күзләре. Дөресен әйткәндә, бу чаклысын ул табыннан хатыны китеп торган араларда гына сөйли, хатыны алдында бик алай тугарылмый иде. Утыра торгач, мин тагын шул чаклысын да төшендем: зур тормыш юлы үткән, балалар үстергән, нужасын да, рәхәтен дә күп күргән, тулаем алганда, ничек бар — шулай күренә, ясалуны белми торган, чак кына хәйләкәр, чак кына борчак сибәргә яратучы бу зур гәүдәле, калын тавышлы мәһабәт кеше, минем якташ — сәер хәлләр тулып ята ич бу дөньяда, — әнә шул юаш кына хатыннан чак-чак кына өркә дә иде булса кирәк.

Үзе шулай сөйләшергә ярата торган самими кеше күренгәч, шуның өстенә якташ та булгач, шуның өстенә тагын, бик ештан булмаса да, иреннәрне дә «чылаткалый» торгач, минем дә тел чишелеп китте булса кирәк, табында икебез генә калган бер форсаттан файдаланып, мин агайга турыдан-туры сорау куйдым:

— Моңа хәтле сөйләгәннәрегез барысы да шулайдыр, якташ, килешәм. Мәскәүдәге иң шәп йортлар сезнең улыгыз салдырган йортлардыр, ул чаклысына да каршылыгым юк, — дип башладым мин сүзне, җор картның үз җаена ята төшебрәк, — но шулай да минем бер аңлап җитмәгән нәрсәм бар, Гаптелмөлек агай, нәрсә дигән сүз ул «Әхсәнә Герасимовна»? Исеме татарныкы, әтисенең исеме русныкы? Ничек аңларга моны?

Сорауны мин икебез генә калган чакта, шыпырт кына куйган идем, ә менә Гаптелмөлек агай, мине оятлы итеп, моны хатыны алдында селкергә булды.

— Әй, Әхсәнә Герасимовна, кил әле монда, — дип хатынын чакырып китерде ул, кәефле шаулап. — Син нинди киңәш бирәсең, әнисе, бу кунак безнең бик төпченүчән булып чыкты. Кабыргасы белән китереп куйды мәсьәләне: ни өчен Әхсәнә дә, кайдан килеп Герасимовна, ди. Сөйләргәме, юкмы?

— Мин кайдан белим, синң куйганнар сорауны, син җавап бирергә тиеш, — диде хатыны, гадәтенчә тыйнак кына елмаеп. Һәм соңыннан картның хәлен тагын да җиңеләйтергә тырышкан кебек, әлеге саутаза тешләрен балкытып, көлеп үк куйды: — Язучы кешене өйгә керт-

сәң, шул буласын мин алдан ук белеп тордым. Менә хәзер хикәя итеп язып чыгарса, чыдап тор инде.

Бу шул, Гаптелмөлек агай белән мин көткән сүз, «үзеңә кара, минем каршылыгым юк» дигән сүз иде инде.

— Әй, язып чыгарса тагы,— дип, кулын гына селтәде агаем,— эшләргә курыкмаганны язудан курыкканым бар иде, ди. Яза бирсен кәгазе тетсә.

Һәм ул, ниндидер кодрәт буенча янадан яшьлегенә әйләнеп кайткандай, жанланып, авыз читләре белән генә көлемсерәп, сүз арасында анда-санда борчак та сипкәли-сипкәли һәм борчак сипкәнен әллә ни яшереп тә тормыйча, кыскасы, бик тә хозурланып, башларыннан узган кызыклы бер тарихны сөйләргә кереште.

## II

— Безнең Ямбулат белән Теләче арасын үзегез беләсез, жил шул яктанрак иссә, Теләчедә каккан чиркәү кыңгыравы безнең колакта була торган ие, — дип башлап китте ул, бераз шаяртткандай итеп, — мин үзем, туры килгәндә, дуңгыз итен дә артка куя торган кеше түгел, ул якка, аллага шөкер, яшь чактан ук батыр булдым, ә фактически алып әйткәндә, эш дуңгыз итенә генә терәлеп калмады, поп кызына ук барып жителде. Болай өстән-өстән сөйләү белән генә котылып булмас, шул бер рәттән яшь чакларны да искә төшереп, баштанаяк түгеп салыйм әле.

...Егерме беренче елгы ачлыкны хәтерли торгансыздыр, безнең якларда күп кенә кешеләрнең башына житкән хәтәр елларны... Хәер, мин үзем ачлыкка койрыкны тоттырмадым. Бура төбенең күздән ук такырая баруын, кышның яман киләсен алдан ук сизеп, аннан-моннан гына әти-әнинең фатихасын алдым да Донбасс якларына сыздым. Дуңгыз итеннән качуын качмыйм да, шулай да читкә киткәндә олыларның фатихасын алмыйча ярамый ич.

Донбасста ниләр булганны сөйләп тормыйм, буласы булгандыр — мәсьәлә анда түгел, мәсьәлә менә монда: бер кыш, бер жәй, аннары фасон өчен тагын бер кыш эшләп, өсне-башны бөтәйткәч, кесәгә әтәч булып кычкыра торган акча да кергәч, чатылдатып урысчасын такылдый башлагач, кайтып, авылдашларны бер шаккатырырга булдым. Шундый бит ул безнең Ямбулат токымы, син аңа ашарына бирмә, син аңа мактанырга бир. Кесәсендә мәшрикъ жиле белән мәгърип жиле икесе бергә уйнаса уйнар, шулай да серне сынатмас, түше киеренке, сүзе бөереннән чыгар. Ә минем кесәдә ул чак, әйтеп узганымча, бераз гына теге... Алдан йөгерә торган да бар, жанга тынгы бирми торган акча, икенче төрле әйткәндә.

Шулай итеп шул, кайттым әйләнеп туган якларга. Әмма ачлык ел безнең Ямбулат кешеләрен дә яхшы ук сыккан, кырларның яртысы чәчелми калган, мал-туарны суеп ашап бетергәннәр, ишек алдында алабута урманы үсеп утыра. Әти белән әни ничек кирәк алай жан саклап калганнар, ә Гаптелхәй энекәш өйдә башук күренми. Бактын исә, нужа — кара сакал аны да йорттан сөреп чыгарган, имеш. Теләче побына барып, батраклыкка ялланган бу. Тамагы шунда үтә, өстен-башын карый, өстәвенә тагын ялманырлык кына булса да өйгә — карт белән карчыкка да тамгалап тора икән. Гаптелхәйнең бу эшенә кул куйдым, өйдә куырылып ятканчы, картлар әйтмешли, хәрәкәттә — бәрәкәт. Ул агы шулаен шулай да, бик үк бәрәкәт булып житмәгән почмагы да бар, имеш. Моны миңа башта авылдашлардан ишетергә туры килгән иде, бер дә бер көнне, өйдә икебез генә калган форсаттан файдаланып, әни тиште.

— Кара әле, Гаптелмөлек, синең колагына кердеме? Чынмы икән, ялганмы икән шул сүз? — дип, бик тә шөбһә сала торган итеп башлады әни, шыпырт кына. Аннары тавышын тагын да кыса төшеп, үз сүзләреннән үзе өреккәндәй, ялгап алып китте: — Абый кешесе, синнән яшерә алмас. Яшерсә, бугазыннан буып әйттер: дошман көнчелеге аркасында чыгарылган сүз булмаса әгәр... Теге дивана безнең, шул Гаптелхәй гөнаһ-шомлыгын әйтәм, поп кызына өйләнәм, шуннан башка миңа тормыш юк, әгәр болай бирмәсәләр, чукынам, татар дененнән баш тартам, дип әйтәдер, ди.

Әни артык дәвам итә алмады, аңарга, мескен карчыкка, шул кадәресе дә бик житкән, моннан да арысын уйларга да, күз алдына китерергә дә курка иде булса кирәк.

— Әй, кеше сүзен сөйләгән булмасана, — дидем мин, әнине тынычландырырга тырышып. Ә үземнең — дөресен әйтим — таш бик кызган, унбиш-уналты яшьлек малайны алай тилертә ала торган ул кызны күз кырыем белән генә булса да бер күреп карыйсым килә. «Бәлки, минем хакым зуррактыр да, — дип уйлап куйдым эчемнән генә. — Яшем егермегә житкән, дуңгыз ите ашарга дисәң, ике дә уйлап тормыйм, кесәдә өйгә бушатканнан соң калган акча да бар, өс-баш та кеше күзе төшмәстәй түгел, ялтыр кунычлы күн итегем үзе генә дә ни тора! Пинжакның түш кесәсендә — кирәк булса, булмаса, фасон өчен дип тыккан — чалма башлы карандаш, поп кызы белән генә сөйләшерлек русчасын да беләм, ә иң кыздырганы тагын шул: үз күзләрем белән күрәсем килә шул кеше аздыручы чукынмыш кызны».

Ул арада авылда сүзләр куерганнан-куерып китте, кайберәүләр узган елгы корылыкларны искә төшерә башладылар: янәсе, тирә-юнендә шундый-шундый шомлыклар котырып торганда, яхшыдан яман туган балалар, бер нәфесләрен тыя алмыйча, маржа итәгенә тагылып, деннәрен сатарга йөрсәләр, — алла сакласын, — илгә әллә ниткән афәтләр килүе бар һәм башка, һәм башка шундый өркетүләр. Бу сүзләргә төкереп тә бирмәгән булыр идем, бер көнне әни тагын күз яше белән битен юарга тотынды:

— Бар, ил-су арасында рисвай итмә башымны, якасыннан борып, өстерәп алып кайт шул сөйрәлчек малайны,— дип, кабыргасы белән куйды мәсьәләне.

Әнисе сүзеннән тыр-тыр йөгерде бу, дип уйламагыз, үземнең бик күрәсе килә бит теге шомлыкны. Шулай итеп, бер көнне киттем мин Теләче якларына. Аякта әлеге шул ялтыр кунычлы итек, пинжак кесәсенә — тартсам, тартмасам — папирос алып тыктым, эчке кесәдә өйдәгеләрдән яшереп алып калган акча, башка чәпәп куйган хәтфә кәләпүшне авылны чыгу белән, баштан йолкып алып, йомарлап, чалбар кесәсенә борып тыктым, житү чәчле башны куйдым жил иркенә... Кыскасы, барам шулай жилфердәп. Чәчне туздыруым, бер яктан, юлдан язган энекәшне өркетү өчен булса, икенче яктан, алла сакласын, күңелнең кайсыдыр бер почмагында качып утыручы шайтан малае котыртып бара: бик алай кырган баш булып калтырап торма поп кызы алдында, ул шәп икән, син дә йоннан төргән гөнжәлә түгел, ди.

Барып життем. Попныкы попча, малай, йорт-жир кала корган кебек, капка-койма чыпчык та үтеп кермәле түгел. Ә мин кердем, миңа — Донбасс якларыннан шомарып кайткан яшен ташына — капка капка була алмый. Житмәсә бит, сылтау да бар, энекәшне күрергә килгән, янәсе. Энекәш дигәннән, аны өйдә туры китереп булмады, каты сука өсте иде, сукада икән бу. Күлеңгә кайтканчы көтәргә булдым. «Өйгә кер» дип әйтүче булмады, шулай да бик бөрешеп калды бу, дип тә уйламагыз. Амбар алдындагы зур лар өстенә кыңгыр барып төштем, каптым авызга папирос, чәчне туздырып жибәрдем, кояш минем иткә, ә күзләр минем поп йортының тәрәзәсендә. Әллә нәрсәдән дип уйлый

күрмәгез, сер бирәсе килмәгәннән, янәсе, энекәшне бик алай сыкмагыз, ташландык бала түгел ул, менә аның нинди фасон йөрүче абыйсы бар.

Поп үзе, җирдән сөйрәлә торган кара җиләнен җилфердәтеп, каядыр чыгып китте. Хатыны булса кирәк, миңа кырын күзен генә салып, берәү, вак-вак кына атлап, кар базы ягына үтте. Олы гына гәүдәле, зур зәңгәр күзле, кабарынкы гына бер нәрсә, һәрхәлдә, ачлык күргән кешегә бер дә охшамый. Ачуланды дип әйтмәс идем, шулай да, сыртына караганда, аптыраганлык бар. Янәсе, кайдан килгән кала этәче бу, каралты-кура арасына ут төшереп калдырмаса ярый?

Ә фактически алып әйткәндә, утны мин түгел, утны ул йортта минем үземә төшерделәр. Рәте-рәте белән генә сөйләргә дә бит, яшь чаклар искә төште, күңел түзми, берьюлы чыгарып түгәсе килә.

Кыскасы шул: әлеге теге миңа аптырабрак карап узган хатын кереп китте, мин кырын әйләнеп төшкән урынымда бариндай ятып калдым, авыздагы папирос та, көн яктысында көзгедәй ялтырап торган итекләрем дә файда итмәде, мине өйгә чакырып алучы юк та юк. Утырам да утырам, кояшта кызынып утырган ялкау мәчедәй. Каршымда поп өенең зур-зур тәрәзәләре, челтәрле пәрдәләр, пәрдәләр артында ник кенә бер җан иясе күренсен.

Ичмасам, теге малай да кайтмый, сөйләшәсен сөйләшер идем дә кайтып китәр идем. Монда, кеше тәрәзәсенә карап, күзләрне яндырып утырганчы...

Энекәшне кайтарып җиткерә алмадым, мин берне көткәндә, икенче яктан, бөтенләй көтмәгәндә, икенче тамаша килеп басты минем каршыма... Туктагыз, бу тирәгә җиткәч, бик кумагыз, җайлабрак сөйләргә исәп. Сөйләп биреп булса ярый. Элек иреннәрне бер чылатып алыйк.

Агаем рюмкага авызын тидереп алды, ләкин эчмәде, күреп торам, ул эчмәгән килеш тә минуттан-минутка исерә барган кебек иде. Бер мәл бер ноктага текәлеп тынып торды, ахрысы, сүзне нидән башлап җибәрергә белмичә аптырабрак калды булса кирәк.

— ...Менә шунда, әйтергә кирәк, бу килеп чыкты и шуннан башлап, малай, минем эш хөртигә китте, — дип тотынды Гаптелмөлек абзый, гадәтенчә, чак-чак шаярткандай итеп. — Сез уйлыйсыз булыр: амбар алдында ялтыр куныччлы итекләрен балкытып, чәчен-башын түздырып, авызында кала папиросы төтәтүче фасон егет берәүнең дә башын әйләндермәгәндер дип? Әйләндергән икән шул. Әйләндермәгән булса, чыгар иде Оксана апаң. Чыкса да, алай үзәкне өзәрлек итеп, киенеп-ясанып чыкмаган булыр иде. Ничек итеп аңлатып бирергә инде сезгә. Рас тәртә арасына керден, көчең җитсә, җитмәсә, тарт инде. Кыскасы, чыкты бу. Киенгән-ясанган. Чәче-башы лента белән түлган, биленда шулай ук ленталы пута, дөресе, телгә кертеп әйтерлек биле дә юк, неп-нечкә, кыс та өз шул нечкә биленнән. Кыскасы, чыкты бу. Йөри бу ишек алдында тырт та пырт басып. Әллә кирәккә, әллә кирәксезгә йөри — белгән кеше юк. Шулай да мин беләм, дөресе, белергә тырышам. Бер дә бүтән түгел, минем күңелгә ут үрләтергә йөри. Ә миңа, әле генә Донбасстан шомарып кайткан ялтыр куныччлы аякка, күпме генә кирәк соң! Нечкә билен сыгылдырып, бии-бии бер узып барганда, ходай тел ачкычы бирде дип әйтимме, тот та дәш мин моңа:

— Берәр кадерле әйбереңне югалтыңмы әллә, чибәркәем? Әйт миңа да, әйдә, бергәләп эзлик.

Ышанмасагыз, әнә Герасимовнаның үзен чакырып, ант иттерәбез, билләһи, шулай дидем. Чатылдатып русча шулай дидем, хәзергә хәтле үземә үзем отчет биреп җиткерә алганым юк, ничек йөрәгем җитте икән дә, ничек телем әйләнде икән!

Кыз, гаҗәпләнгәндәй, миңа күтәрелеп бер карап куйды, и әйтергә кирәк, шул бер карашы белән өзде дә алды йөрәгемне, и шуннан бирле йөрәгем тәки аның кулында.

Анын шулай күтәрелеп бер каравы булды, минем солдатча каршына барып басуым булды. Ул тора елмаеп, мин торам елмаеп. Ул бер сүз эндәшми, мин бер сүз эндәшә алмыйм. Югалып калдым дисәм, бик үк югалганга да охшамыйм, әчтә пәри түе: күзләрем белән ашыйм мин моны. Теләчедә базар гына дип уйлый идем мин монарчы, Теләчедә чиркәү генә дип уйлый идем, юк, дөрес уйламаган икәнмен, Теләчедә керфекләреннән бал-май коела торган менә бу чибәр маржа кызы да булган икән. Үземнең нәрсәгә килгәнлегемне онытым, әнинең жылый-жылый Гаптелхәйне каргавын да онытым, каршымда бары шул чибәр кыз гына басып калды, анын шаян зәңгәр күзләре, ак маңгае, нечкә биле, беленер-беленмәс кенә калкып торган күкрәкләре калды. Күңелемнән шунда яшен тизлегендә бер уй узды: «Тагын барырмын, тагын таш, күмер казырмын, тагын урысча өйрәнермен, жылый-жылый өйрәнермен, кирәк икән, алтын шахтасына китәрмен, каз күкәе чаклы алтын табармын, таба алмасам, урлармын, ничек итсәм дә итәрмен, Теләче уртасында, бөтенләй коры жирдә үскән бу су кызын, бу әкият кызын, бу нечкә-билне ничек тә үземнеке итәрмен. Ант итеп әйтәм: билләһи, билләһи! Алай дисәң, бу маржа кызына безнең татар анты батмый да торгандыр әле. Ярамаса ярамас, мин барыбер шулай эшлим. Мин барыбер аны үземнеке итәм!»

Күңелемнән үзем шулай кала корам, үземнең шул арада — бәхеткә каршыдыр инде — телем тагын әйләнеп китте.

— Әниеңнән курыкмыйсыңмы соң? Тәрәзәдән әниең карап торса...

— Торса тагын... Син бит мине тотып ашамассыңдыр?

Ул шулай диде, билләһи, шулай диде. Шулай дигәндә анын ак кына, вак кына тешләре жемелдәп калды. Ходаем, мин күргән чибәрлекләре өстенә әле тагын анын әнә нинди матур тешләре дә бар икән. Битемне куяр идем анын шул тешләре арасына, умырып алсын иде битемне.

Шушы бер-ике авыз сүз сөйләшеп алу, шушы сөйләшмичә карашып тору житә калды. Төшкә кайткан жирендә энем Гаптелхәйне лапас астына алып кердем дә борылып карарга вакыт та калдырмыйча, йөзенә бәреп әйттем:

— Чукынасыңмы ул кыз өчен, Гаптелхәй? Турысын әйт, син чукынмасаң, мин чукынам.

Менә сезгә үгетли килгән абый!

### III

Китте шулай башланып, китте башланып, син инде, жан кисәгем, туктатам дисән дә, туктата алмаган булыр идең. Элек энекәш янына барган атлы булып чаптым — ишек алды тирәсеннән әллә ни узган булмады, мәгәр кызны күрмичә киткән дә булмады. Теләче белән безнең Ямбулат арасы ерак жир түгел, шулай да юлда нинди дә булса берәр усаллык уйлап чыгару өчен житәрлек: «Исәнме, саумы»дан узылган, ләкин: «Мин сине сөям! Син миңа кияүгә чык!»ка хәтле үк барып жителмәгән. Шул ике арада Бактың исә, малай, шул ике арада да байтак баш әйләндерергә мөмкин икән. Бер барганда: «Мә, сыерасыңмы, Донбасстан кайткан күчтәнәч», дип, калай тартмалы мятный конфет тәрттем тегеңә. Юха түгел диген ялтыр куныччлы итекне: «Үзебезнең авылда бүләк итәрдәй кеше тапмадым, ходай синең авызыңа насыйп иткән икән», дигән булып теләмә салынам. Әллә татар ходаен күздә тотам, әллә урысныкын — анысын белгән юк. Кызыйның авызы ерыла, күз алдымда ак кына, вак кына тешләре ялтырап кала. Ә бу инде миңа атна буена хыялланy өчен житәрлек. Икенче барганда икенче усаллык әзер: «Тотып карыйм әле, малай, кулларыныңның сөяге бармы синең? Бик ак, бик йомшак күренә безнең кара күзләргә», дигән булып, кулын

кысып алам. Шундый йомшак, шундый татлы, монысы белән хет ике атна исереп йөр. Ә мин тиле ике-өч көн дә тора алмадым, иртәгә Теләче базары дигән кичне тагын киттем — сылтау да эзләп тормадым бу юлы, өйдәгеләргә дә сиздермәдем. Күренмәсме, капка төбенә чыкмасмы дип, капка-коймалары тирәли солдаттай урә катып әйләнеп йөрдем. Юк, күренмәде, хәерсез. Аның каравы икенче көнне базарда, бер кирәксезгә кешеләр арасында буталып, иптәш кызы белән бу килеп чыкты. Теләче кызлары шулай алар, йомышлары булса-булмаса, базар көнне үзләрен күрсәтә чыгалар. Киенәләр-ясаналар, бил путаларына кулъяулык кыстыралар, кесәләренә көнбагыш алып салалар — чырт та чырт көнбагыш чиертеп йөриләр. Минеке ул дәрәҗәгә үк барып җитмәгән, мәгәр мин алып кесәсенә салсам, түгеп ташламас кебек күренә кызый. И сүзне шуннан башладым да:

— Көнбагыш белән сыйлыйммы үзегезне, кызлар? — дидем эре генә.

Минеке — поп кызы ич — әллә ни сер бирмәде, әмма тагылып йөри торган иптәш кызының авызы җәелде. Һич уйламаганда бер кесә күчтәнәч эләккәч, поп кызы белән безнең арада эшнең тегеләй-болайрак икәнлеген чамалап, тизрәк китү ягын карады. Икебез генә калдык димим, нишләп икебез генә калыйк, базар тулы халык, шау-гөр килеп кайнап тора. Аласы кеше ала, сатасы сата. Ә минем күзгә бер нәрсә дә күренми. Минем өчен базарында да, дөньясында да без икәү генә.

Шулай итеп, безнең дөнья киңәя төште, ишек алдыннан бәреп чыктык, атна кич саен базарда очраша башладык. Аламы, алмыйммы, — әлбәттә, кыз янына буш кул белән бару юк, бигрәк тә базар көнне. Бер заман өйдәгеләрдән качырып алып калган акча бетте, авылда акча табар урын юк, әнинең тавыкларына тотындым. Базар көнне таң тишеленнән торам да, тавыклар кунакчадан төшеп өлгергәнче, кырылдатып берсен эләктерәм, и кеше-кара күзе төшкәнче, тавыкны култык астына кыстырып, алдына-артына карамыйча, кем чаба Теләче юлында? — Гаптелмөлек абзаң чаба Теләче юлында.

Шулай да, аягында ялтыр кунычлы итек булган хәлдә, әниеңнең тавыгын чәлдереп, шул тавык саткан акчага кыз сыйлап азапланулар туйдырды мине, гарьлегемне кутәреп йөри алмас чиккә җиттем. Шулай базарда очрашуларның берсендә, кызны беләгеннән алып, үземә якынрак китердем дә аның әлеге шул күргән саен мине акылдан яздыра торган йомшак зәңгәр күзләренә туп-туры карадым. Бөтен бәла дә шунда: аның ул күзләренә карап, башыңны югалтмыйча озак калырга мөмкин түгел иде яшь чагында. И мин, башымны югалтканчы, күңелемдәгеп тизрәк бушатырга булдым.

— Кара әле, шайтан кызы, кайчанга хәтле болай, акчасыз килеш, базар таптап йөрербез икән без? — дидем ачуымны-дәртемне бергә кушып.— Мине беләсең, дөньяның кай төшендә кычыткан, кай төшендә акча үскәнлеген күреп кайткан кеше. Туйдым мин ике авыл арасын таптап. Китәм. Китәсеңме, әгәр сине дә алып китәм дисәм?

Дуамал каты куелган бу сораудан Оксана — маржа кызы — кинәт сискәнеп, җиңел гәүдәсе белән калтырангандай итте. Бите алсу-кызыл булып янып куйды, аннары күтәрелеп миңа бер карап алды, — янәсе, уйлап әйтүеңме бу, Ямбулат тилесе? Күтәрелеп карап алды, шундук күзләрен озын керфекләре астына яшерде. Мине ак маңгае белән сөзеп торган кебек, тора да тора бу. Ә мин сөзеп караганны бик өнәмим, җитмәсә тагын, әнинең тавыкларын урлап саткан акчага кызлар сыйлап йөрүдән тәмам туйган да идем. Алдын-артын уйлап карамастан, ялт тиледән туры хәбәр:

— Мин ике сөйләп торырга яратмыйм: исәбең бар икән, әзерлән. Киләсе атнага Арча поезды белән... шау-шу күтәрмичә генә сәфәр чыгабыз. Мәтәштергән генә буласың икән, үпкә-сапка юк, но, конешно, миңа җиңел булмаячак.

— Монда, базар уртасында сөйләшеп буламыни мондый сүзләрне, — диде ул, бу юлы инде үзе минем беләктән алып. Кая алып барганын, ни эшкә алып барганын һич әйтмичә, җилтерәтеп, базардан алып чыгып китте мине. Авылдан ук алып чыгып китте. Бераздан без инде Комаровка болынындагы таллыклар арасында, аулакта, икәүдән-икәү генә калган идек. Алай куркыныч эшкә дә алып килмәгән икән, хәер. Килеп җитү белән, аны-моны һич аңлатып тормастан, муеныма сарылды һәм, әйтергә кирәк, яхшы ук җиренә җиткереп авызымнан үбеп тә алды. Дөресен әйтим, ялганлыйм икән, шушы урында җир йотсын, бу минем кыз белән беренче үбешүем иде — кара әле, ходаем, әкәмәт кызык нәрсә икән ул, беренче үбешү, тәменнән башларым әйләнеп киткәндәй булды. Ә ул, Оксана очкалакны әйтәм, үзе куркуыннан бер агарды, бер кызарды, үзе аска караган, үзенең күзләрендә яшь, үзе шул килеш, тотлыга-тотлыга, сүз әйтергә азапланган була:

— Ризалыкка... мин риза да булдым, ди. Миндә гenәмени эш. Олылар бар бит минем... Синең дә бардыр олыларың. Алар нәрсә дияр бу эшкә?

Олылар белән сөйләшербезме, юкмы? — хәзергесе минутта ул чаклысын белгән кеше юк, хәзергесе минутта миңа иң ачыгы шул: без инде утыртма койма белән төреп алынган ишек алдында түгел, без хәзер мәш килеп кайнап торган базар уртасында түгел, без аның белән икәүдән-икәү генә, безнең өстә киң булып зәңгәр күк ачылган, безнең өстә кояш, безнең башларыбызга аның җылысы, ягымлы нуры коела...

Кояшын кояш та, ахырында бер көнне Герасим поп каршына да бармый мөмкин түгел иде. Оксана моңа теше-тырнагы белән каршы килеп карады, ул әйтмичә-белдермичә китәргә әзер, ләкин минем, Ямбулат татарының, сорап, нигә булса да ирешә алачагына ышанып җитми иде. Качырып алып китәргә бервакытта да соң түгел, мин шулай да тәвәккәлләргә, сорап карарга булдым. Итекләремне күз чагылдырырлык итеп ялтыраттым, өскә сатин күлмәкне кидем, иңгә, җиңнәрен кими генә, пинжакны элдем, пинжакның күкрәк кесәсендә әлеге теге чалма башлы карандаш — писарь да писарь, мин дә писарь. Бардым да чакырып чыгардым Герасим атакайны крыльцога:

— Шундый-шундый эш, атакай гынам, мин сезнең Оксананы үзем белән алып китәргә булдым, — дидем.

Башта, берни дә аңламагандай, күзләрен челт-челт йомгалап карап торды бу. Аңламыйммы соң, аңлады, әле ничек кенә аңлады. Мин бит сүземне бик ачык итеп әйттем. Сүздә генә дә түгел хикмәт, үзем дә бик кызышкан идем ул минутта. Күземне терәдем дә каттым. «Бу зимагорны берьюлы болай тилертсәң, алды барның арты бар», дип уйлады бугай. Ул дәшмичәрәк торгач, мин, суынырга бирмичә, тагын ярып салдым:

— Чукынырга дисең икән, алып бар чиркәвеңә, атакай гынам, чукынам, — дидем, һаваны ярып. «Мина синең Исусың ни дә, татарның Мөхәммәте ни — берсе белән дә кул биреп күрешкәнем юк», дигән кәфер уй узды күңелдән. Ләкин бу чаклысына баш җитте, әйтмәдем. Күземне терәп, тик торам карап.

Герасим атакай мәсьәләне бу чаклы текә китереп куюдан тәмам аптырап калды бугай, ни дип әйтергә дә белми, ул да карап тик тора. Уйлый бугай эченнән: «Үсп түгел, ахры, боларның эшләре, бу чиккә килеп җиткәч». Әйтәсе дә юк, уйларлыгы да бар шул. Бер яктан, күренеп тора, саваплы эш: бер татарны христиан диненә күчерү мең пот дуңгыз ите ашау белән бердер ул — белеп әйткән сүзем түгел, күңелгә шундый дурак уй килде. Икенче яктан, хәтәрлеген дә чамалый булыр: илдә кругом совет законы, койрыгыңны гына кысып торасы бервакытта дин исеменнән шулай кеше аздыра башласаң, соңыннан савабыннан болайрак җавабы булыр. Хет алды, хет арты, әйтмичә булдыра

ФАТИХ ХӨСНИ ◆ ПОП КЫЗЫ ЭКСӘНӘ ◆

алмыйм, башлы кеше булып чыкты ул минем Герасим кайнатай. Моны мин хатынымның этисе булганлыктан гына әйтмим. Уйлады бугай шул чагында ук: «Күзләре бик ут яна бу зимагор татарның, эшләре тирәнгә киткәндер, поп башын белән соңыннан адәм актыгына калуын бар», дип пичәт сугып куйды бугай. Ә безнең арада, әлеге шул Комаровка болынында бер үбешүдән башка, берни дә булганы юк иде ул чагында. Шулай бит, Әхсәнә Герасимовна, дөресен әйтәм бит?

— Әй, сине, карт болтун, — дип кулын селтәде хатыны һәм табыннан торып ук китте. Ләкин мин аермачык сиздем: ачуланып түгел, яшьлек хатирәләре искә төшүдән кинәт тулышып, бер урында утырып кала алмаганнан торып китте. Хатыны кузгалып киткәч, бу сәрхүш агай инде бөтенләй тугарылыр дип уйлаган идем, киресенчә килеп чыкты, агаем ничектер аксый төшкән кебек булды, юмор уты сүрелде, берсеннән икенчесенә лап-лоп сикергәндәй, фактларны гына ата башлады — шунда мин тагын бер кат төшендем, юк, аларның эшләре уен булмаган, алар чын-чынлап бер-берсен яратышканнар, бу яратышу әле хәзер дә сүрелмәгән-сүнмәгән, Гаптелмөлек агаебыз ни өчен болай сандугач? Якында яраткан кешесе булганга сандугач икән!

— Бер бардым, ике бардым Герасим атакай каршына, — дип сүзне тизрәк очларга тырышкандай, ашыгып ялгап алып китте аннары, — соңыннан Оксана белән икәүләп бардык. Совет властен исенә төшердек атакайга, Совет властенда кешеләрнең бәхетенә аяк чалырга ярамаганлыкны исенә төшердек, янә дә килеп, шул елларны безнең тирәдә шаулап алган бер эшне исенә төшердек: «Әнә анда, Мәтәскә мулласының кызы тегермәнче Тимофей малае Пашкага кияүгә чыккан, үзләре шулай теләгәч, бөрәүнең бер каршы килергә хакы юк. Тора бирәләр», дип тә өстәдек. Дөресе, Оксана түгел, мин шулай тездем боларын. Ник дисәң, мин тәкатьсез идем бигрәк.

Күп сатулашулардан соң ахыр, бер көнне буасы ычкынды атакайның:

— Алла үзе шаһит, минем кулдан килерлеге калмады, — диде ул, тәмам гажизләнгән бер тавыш белән. Шул арада үзе, почмактагы икона тактасына иңбашы аркылы гына борылып, аннан-моннан гына бер төртенеп тә алды. — Үз бәхетегез үзегез белән, балалар. Безгә рәнҗемәгез, шулай ук бер-берегезне дә рәнҗетмәгез. Илла әнигезнең бер үтенече бар: кешегә-карага, мәхәллә халкына бик сиздермичә, шау-шусыз гына тирәдән чыгып китсеннәр, без картларның йөзенә кызыллык китермәсеннәр, ди.

Безгә нәрсә? Безгә шул сүз генә кирәк тә. И киттек шулай — ике чабата бер кием булып.

— Ярый, сез киттегез, ди. Ә Гаптелхәй? — дип бүлдердем мин кызулы тәмам житкән агаемны, бүлдермичә булдыра алмадым. — Сезнең бит әле Гаптелхәй энегез дә бар иде түгелме соң? Заманасында шул ук кыз өчен сездән алданрак чукынырга йөргән и шуның белән авылыгызда шау-шу кузгаткан энекәшегезне әйтәм.

— И якташ! — Гаптелмөлек абзый тәмле жирендә сүзне бүлдергәнем өчен чак кына ачулангандай, кул селтәп куйды. — Язучы булсаң да авылны житәрлек белмисең икән, жаным. Авыл бит ул моржадан очкын чәчрәп чыкканга да «Пожар!» дип кычкырырга тора. Куак кыштырдаганны, йөз бүре күрдем, дип кайтып әйткән, ди ич берәү. Әллә син аны әллә кайдан — ерактан килгән бәндә дип беләнме? Шул безнең авыл кешесе ул. Безнең авылныкы булмаса, безнең якныкы. Гаптелхәй турындагы сүз дә шулай йөз бүре әкияте булып чыкты. Бәлкем, йөргәндер итәгенә кызыгып, кем белә ул чаклысын. Ә бит поп кызы чаклы поп кызын кулга төшерү өчен, агай-эне, итәккә кызыгып йөрү генә житми, урысчасын да сайра, кирәк урында кызның желегенә йөгерә торган сүзен дә тап, житү чәч тә кирәк, авызында тәртә юанлыгы папирос та

булсын и, кешегә-карага сиздермичә, эниеңнең тавыгын да чәлдерә бел...

— ...Әмма шулай да, узган эшкә салават, дөресен әйтми булмый бу урында, — дип, бераз икеләнгәндәй сузып торды Гаптелмөлек агай, — шулай да, хәйлә-усаллыкта минем кебек Донбасс ташы астыннан чыккан булмаса да, уйнап йөрмәгән булса кирәк Гаптелхәй дә. Шуннан чыгып әйтәм бу сүзне: Герасим кайнатай Оксана белән мине, ат жиктереп, Арча станциясенә хәтле озаттырырга булгач, жир астына төшеп югалгандай качты малай, тыңламады хуҗасының сүзен... Күрәсең, ачуланган безгә. Нишләмәк кирәк, кешегә-карага бик шауламыйча гына икенче бер олаучы малай ялларга туры килде. Әй, андамыни эш. Эш шунда: Оксана апагызны Гаптелмөлек абыегыз тәки чиртеп китте бит! Кая? Кая булсын, әлеге шул күз күргән Донбасс якларына. Картлар алдында биргән сүзне җиргә егып салмадык, бер-беребезне рәнжетешү булмады. Мин эшләгәндә Оксана укыды, инженер булып чыкты. Аннары ул эшләде, мин укыдым. Минем татар икәнлекне бөтенләй онытып бетермәсен дип мин аны юри «Әхсәнә» дип йөри башладым, — шуннан китте инә ул «Әхсәнә Герасимовна». Кайчакта ул да «Гаптелмөлек» дип сузып тору бик читен, тел сына, яртысын әйткәч, утырып ял итәргә кирәк, дигән булып теленә салынып, «Миша» гына дип җибәрә — аңа карап кырыебыз кителгәне юк, яшибез.

Алдан сөйләшенеп куйган договор буенча, беренче балабыз кыз булып туса, ана Мария исеме кушмакчы идек, договорны үтәдек, кызыбыз булды, Мария исемен куштык. Ләкин анысы бездән рөхсәт сорамыйча гына Мәрьямгә әйләнде. Сәбәбе шунда: җәен авылга, безнең Ямбулатка кайтаргалап торткан идек, шунда шул әбисе белән, әйтергә кирәк, минем әни белән бик дуслашкан. Әбисе, бездән сорамыйча гына, Марияне Мәрьямгә әйләндергән. Шулай йөри ике ат белән — авылга кайтса Мәрьям, Мәскәүгә килсә — Мария. Бездән уздырды, өч тел белә хәзер, телләр буенча китте эше. Рус теле белән татар теле — үзенең родной телләр инде, берсе ана теле булса, икенчесе ата теле. Аларны кая да куяр хәл юк. Икенче балабызга — малай булып туды анысы — минем күңелне табарга тырышыптыр инде, Әхсәнә Герасимовна үзе йөреп Рөстәм дип куштырган иде, анысы аллага шөкер, бер телне дә рәтләп белми, анысының теле — архитектура булып чыкты. Җенләнгән шул архитектурасы белән. Мәскәүдә нинди шәп йорт бар — бөтенесе шул минем малай эше.

— Түгелдер лә, әтисе, башка кешенекеләр дә бардыр арада, — дип сүз кыстырып куйды Әхсәнә Герасимовна, шаяртып. Гаптелмөлек агай, хатынына сиздермәгән атлы күренергә тырышып, миңа күз кысты:

— Ә поп кызы Әхсәнә апаң татарча ничек сайрый, күрдеңме? Белеп тор: бусы моның минем заслуга. — Ул мактангандай тамак кырып куйды. Хәер, картайганчы көр күңеллелеген югалтмаган бу абзыйга мактанса да җирендә иде. — Аны татарча сөйләргә өйрәттем, үзем татарчаны әкренләп онытып барам, яшибез шунда Мәскәү уртасында кечкенә генә бер интернационал булып.

— Кунакны ялыктырып бетерден бугай инде юк-бар сүзләрең белән. Кыстый да белмисең кеше кебек, — дип, картын бүлдерде Әхсәнә Герасимовна. Ул арада ишектә звонок булды, без барыбыз да кинәт кенә бик житди кешеләргә әверелеп калдык.

## IV

Аларның Рөстәме, әлеге шул «Мәскәүдә нинди шәп йорт бар — шуларның барысын да» салган архитектор уллары кайтты. Алдан рекламасы да шәп булгач, мин ул егетне баштанаяк һәм барлык хәрәкәтләрен игътибар белән күздән кичереп утырдым. Әтисенең «бер телне

дә белми» дигән сүзләрендә дә хаклык юк түгел икән, егет гомумән бик аз сүзле күренә, картның салып алгач күп сүзлегә әйләнүен башук өнәми иде булса кирәк. Әтисе аны төрле сораулар биргәләп сүзгә катнашырга бик тырышып караса да, теләгенә ирешә алмады, егет кыска-кыска җаваплардан узмады. Коньяк салып биргәч тә:

— Бетерәсе эшем бар, ярамый, — дип кире какты. Әтисе кебек зур гәүдәле, калын тавышлы, калын кара кашлы, йөз сызыклары гомумән эре, хәтта беркадәр тупасрак та булган, әмма үзеннән көч-куәт ташып торган бу ир-егетнең акылы-фигыле күбрәк әнисенә охшаган иде булса кирәк, шул кыска гына арада абайлап алуыма караганда, әнисе белән алар сүзсез дә, күз карашлары белән дә ничектер тиз генә аңлашып алалар иде шикелле.

— Син якланма инде, әтисе, күрәсең, эшем бар, ди ич, — дип арага керде Әхсәнә Герасимовна, агаебыз кызмача баштан артык сагызланырга тотынгач. Ләкин бала җанлы Гаптелмөлек агай ничек кенә булса да малайны миңа — язучы якташына — төрле яклабрак һәм мөмкин чаклы шәбрәк итеп күрсәтергә тырыша иде. Әмма барып чыкмады картның бу тырышлыклары. Егет өстәл янына утырып, берни капмыйча, куе итеп ике чынаяк чәй ясатып эчте дә өстәл яныннан кузгалды, ләкин сүзсез генә китәргә яхшысынмады булса кирәк, нәзакәтле генә итеп рөхсәт сорады һәм шул арада, башкаларга сиздермәскә тырышып кына, әтисенә күз кысып алды. «Бик арттырып җибәрмә син, картлач!» дип кисәтү дә өстәл янында озак лыкылдап утыра алмавы өчен шаяртып кына булса да гафу үтенү дә, ата белән малай арасында тиз генә өскә бәреп чыкмый торган тотрыклы якынлык та чагылып калды бу күз кысуда. Бу аз сүзлелектә, кыска һәм җыйнак хәрәкәтләрдә, эчемлеккә исе китмәүдә һәм әнисе белән ничектер ымлыклар аша гына аңлаша белүендә егетнең әтисе күрсәтергә теләгәннәрдән күбрәкне күрдем мин, әйе, «бер телне дә белми торган» бу егет эш телен яхшы белә булса кирәк һәм ул, бүгенге яшьләргә хас булганча, безгә — олырак буын кешеләренә — бераз гына өстән торыбрак та карый түгелме икән әле? Һәрхәлдә, миңа шулайрак тоелды.

Тырышып-тырышып та малаен минем алда тиешенчә «чишендерә» алмагач, ниһаять, Гаптелмөлек агай малае алдында мине «чишендерергә» керешә.

— Менә, белеп кал, малай актыгы, безнең якташ булыр бу, — диде ул, бүлмәсенә кереп китәргә торган Рөстәмнең юлына аркылы төшеп, — язучы, панимаешь. Роман артыннан роман чыгара. Әле менә Мәскәүгә алдырырга торалар икән үзен.

Ходәвәндә! Коньяк нишләтә бәндәне! Олы башы белән, күрәләтә торып, нинди бәлаләр яга өстемә. Гомердә булмаган, телгә килмәгән, телгә түгел, күңелгә килмәгән сүзләрне ничек килештереп ялганлый. Әнә шундый килешле мактанчыклары, ялганчылары өчен дә яратам мин үзебезнең Теләче якларын.

Ә аның Рөстәме — икенче шартларда үскән, икенче диңгезләрне йөзеп, икенче җилләрдә чыныгу алган яшь буын — әтисенең җилъяграк кеше икәнлеген инде әллә кайчан белеп бетергән иде булса кирәк, әллә ни егылып төшмәде, авыз чите белән генә бер мәл көләмсерәп торды да кыска һәм эшлекле караш белән миңа карап куйды.

— Гафу итегез, әдәбиятта мин әти кебек җиңел йөзә алмыйм, — ул тагын бер кат ирония белән әтисенә күз төшерде һәм шундук янә минем якка борылды. — Толстойны күздән ычкындырмасам, миңа — техника кешесенә — шул бик җиткән.

— Толстойларның кайсысын? — дип иroниягә каршы мин дә ирония кыстырырга маташтым.

— Алары да берничәмени әле? Белмәгән идем, — дип, Рөстәм көр тавыш белән шаркылдап көлде һәм, шундук гадәттәге җитдилегенә кай-

тып, артык сөйләшеп тора алмаганлыгы өчен гафу үтенгәндәй, ашыгып бүлмәсенә үтте.

Соңыннан, Гаптелмөлек агай миңа тагын бер кат үзләренең китапханәсен күрсәткәндә, идәннән түшәмгә кадәр китап белән шыплап тутырылган стеллажларда моннан ике мең ел элек яшәгән борынгы Рим шагыйре Катуллдан башлап Евтушенкога хәтле — күп кенә шагыйрьләрне, хикәячеләрне, философларны күреп һәм алар арасында минем баш житмәслек техник әдәбиятны да күреп, алардан да бигрәк, бу китаплар тирәсеннән Гаптелмөлек агаемның, ничектер телсез калып, тизрәк шуып үтәргә тырышуын күреп, мин күңелемнән генә нәтиҗә ясадым: яшь буын, әлбәттә, бер Толстой белән генә туенып тора алмый, юкны маташтырмасын теге «телсез егет». Шул ук вакытта яшь буын безнең кебек шапырынырга да яратмый.

Тагын шунысы да кызык: шул стеллажларның берсендә, бер кырыйдарак, кырык-илле китап — татар китаплары да кереп кысылган иде.

— Бусы минем байлык, — дип әйтеп куйды агаем, шул уңайдан башкаларга үзенең «теше үтмәгәнлеген» икърар итүне үзе дә сизмәстән, — туры килгәндә алгалый йөрим, Әхсәнә Герасимовна белән без укыйбыз...

Ул кинәт, сискәнгәндәй булып, тотлыгып калды, артык әйтерлек сүз тапмады булса кирәк. Ләкин калганы сүзсез дә аңлашыла, бу күңелле агайның кинәт телсез калуыннан да бик аңлашыла: кунакның бу йортта, бигрәк тә яшьләр арасында, популярлыгы чамалырак иде булса кирәк шул.

*Март, апрель — 1968 ел.*

● ● ● ●

1ү

тє



# ХУҖАЛАР

Гариф Ахунов

РОМАН[1]

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

Мөстәкыймов хатынын уятмас өчен караватыннан иппәп төште, йомшак табанлы өй башмакларын аягына эләктереп, кухня ягына шыпырт кына чыкты. Кухня тәрәзәсенең форточкасын ачып, төнге тын урамнан салкынча бер агынты булып ташып кергән җиләс саф һавага ялангач күкрәген куеп, йотлыгып һава сулады. Рәттән ике тапкыр сигарет тартты, өченчесенә дә тотынган иде, теле бик өтелгәч, сигаретын бармаклары арасында йомарлап, чүп чиләгенә ташлады да, ялангач беләкләре белән үзен-үзе кочаклап, өстәл буенда утыра башлады.

Соңгы көннәрдә ул ничектер төнлә уяна торган булып китте. Моның сәбәпләрен тонык кына булса да сизенә иде Камил. Аның йокысын алган кеше — Арслан Гобәйдуллин — эшендә дә мактала, тормышында да гөрләп яши. Кыңгыраулы заводын инде сала да башладылар. Мотор тавышлары анда тәүлек буена тынмый, бетон баганаларга беркетелгән прожектор утлары төннәрен бик ерактан күренә.

Камил төзүчеләрнең нинди хисләр белән яшәвен, дөресрәге, Гобәйдуллин башлаган эшкә аларның нинди мөнәсәбәттә булуларын белү өчен ике мәртәбә төзелеш урынына барып кайтты. Ун гектарга якын мәйдан төптәрле тимер конструкцияләр, озын-озын торбалар, сферик шарлар белән тулган; гигант самосваллар аларны әле һаман китереп торалар; берничә урында бетоннан фундамент коялар; рельслар өстен-

[1] Ахыры. Башы 8—9 саннарда.

нән, дырылдап, күтәрү краннары шуыша; яшел пыялалы битлек, брезент куртка кигән сварщиклар, яшен утлары чәчрәтеп, заводның каркасларын ялгыйлар; металл чыны, машиналар гөрелтесе, команда тавышлары мәйдан өстен күмеп киткән.

Төзелештән Камил ике төрле хис белән кайтты. Зур максатка юнәлдерелгән күмәк хезмәтнең кешеләрне ничек туплавы, оештыра белүе, бер яктан, аның күңелен кузгатса, икенчедән, шушы зур эшне башлаган кешенең аның авторитетына бик кинәт китереп сугуы күңел төпкелендә берәүгә дә әйтми торган яра да калдырган иде.

Яңа промыселлар парткомының отчет-сайлау җыелышын нефтьчеләр Гобәйдуллин белән Вилдановның зур бер батырлыгы дип саныйлар. Имеш, алар үз ихтыярын көчләп тагарга тырышучы Мөстәкыймовны акылга утырткannар. Камил үзенә булган мөнәсәбәтнең үзгәрүен, коммунистларның аны әүвәлгечә үк ихтирам итмәүләрен сизеп йөри. Очрашкан чакларда аның белән коры гына исәнләшәләр. Бәлки ул алай да түгелдер, бәлки күңелдә рәнжеш саклаганга гына шулай тоеладыр. Ләкин, ни генә булмасын, әнә шул хис аны гасабиландырып, тәнгә чыккан сызлавыктай, кәефен алып тора.

Мөстәкыймов табигате белән үчлекле кеше түгел иде. Аның әле тормышта әллә ни авырлык та күргәне юк, берәү белән дә көрәшеп карарга туры килгәне булмады әле аңа. Кама буендагы кечерәк бер шәһәрдә пекарь семьясында туып үскәнгәме, сугыш елларында да алар семьясы ипидән өзелмәде. Әтисе алтмышлардан узган иде инде. Кызу мич янында көрәк белән ипи күтәреп гомере узгангадыр — ул аз сүзле, көрәктәй дәү куллы, сабыр табигатьле бер кеше иде.

Камилне, унөч яшьлек үсмерне, ул кырык өченче елны үзе белән ике атналык юлга алып чыкты. Камилнең абыйсы Сослангерда хезмәт итә. Саз эчендә урман кисүдән, фронтка җибәрмәүләреннән, ризык җитмәүдән зарлана иде. Камилнең әтисе аңа кыш суыгында бәләкәй чана белән бер пот сохари, бер пот ипи тартып алып барды. Ерак юл йөрергә гадәтләнмәгән Камилгә ул чагында кышкы ялангарның иге дә, чиге дә юктыр, алар җир читенә барalардыр кебек тоелды. Чана артыннан этеп бара торгач, аның аяклары тала, күзләре йомыла башлый, әтисе ләм-мим бер сүз дәшмичә бара да бара. Ничектер шулай бер авылда, өч баласы белән ятим калган ак чырайлы тол хатында төн кунып чыктылар.

Иртән, хатын белән саубуллашканда, Сәләх карт тол хатынга бер бөтен ипи бирде. Сөенеченнән ничек итеп рәхмәт әйтергә белмәгән толга әйтте:

— Килен, син тырыша күр инде. Балаларыңны укыта күр. Кара эш эшләп яшәүләре дә бик авыр,— диде.

Бу сүзләр Камилнең яшь күңеленә сеңеп калдылар. Мәктәптә ул әйбәт укыды. Хәтере дә шәп булгандыр, ике мәртәбә укып чыкса, озын-озын шигырьләрне ятлап ала, бер төн эчендә мәктәпнең стена газетасын чыгарып өлгертә, рәсемнәрне копировка кәгазе аша бик оста төшерә белә иде. Ләкин шул чакта ук аның күңелендә каршылыклы бер хис туган иде. Укытучылар аны гел мактап сөйлиләр, концертлар алып баруны, стена газеталары чыгаруны гел аңа тапшыралар, әмма укучы иптәшләре аны өнәп бетермиләр, аның чын күңелдән эшләгән эшләрен ярарга тырышу дип, куштанлык дип карыйлар иде.

Үзенең бүтәннәрдән сәләтлерәк булуын һәм шул сәләтлелек аңа күңелсезлекләр китерүен аңлау Камилнең холкына да чыкты. Күк ачуташ кебек зәңгәр күзләре ничектер маңгай астыннан карый торган авыр карашлы булып калдылар.

Мөстәкыймов университет тәмамлады. Анда да аның сәләтен күрделәр, комсомол комитетына, парткомга сайладылар. Аның хезмәт баскычы әнә шулай өзлексез үсә барды.

Кәлиматкә килгәч, берничә еллар лектор булып, аннары шәһәр комитетының инструкторы булып эшләде. Һәм, ниһаять, горком секретаре булып сайланды.

Ул инде үзен ихтирамга лаеклы кеше дип саный, партия карарларын төгәл үтәргә тырыша, эшкә бик пөхтә киенеп, төгәл килә иде.

Әйе, Яңа промыселларның отчет-сайлау җыелышына кадәр ул үзен көчле итеп сизә, файдалы эш эшләвенә нык ышана иде. Җыелышта үзе алып килгән кандидатура белән дөбер-шатыр җимерелеп төшкәч, ул Гобәйдуллин белән Вилдановка үпкәләсә дә, алардан үч алу, аларны эзәрлекләү турында уйлап та карамады. Шул ук вакытта бу гыйбрәтле хәлдән үзенә сабак та ала белмәде. Вакытлыча килеп чыккан бу аңлашылмаучылык узар, Гәрәйшин монда сайланмаса, башка урында сайланыр, дәгъвасыз гына сайланган урында эшләве аңа җиңелрәк тә булыр, ул үзен күрсәтер әле, Гобәйдуллин үзе үкенер, дип фикер йөртте.

Тик дөнья кинәт кире якка әйләнде. Хәким Гәрәйшинны идарә парткомнарына түгел, промыселларның башлангыч оешмаларына да сайламадылар.

Монысына инде Камил тыныч кына карый алмады.

Мөстәкыймовның рәнҗетелгән күңелендә беренче мәртәбә Гобәйдуллинга карата өнәмәү хисе туды. Бәхетсезлек аның идарәсеннән башланды, Гәрәйшинны ул якламады, Камилнең хәленә ул керергә теләмәде.

Мөстәкыймов кинәт Гобәйдуллинның сөйләшү рәвешендә дә, үз-үзен тотуында да, кылган гамәлләрендә дә масаю, шәһәр комитеты белән исәпләшмәү, коммунист иптәшләрен санга сукмау бар дип тапты. Партия тарафыннан җитәкчелек эшенә куелган, рядовой коммунистларны тәрбияләргә чакырылган кеше буларак, ул, Камил Мөстәкыймов, идарә башлыгының мондый тәртибе белән килешеп тора аламыни? Ничектер, үзеннән-үзе шулай килеп чыкты, ул Арслан Гобәйдуллинның кылган эшләрен бер генә көнгә дә күздән ычкындырмыйча, бик уяу күзәтә башлады. Максат куеп күзәтсәң — күренә икән. Иң әүвәл, ул идарә башлыгының властьтан файдалануын белеп алды. Халык арасында: Гобәйдуллин, сәүдә работнигын куркытып, үзенә келәм китерткән, дигән сүз йөри. Моны ачыкларга кирәк иде. Мөстәкыймов келәм китерүчене шәһәр комитетына чакырып, кабинетта япа-ялгызы гына сөйләште. Артык йомшак, артык ягымлы тавыш белән сөйләшкәнгәме, Гозәеров секретарьның үзенә ярдәм итәргә теләвен беренче сүздән үк аңлап, келәм вакыйгасын түкми-чәчми сөйләп бирде.

— Арслан Шәвәлиевичка минем тел-теш тидерер хәлем юк,— диде сәүдә работнигы,— ул башкалар кыланганнан артыгын кыланмады. Ул миңа әйтте: иң яхшы келәмне сайлап алып кил, бәясеннән тормам, диде. Мәскәүдән кайтышына дип мин келәмне аларга илтеп куйдым, әмма бәясен әйтә башлагач, ул күпсенде, мине алдап әйткән сымак итеп, ялганчы итеп сөйләште, мин төп-төгәл дөресен әйтеп тора башлагач, келәмем-нием белән өеннән куып чыгарды.

— Бу бит мыскыллау. Күрәләтә шәхестән көлү,— диде Мөстәкыймов.— Нишләп шәһәр комитетына килмәдегез?

— Сез мине якламасагыз? Мин кем дә, Гобәйдуллин кем! Минем урынга ун кеше табылыр, ә номенклатурный работник Арслан Шәвәлиевич урынына кеше каян табасыз? — диде Гозәеров, мескен кыяфәт белән.

Озак та үтми, гаделлек эзләп, шәһәр комитетына шофер Дугинцев килде. Ялгышуын чын күңелдән икърар итте Дугинцев, әмма идарә башлыгының властьтан артык файдалануын, транспорт конторасы директорына басым ясап, аны кышкы суыкта эштән кудыртуын сөйләп бирде. Дугинцев тәртипсезлек эшләвенең инде өченче мәртәбә булуын

әйтмәде, иптәшләр суды тарафыннан хөкем ителүен дә яшерде, аны ничегрәк мескенләнергә Гозәеров өйрәтеп куйган иде.

Шушылар өстенә Гобәйдуллинның комсомол башлыклары белән низагка керүе, әнисе аркылы комсомолга тел тидерүе билгеле булды.

Гобәйдуллинның эшен бюрога кую өчен бу өч факт бик житкән иде. Мөстәкыймов аны башта Яна промыселлар идарәсендә дә тикшерә ала иде. Ләкин партком секретаре Вилданов аны екмас, теше-тырнагы белән яклап калыр, дип уйлады.

Мөстәкыймов хәлләрне бик хәвефләнеп Корбановка житкерде. Чөнки Гобәйдуллин бик җаваплы пост били, аның бу башбаштаклыгы бөтәннәргә кире тәэсир итеп, шәһәр комитетын да уңайсыз хәлгә куячак бит.

Беренче секретарь аны үтә сабыр кыяфәт белән, бер генә мәртәбә дә бүлдермичә тыңлады.

Байтак вакыт тын гына утыргач, Корбанов өстәл тартмасыннан трубкасын чыгарып, аңа йомшак тәмәке тутырды, башын кыңгыр салып, трубкасына ут кабызды, тирән-тирән итеп рәттән өч мәртәбә суырды да үз тирәсенә җыелган төтенне кулы белән таратып җибәрде.

— Сез моннан нинди нәтиҗә чыгарасыз инде?

— Һич кичекми бюро җыйнарга кирәк.

— Ала-аай. Ә теге кем... Хәким Гәрәйшин кайда үтмәгән иде әле парткомга?

Мөстәкыймов кинәт битенең кызышып китүен тоеп:

— Ә нигә? Яна промыселлар идарәсендә,— диде.

— Әһә. Гобәйдуллин эшли торган идарәдә, әйеме?

— Ә нигә? — диде Мөстәкыймов, яман эштә тотылгандай.

— Юк. Болай гына...— Корбанов трубкасын катырак суырды, аннан хәтта чатырдап очкын чәчрәп китте.— Менә нәрсә, Камил Сәләхович, сезгә зур гына бер үтенеч: моны тагын бер мәртәбә бик җентекләп тикшерегез әле, барлык ягын уйлагыз, исәпләгез, бер атнадан соң миңа, рөхсәт-мазар сорамыйча гына кереп, докладовать итәрсез. Килештекме?

Камил башын иеп чыгып китте. Корбанов аның сизгерлеген хуплап каршы алыр, шундук бюрога куярга кинәш итмәсә дә, һәрхәлдә, комиссия төзергә, Гобәйдуллинның башбаштаклыкларын тикшертә башларга, аермачык нәтиҗәләр ясап килергә кушар, дип уйлаган иде.

Корбановның бу мәсьәләгә карашы томанлы булып калуы, юк, томанлы булып кына түгел, Мөстәкыймов инициативасын якламавы аны сәерсендерде, ул Гобәйдуллин белән Корбановны да янәшә куеп, аларның икесен бер сүздә дип исәпләп, бу эшне ник башлавына үкенеп тә куйды. Аның үзенә кыен килмәгәе, Корбанов авторитетлы, тәҗрибәле партработник, әгәр батырам дисә, Мөстәкыймовны ул бик ансат батыра ала. Ә өлкә комитетында нәрсә диярләр? Алар, мөгаен, Корбановны яклар, чөнки Мөстәкыймов аларның ышанычын акламады, Гәрәйшинны парткомга сайлатырга көченнән килмәде, ашыгуы, секретарь дигән исемне артык зур итеп аңлавы сәбәпле, коммунистларны алдан әзерләп куя белмәде, менә хәзер шуның аркасында кеше күзеннән төшеп бара инде...

Мөстәкыймовның доклад белән Корбанов янына керергә ике генә көне калган, ә ул фактларны ныклап тикшерә алмаган иде әле. Хәер, келәм вакыйгасын ул кабат тикшерә дә алмый, аны Гобәйдуллин белә дә, Гозәеров кына белә, ә Гозәеровның никадәрле намуслы хезмәт иткәнен ОРСтан тикшереп карарга Мөстәкыймовның башына да килми, әгәр келәм вакыйгасы төшеп кала торган булса, тәртип бозган шофер һәм комсомол мәҗлесендә килеп чыккан низаг Гобәйдуллин өстеннән казыну гына булып калачак. Мөстәкыймов төпсез көймәгә утырганын сизде. Менә ни өчен ул соңгы көннәрдә йоклый алмый башлаган иде.

Бүген ул эшкә дә бик әшәке кәеф белән килде. Тамагына берни капмады, бер стакан куе чәй эчте дә шул килеш китеп барды.

Кырык җирдә кырык эше кырылып ята иде аның. Тиздән Татарстан нефтьчеләренең актив җыелышы үткәрелергә тиеш, аңа чаклы күргәзмә әсбаплар әзерләргә, урамнарны бизәргә, Казаннан художник чакырырга, Кәлимәттәгеләрен дә шулар янына кушып, бик нык эшләтергә кирәк. Аның бернәрсәгә кулы бармый. Я, нәрсә дип әйтә инде ул беренче секретарьга?

Көндезге сәгать өчләр тирәсендә буфеттан чәй китертеп, кабинетында япа-ялгызы утыра иде, телефон шалтырады.

— Тыңлыйм, — диде Мөстәкыймов, күңелсез генә, әмма аның чырае шундук яктырып китте, кашлары, очынып, югары күтәрелделәр, һәм ул ак күлмәгенең катыргы якасын рәхимсез рәвештә бөтәрли башлады.

Телефоннан милиция башлыгы шалтырата иде. Ул Арслан Гобәйдуллинның Сарман юлы өстендә хулиганлык эшләвен, шул хакта милициягә жалоба килүен әйтте, нишлибез, дип киңәш сорады.

Мөстәкыймов, йөрәге каты-каты тибә башлавын тоеп, урыныннан торды һәм кул астындагы ике инструкторын чакырып, бүген үк, сәгате-минуты белән, Арслан Гобәйдуллинның гаугалы эшен тикшерергә җибәрде.

## 2

Татарстан бәйрәме көннәрендә район үзәкләрендә сабан туйлары башлангач, һич көтмәгәндә, Арслан күңелендә Көбәшләр заманыннан ук килә торган көрәшче дәрте кузгалды. Баштарак ул үзенең бу хиссеннән ирен чите белән генә елмаеп: «И, карт алаша, синең дә дәртең кузгалган була бит әле. Кая инде ул сиңа мәйдан тотып, көрәшеп йөрүләр! Авылларда әнә нинди әзмәвер егетләр үсеп җитте»,— дип, көлемсерәп кенә куя иде, гөнаһ шомлыгы, Габделхәй коткы салды аңа.

— Абый, алып бар әле мине сабан туена. Минем ничә ел инде көрәш караганым юк, — диде энесе.— Бәлки мин дә көрәшеп карармын.

Арслан аның таза базык гәүдәсенә күз ташлап, әллә чыннан да алып барыргамы икән дип, икеләнеп куйды. Эшләре дә көйле бара, завод салына башлаганнан бирле, промыселларда эш җайлана төште. Көзгә таба Җәлил шәһәренең беренче йортлары өлгерә. Ул чакта инде эш муеннан булачак, күңел ачып йөрүләр тәтемәс... тик менә сабан туеның мәшәкате күп шул — балаларны төяп чыгасы, Сәгыйдәнең яңа капризларын, бәйрәм күлмәге таптыруларын көттә тор.

Ләкин Габделхәйнең чигенергә бер дә нияте юк иде.

— Дәү абый, мин биг синең үтенечеңне үтәдем, сакалны кырып ташладым. Сашаның да сабан туен бик күрәсе килә. Безнең якларның матур бәйрәмнәрен аңар да күрсәтик инде,— диде. Арсланның дәшми торуын күреп, Сәгыйдә аркылы һөҗүм ясамакчы булды.— Алма апай, тәти җиңги, үгетлә әле начальнигыңны. Әнә күрмисеңмени, ул тагын әллә ниткән эшләр табар, промыселларым мин югында ятим утырыр, операторларым качып бетәр, диер. Әй, тәти җиңги, алма апай...

Шау-шу күтәрергә дисәң — Сәгыйдәгә бир. Ул бөтен өйне тутырып, әллә ниткән тыелгысыз бер сөенеч белән:

— Һай, җаным Габделхәй! Кайларда йөрдең син моңарчы, әллә кайчан сиңа ябышып чыккан булсам, егылыплар уңар идем. Җиде ел ирле-хатынлы булып торабыз, җиде елга бер мәртәбә бәйрәм-сабан туйлары да күрсәткәне юк бит аның миңа! Багынган китабына, багынган промыселларына, билләһи менә әгәр, шуннан башка бер генә кызык та юк дип уйлыймы соң ул!

— Я, бик остарма, — диде Арслан, сабыр гына.

— Остарам әле. Каениш барабыз дип торганда, остарам! Бу нинди мүкләнгән таш булдың син! Кешедән машина сорап йөрисе булса,

тагын бер хәл, машина үз кулында. Атнабайга бер сызгырдың, сәгате-минуты белән килеп җитә. Барабыз сабан туена, авызыңны да ачма, каршы да килеп маташма, начальник хатыны булдым дип кенә мин кеше төсле ял да итмәскә, чистый? Синең кебек үк мин дә эшлим, больницасына да йөгерәм, балаларны да тәрбиялим...

Арсланның сабан туена бармау теләге тәмам ныгып килә иде инде, әмма хатынының тавышы калтыранып, өзелеп китүен, тагын күз яше, үпкәләшүләр башланачагын уйлап, аңа юл куйды. Теге чакта келәм белән дә бик күңелсез килеп чыкты, булмаса булган икән, алып барырга кирәк.

— Кая барабыз? — диде ул, өзеп кенә.

— Сарманга,— диде Сәгыйдә.— Хәзер үк балаларымны әзерли башлыйм, җәйге җиңел костюмнарын юам, термослар алып барабыз, чәйләр эчеп, туйганчы бер ял итеп кайтырбыз. Сез теләсәгез, көрәш карарсыз, теләсәгез... анда ничек телисез, шулай эшләрсез.

Һәм шуның белән мәсьәлә хәл ителде.

Атнабайның «алмачуарына» төялеп, Сарманга, ел да саен сабан туе була торган җиргә, бик матур бер болын тугаена килеп җиткәндә, чуп-чуар мәйдан өсте күзләрне камаштырып җемелди иде инде. Райбашкарма председателе Сарман игенчеләрен язгы кыр эшләрен әйбәт башкарып чыгу белән котлап, сабан туеның башлануын хәбәр иткән арада, ягъни халыкны кыздырып җибәргәнче, машина күләгәсенә утырып, Атнабай, Габделхәй, Саша, Арслан белән Сәгыйдә һәм балалар тамак ялгап алдылар. Аннары Сәгыйдәне, бөтерчекләре белән бергә, мәйдан уртасы күренә торган уңайлы урынга утыртып куйдылар да, Атнабай белән Сашага аларны сакларга кушып, Арслан белән Габделхәй икесе көрәшчеләр янына кереп киттеләр.

Саша өчен боларның барысы да яңалык. Воронеж ягы рус авылларында туып үскән егет булганлыктан, ул берсен дә күргән-белгән кеше түгел, әле Атнабайдан, әле Сәгыйдәдән ул гел сорашып торды. Нигә капчык киеп йөгерәләр? Капчыкның төбе тишек түгелме? Бер бабай чүлмәк вата алмый аптыраган чакта, ул урыныннан сикереп-сикереп торгалады. «Селтәп сал!», «Астан җибәр!» — дип, бүтәннәр белән бергә көч-куәт биреп торды. Тик Атнабай аңа: «Син, дус кеше, бик кычкырма, балаларны куркытырсың, аннары синең бу җирән сакалыңа әнә кешеләр карый башлады инде»,— дигәч, уңайсызланып кызарды да, сәгать буе бер сүз дәшмичә, тик кенә утырды.

Көрәшчеләргә чират җиткәч, ул тагын ярсына башлады. Габделхәй өчен кайгырып та карады соң ул! Габделхәй ега алмый азапланган чакларда:

— Не подкачай, старик! Еще немножко! — дип, аның өчен үзе кереп егардай булып утырды. Габделхәй әйләндереп салган чакларда сабый бала кебек сөенде, Сәгыйдәгә берсеннән-берсе матуррак мактау сүзләре әйтте.

Ләкин аның шатлыгына бер мәлне күләгә төште. Габделхәй үзеннән күп олы яшьтәге, әкәмәт юан бер кешегә туры килде дә батырлар сайланышыннан төшеп калды.

Аның өчен бик кайгырдылар. Сәгыйдә дә кайгырды. Саша үкенеп бетә алмады. Бер Атнабай гына, кырын төшеп яткан җиреннән, акыл иясе картлар сыман:

— Сыек шул әле. Буын ныгып җитмәгән. Менә хәзер минем начальник көрәшкәнне карагыз,— дип, мутланып күз кысып алды.— Көч белән генә дә булмый. Хәйлә кирәк, агаем. Й осталык!

Барысының гаҗәбенә каршы, Арслан бик таза булып чыкты. Соңгы батырларның ул беренче турын да узды, икенче турында да беренче парда өстен булып чыкты. Аның зәңгәр ефәк майкасын күргән саен, бәләкәй Рәфикъ нишләргә белмичә:

— Әнә эти, әнә эти! — дип, этисенең мәйданда икәнен башкаларга хәбәр итеп торды, энисенең алдына кереп оялаган Әлфия, абыйсы әйткән саен, кулларын чәбәкли иде.

Арслан соңгы дүрт көрәшче турына чыккач, Габделхәй үзе еккаңнан болайрак шатланды.

— Молодец, абый! Ну көрәшеп тә карый! — дип, исе китеп әйтте ул.— Батыр калса гына ярар иде.

— Син нәрсә! — диде Сәгыйдә, коты алынып.— Курмисеңмени Арсланны көл итәрдәй егетләр утыра бит. Бар әле тизрәк, әйт әле абыеңа, балалары барын онытмасын, я имгәтеп куярлар...

Сәгыйдәнең борчылганын Арслан үзе дә аңлап алды бугай, семьясы, туганнары янына килеп, ак тешләрен күрсәтеп елмаеп китте: кайгырмагыз, янәсе, көч күп әле миндә...

Аның калак сөяге турысында майкасы ертылган, бите кызарып, тирләп чыккан, әмма беләгендә чыннан да көч күп иде бугай, энесенең кулын кыскан чакта, Габделхәй чамалап өлгерде: батыр ук булмаса да икенче батырга торырлыгы бар моның.

Ләкин беренче пар белән көрәшү Арсланга бик авырга килде. Әллә ниткән бер утын түмәркәсе — токтымалга дәү, ни селкенә, ни көрәшә белми торган аю Арсланның ике тапкыр өстенә төште. Икенчесендә Сәгыйдә чырыйлап кычкырып җибәрде. Ахырда түзмәде, баласын күтәргән көе йөгерә-йөгерә, көрәшчеләр янына кереп китте. Комиссия членнары аны ярты юлда туктаттылар. Кайгырмагыз, хәзер ега ул аны, диделәр. Сәгыйдәнең елар чиккә җитеп ачуы чыкты:

— Нәрсәсен ексын! Имгәтә бит! — дип, усалланып, комиссия членнарын тиргәргә тотынды. Әллә шуның файдасы тиде, түгәрәк кырма сакаллы, кара кәләпүшле чибәр бер карт көрәшчеләрне барып аерды да:

— Насрый, син көрәшәсең икән, көрәш, көрәшмисең икән, азапламa кешене,— диде.— Соңгы тапкыр алышасыз, әгәр дә мәгәр бу юлы да ул сине күтәрә икән, җиңү аның ягында калачак.

Инде мәйдан читеннән дә кычкыра башладылар.

— Куыгыз шул аюны!

— Карале ачык авызларны: курәләтә кеше имгәттерәләр!

— Әй, Сарманнар, юри чыгарганнар, яклашалар!

Халык ду килеп дәгъвалашкан арада Арслан үзе белән көрәшүчене җан көченә күтәреп алды да, аңар өскә аварга ирек бирмичә, ян-якка аударып, сыртына каплап куйды.

И шашынды халык! Бүтәннәр белән бергә Габделхәй дә котырынып кул чапты, Сәгыйдә кул чапты, Атнабай да кул чапты, Саша, кулларын көрәк итеп, шап-шоп китереп чапты.

Халыкка хисләрдән айнырга, мәйдан уртасында калган ике көрәшчегә ял итәргә ирек куйдылар. Көрәшчеләргә берьюлы бишәр чи күкәй китереп тоттырдылар. Арслан күкәйләрне маңгаена бәреп вата-вата, бер-бер артлы эчеп торган арада, чибәр итеп киенгән өч егет кереп, аңар: «Ектыр, туган. Без сине буш итмәбез!» — диделәр. Арсланның кинәт ачуы чыкты: тапканнар малга кызыгыр кеше. Ләкин ул киңәш итүчеләргә ак дип тә, күк дип тә әйтмәде. Аның белән көрәшергә тиешле егет яшь иде әле, аңа күп булса егерме ике яшьләр булыр, гәүдәгә ул бик тигез килгән, тәненә сыланып торган спорт костюмы да киеп алган, яшь кызларның симпатиясе, һичшиксез, аның ягында, Сарманнарның да симпатиясе аңарда, алар аның җиңүен өзелеп телиләр булса кирәк, төркемнәре-төркемнәре белән кереп, мең төрле киңәшләр бирәләр иде.

Арсланга да бер киңәш бирүче табылды. Атнабай бик җиңел генә йөгереп керде дә, гадәтенчә, ифрат матур елмаеп, Арсланның инбашына кагылды һәм өзеп кенә:

— Озак көрәшмә. Күтәр дә сал да куй! — диде гап-гади бер эш эшләргә кушкан сыман. Аннары матур итеп тагын бер елмайды да чыгып та китте.

Арслан һич тә егарга атлыгып тормый иде. Үзенә каршы көрәшәчәк егет белән ул бик тыныч, бик дустанә кул биреп күреште. Бернинди дә хәсетлеге юк икәнен күрсәтеп, елмаеп, аның кулын кысты:

— Ега алсаң, ек! — диде, кыска гына итеп.— Мин батыр калырга тырышмыйм.

Түгәрәк кырма сакаллы чибәр карт аларның икесенә дә, «бисмилла әйтеп», өр-яңа сөлгеләр китереп тоттырды. Арслан шуны сизеп калды: біленә сөлгене китереп салган чакта, егетнең әллә ничек кенә, дошманнарча, йөзе кыегаеп китте һәм ул көч белән түгел, гадел рәвештә түгел, хәйләләп, һич югы, аяк чалып егарга итенә башлады.

Гаделсезлекне күтәрә алмый иде Арслан. Эшләр алайга киткәч, ул, гадәттән тыш бер сабырлык белән, егетнең біленнән чытырдатып буып алды да аны күкрәгенә суырып китерде һәм, күз ачып йомганчы күтәреп, әйләндереп салып та куйды. Бу шулкадәр тиз, шулкадәр чиста эшләнде, егетнең әшнәләре дәгъвалашырга да өлгерә алмый калдылар.

Мәйданны бозып, уртага ташланган халык Арсланны күккә чөйде, тавыш көчәйткеч аның магнитофон белән бүләкләнүен хәбәр итте...

Кояш баеп, юлга кузгалган атларның дугаларында кыңгыраулар шылтырый башлагач, кайтырга чыктылар. Сабан туе көрәшенең аерым эпизодларын рәхәт бер елмаю белән күз алдына китереп, көлешә-көлешә кайтып килә иде. Инде Сарманнан ун чакрымнар чамасы ары кигкәннәр иде, кинәт, җир астыннан чыккандай, җан-фәрманга чабып, бер ат йөге егетләр килеп чыкты да, эшлияле-чуклы, кыңгыраулы атны машинага аркылы китереп куйдылар.

Атнабай «алмачуарын» туктатырга мәҗбүр булды. Арслан машина ишегеннән башын тыгып:

— Нәрсә бар, егетләр? — диде, хәлне аңламыйча.

Арбадан бер егет төште.

— Батыр кайда?

— Нигә?

— Кем дип сорыйм!

— Мин.

— Чык монда. Сөйләшәбез.

Арслан, сабыр гына, машинадан чыкты. Эшләрнең юньле булып бетмәсен аңлаган Атнабай, Саша белән Габделхәйгә ымлап:

— Салават токымы, көрәшкә әзерләнә! — диде, ә үзе әллә ни арада, пәке алып, ат башына чыгып басты.

Габделхәй белән Саша Арсланның ике ягына бастылар. Сәгыйдә, куркып, өнсез калды.

Арбадан төшкән егетнең кепкасы кырын, күзләре мыскылчан, кепка астыннан бер көлтә чәче бүлтәеп чыккан һәм кыяфәте исерек иде. Сул аягын алга куеп, біленә таянды:

— Нишләп син безнең авыл егетенә ектырмадың? Акча кызганырлар дип курыктыңмы? Хәзер без синең сөягеңне капчыкка тутырып җибәрәбез.

Атнабай сиздерми генә үз эшен эшли: камыт бауларын кисә иде. Эшлисе эшен эшләп бетергәч, ул, вакыт җиткәнне белдереп, башкортча җыр җырлый башлады һәм атның корсак астына типте. Шул минутта ук ат тәртә арасыннан ычкынып, кешни-кешни кырга чыгып чапты.

Габделхәй белән Саша каршыларында киерелеп торган егетне икесе ике ягыннан тотып, читкә алып куйдылар да, әле ни булганын абайламыйча, аптырашып, арба өстендә бер-берсенең җилкәләреннән кочаклашып утырган егетләрне арбасы-ние белән аударып җибәрделәр.

Бюроны Корбанов булмәсенә җыйганнар иде. Ишекне ачып җибәрүгә, Арсланның күзенә ташланган беренче күренеш — кабинеттагы халыкның күплеге булды. Ул аларның барысын бер итеп, үзен ялгыз итеп тойды. Аның сәламенә салкын гына җавап кайтардылар. Фәкать ике кеше — Нәҗип Корбанов белән Лотфулла Дияров кына адәм рәтле исәнләштеләр.

Өйләреннән тыныч күңел белән чыккан иде Арслан. Аның тәртибенә нинди бәя бирәләр, эшләгән эшләренә ничек карыйлар, бу аның өчен барыбер, чөнки ул тормыш принцибы итеп иң әүвәл үз намусы алдында чиста булуны куя иде. Ләкин менә хәзер, бюро членнары җыелган кабинетка килеп кергәч, аннан да бигрәк аларның тыенкы-салкын карашлары белән очрашкач, ул каушый төште, күңел ныклыгы кимегәндәй булды. Утырыр өчен урын эзләп, як-ягына карангалап алды. Лотфулла агай, кул изәп, аны үз янына чакыра иде — күңеленнән картка рәхмәт әйтеп һәм бөтен ихтыярын аякларына туплап, нык адымнар белән шунда таба юнәлде.

Корбанов аяк өсте басты, күзлек киеп, ниндидер кәгазьне карады.

— Килер кеше килеп бетте шикелле, иптәшләр. Башласак та ярый торгандыр,— диде ул һәм көн тәртибендә Яңа промыселлар идарәсе начальнигы Арслан Гобәйдуллинның персональ эше каралачагын хәбәр итте.

Арслан аның күзләре бимазалырак икәнен, тавышында ныклык булмавын сизеп алды. Чыннан да, Корбанов тыныч түгел, Гобәйдуллинның эше хакында ул төпле бер фикергә килмәгән иде әле. Күңеленнән ул аның намуслы булуына ышана иде. Ләкин гаепле кешене «кыл иләктән» үткәрүче җәмәгать комиссиясе Гобәйдуллинның алар белән сөйләшергә теләмәвен хәбәр итте. Бу исә эшне катлауландырып җибәрде, Корбановның Арсланга карата булган ышанычын киметә төште. Шуннан соң беренче секретарь Арслан белән дә, Гозәеров белән дә, Арслан эшенә кагылышлы башка кешеләр белән дә аерым-аерым сөйләште. Сөйләште һәм канәгатьсез калды. Гобәйдуллин да, Гозәеров та, келәм вакыйгасын яшермәделәр, тик икесе ике төрле аңлаттылар. Корбанов келәмне тикшерү өчен ОРСка инструктор җибәрергә мәҗбүр булды. Тикшерү нәтиҗәләре әле билгеле түгел иде. ОРСтан бюрога кадәр материалларны әзерләп бетерербез, дип ышандырдылар.

Бүгенге бюроны җыюдан Корбанов үз алдына зур бер максат куйды: җаваплы урыннарда эшләүче өч коммунистның — шәһәр комитеты секретаре Мөстәкыймовның, промыселлар идарәсе начальнигы Гобәйдуллинның, ОРС начальнигы урынбасары Гозәеровның нинди кешеләр булуын ул, ниһаять, ачыкларга тиеш.

Бюроны персональ эш белән Мөстәкыймов таныштырды. Гобәйдуллинны ул өч нәрсәдә гаепләде. Беренчесе — идарә башлыгы, эш урыныннан файдаланып, ОРС складыннан келәм китерткән. Икенчесе — АТК шоферын, беренче тәртипсезлек эшләү белән үк, эшеннән кудырткан. Өченчесе — Сарман юлы өстендә сугыш оештырган. Боларның барысыннан да бер нәтиҗә килеп чыга: коммунист Гобәйдуллин узынган, коллектив фикерен тыңлаудан туктаган, самосуд ясарга керешкән.

Гаеп зур иде — бюро членнары тынып калдылар.

— Фактларны раслыйсызмы, иптәш Гобәйдуллин? — диде Корбанов.

— Әйе, факт буларак дөрес болар,— диде Арслан һәм шундук кабинеттагы кешеләрнең, бик нык гаҗәпләнеп, үзенә таба борылып карауларын күрде.

— Ә сез, иптәш Гозәеров, келәм фактын раслыйсызмы?

— Раслыйм, миннән көлделәр, мине мыскыл иттеләр,— диде Гозәе-

ров. Ул, ашыгып, урыныннан торды, аның мыеклы чибәр йөзе мунчадан чыккан кебек кызарды.

«Ник мин аны судка бирмәдем икән? — дип, үртәнеп уйлады Арслан.— Хәер, кем уйлаган аның шундый оятсыз булырын. Күр дә тор, судан коры чыгар өчен ул минем өскә чүп өя башлар әле. Ә Мөстәкыймовка шул гына кирәк тә, ул, мөгаен, Гәрәйшин кандидатурасының идарә парткомына үтми калуы үчен ала торгандыр...»

— Ягез, иптәшләр, кемнән башлыйбыз? Сез сөйлисезме, Арслан Шәвәлиевич? — диде Корбанов.

— Мин Ислам агайны тыңларга телэр идем.

Гозәеров, кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып, тирләгән маңгаен сөртте, баскан урынында таптана башлады.

— Мин болай күңелсез хәл килеп чыгар дип башыма да китермәдем. Мин Арслан Шәвәлиевичны ихтирам итәм. Аның намусына ышанып йөрдем.— Гозәеров тотлыгып торды, Арслан ягына карамаска тырышты.— Юк, ул... ул әйбәт эшләмәде, мине хурлыкка калдырды, мин олы башым белән...

— Мәсьәләгә якынрак килегез,— диде Корбанов, тыныч кына.

— Мәсьәләгә якын килергә була. Әйе, мин мәсьәләгә якын килеп әйтәм: факт дөрес. Ул миңә ничек булды... Үзегезгә мәгълүм, иптәш Гобәйдуллин зур урында эшли бит инде, минем өстән баш дигәндәй, ни кылыныйм дисә, үз кулында, аның какрас кырык яше тулып килгән чак иде, кырык яшь кеше тормышында кечкенә дата түгел, үзегезгә мәгълүм, истә кала торган дата; мин уйладым, ул, ягъни Арслан Шәвәлиевич, туган көне хөрмәтенә келәмле булып калырга тели икән дип. Келәм, әлбәттә, кирәк нәрсә, үзегезгә мәгълүм, Арслан Шәвәлиевич, зур урындагы кеше, анар кунак-төшем килми тормый, Мәскәвеннән дә, Казаныннан да түрә-кара килеп тора, келәмле йортка кунак кабул итү күңелле хәл бит инде...

— Мәсьәләгә якынрак килегез,— диде Корбанов, икенче тапкыр.— Келәм китерергә дип Гобәйдуллин сезгә үз теле белән әйттеме?

Гозәеров тагын югалып калды, Арслан ягына карамаска тырышып:

— Әйе, ни... ничек әйтергә сезгә? Үз теле белән, конешны...

— Әйткән көнен хәтерләмисезме?

Гозәеров уйланып торды.

— Әйткән көнеме? Әйткән көне-ее... Хет үтер, хәтердә калмаган...

— Февраль аенда түгел идеме? — дип, анар ярдәмгә килде Мөстәкыймов. Гозәеров, батып баручы саламга тотынгандай, шундук аның сүзләрен эләктереп алды.

— Әйе. Бик дөрес. Нәкъ февраль аенда, рәхмәт, Камил Сәләхович.

— Туган көнегез февраль аендамы, Арслан Шәвәлиевич?

— Февраль аенда,— диде Арслан.

Бюро членнары бер-берсенә карашып алдылар.

— Иптәш Гобәйдуллин, сезгә сүз бирелә.

Арслан, чигәсенә шаулап кан йөгергәнен тоеп, урыныннан торып басты.

— Минемчә, Ислам агай бер нәрсәне бутый. Февраль аенда минем аңар һич әйтүем мөмкин түгел. Февраль аенда мин Мәскәүдә завод проектын раслату артыннан йөрдем.

Кешеләр тагын бер-берсенә карашып алдылар. Мәзәк сүзгә һәм трибунадан речь сөйләргә гаять тә оста булуы белән танылган Мигайфер, нефть берләшмәсенең баш инженеры:

— Миңа бер сорау бирергә мөмкинме? — диде.

— Бирегез, бир,— диде Корбанов,— рөхсәт сорап тормагыз.

— Иптәш Гобәйдуллин, әйтә алмассызмы,— диде Мигайфер, каты бәдрә чәчен каршыга сыпырып.— Туган көнегездә кемнәр булды һәм нинә котлау телеграммасы алдыгыз?

Мөстәкыймов кешеләрнең елмая башлавын тоеп:

— Григорий Исакович, шаярту урынлы түгел,— диде.

— Минем шаяртырга уйлаганым да юк. Моны белү бюро өчен мөһим.

Арслан баскан килеш тора иде әле.

— Бер телеграмма да алмадым. Минем туган көннәр үткәрү гадәтем юк,— диде.

Кабинетта утыручылар — күбесе Арсланны эш буенча якыннан белүчеләр — күңелләреннән барлап чыктылар, чыннан да, аларның беркайчан да Арслан Гобәйдуллинда кунакта булганнары юк, алар аны аскет дип, чамадан тыш коры, күңелсез яшәүче дип уйлыйлар иде.

Камилнең ачуы чыкты. Кара син аны, Гобәйдуллин ничек кылана, исе китмәве белән җиңмәкче. Имеш, ул хаклы, шуңа күрә тыныч...

— Иптәшләр, без мәсьәләнең зурлыгын, җаваплылыгын аңламыйбыз,— диде Мөстәкыймов, тиз генә урыныннан торып. Моңарчы ул утырып сөйләшкән иде.— Тагын бер тапкыр әйтәм, мәсьәләнең зурлыгын аңламыйбыз. Менә безгә, иптәш Гобәйдуллин әйтсен, аның өенә келәм килү факты дөрес түгел, дисен. Дөрес бит? Аның өеннән Гозәеровны биш пот авырлыгындагы келәмне күтәртеп җибәрү факты дөрес түгел, дисен. Дөрес бит?

Корбанов, алдында яткан кәгазьгә плюс-минус билгеләре сыза-сыза:

— Камил Сәләхович, иптәшләргә әйтеп бетерергә ирек куйыйк,— диде.

Мөстәкыймов ашыгыбрак торуын, вакытсыз ярсынуын аңлап, урынына утырды. Бүтән дәшмәде. Бюро членнары да тынып калдылар. Мондый чакта шәһәр советы председателе Шафоновның коткара торган гадәте бар иде. Бөтенләй көтелмәгән сүзне әйтеп, бәхәсне ул бүтән якка борып җибәрә белә иде. Корбанов үзеннән ерак түгел, ике урындыкны биләп утырган юан гәүдәле, куш иякле Шафоновка таба ашыкмый гына башын борып, шәһәр башлыгының томан белән өретелгән йомшак карашлы соры күзләренә төбәлде. Шафонов үзенә чират житкәнне шул караштан аңлап, урындыгын шыгырдатып, аяк өсте күтәрелде.

— Мәсьәлә ачыклана башлады шикелле,— диде ул, карлыккан калын тавыш белән. Оеган аркасын язу өчен артка кайшала биреп, кулы белән ышкып торды.— Келәмнең килү факты дөрес. Ике як та моны инкарь итми. Келәмнең китү факты шулай ук дөрес, монысын да иптәшләр инкарь итмиләр. Димәк, җәмәгать милкен үзләштерүдә Гобәйдуллинны гаепли алмыйбыз. Логика буенча алга таба китик: келәмнең бәясе ничә сум тора?

— Биш йөз дә житмеш бер сум,— диде Гозәеров, тиз генә.

— Әһә. Шуның күпмесен арзанайтырга теләде Гобәйдуллин?

— Ике йөзен...

— Сез, иптәш Гозәеров, версиягезне ахырынача уйлап житкермәгәнсез. Ике ел буена завод салырга, промыселлар идарәсендә яңалыклар кертергә ашкынып йөргән кеше ике йөз сум белән вакланамы? Мин менә хәзер үземне Гобәйдуллин урынына куеп карадым. Нигә миңа келәмне арзанрак алырга? Алгач, алгач, мин аны бөтенләй бушлай алыр идем. Списать итә аласыздыр бит сез аны?

— Алабыз,— дип әйткәнен сизми дә калды Гозәеров.

— Гобәйдуллинны мин биш ел буена беләм. Шәһәр халкының яртысы бакча утыртты, йортлар салды. Мин аңар тәкъдим итеп карадым — якын да килмәде.

— Шулай да аның бакчасы бар, йорты да бар,— диде Мөстәкыймов.

— Дөрес әйтәсез, Камил Сәләхович! — Шәһәр башлыгы Мөстәкыймовның сүзен тыныч кына ялгап алып китте.— Ләкин нинди бакча соң

ул? Мин, алга таба да, шәһәр тирәсендә бакчалар булдыру, дача йортларын типовой итеп эшләтү нияте белән, коллектив бакчаны карап кайттым. Анда да әйбәт кенә йортлар бар. Кстати, бик мул итеп салынган. Без материал бирмәсәк тә, каяндыр табалар кешеләр. Шунда мин эт оясы хәтле генә бер будка күрдем. Монысы кемнеке дип сорагач, каравылчы әйтте, Яңа промыселлар идарәсе начальнигыныкы, бакча ямен җибәреп тора шунда, әйтегез әле, я җүнлерәген салсын, я сүтеп ташласын, диде. Менә шул, иптәшләр, мин Арслан Шәвәлиевичның арзан хакка келәм алырга теләвенә, бигрәк тә аны сәүдә работнигыннан өенә китертүенә ышанмыйм. Кешесе ул түгел!

Кешеләр җиңел сулап, селкенешеп куйдылар.

— Александр Петрович, конкрет тәкъдимегезне әйтмәдегез бит әле,— диде Корбанов, шәһәр Советы председателе урынына утыра башлагач.

— Әһә. Гафу итегез. Конкрет тәкъдимгә кадәр минем бер соравым калган икән әле. Иптәш Гозәеров, сез минем янга ОРС начальнигы булу теләге белән киңәшкә килгән идегез. Мин сезгә иптәш Гобәйдуллинга барырга киңәш иткән идем. Ничек булып бетте ул сөйләшүегез?

Гозәеров, битенә ут капкандай, кып-кызыл булып кызарды, сүзен өзеп кенә әйтә алмады.

— Арслан Шәвәлиевич, килдеме сезгә иптәш Гозәеров? — диде Шафонов, соравын ачыкларга теләп.

Арслан да уңайсызланып калды.

— Мин ул хакта әйтергә теләмәгән идем. Эшләр болайга киткәч, әйтми булмый инде. Ислам агай миннән шул турыда сорарга килде. Ә келәмне ул шуннан бер көн элек, мин Мәскәүдә чакта, китереп куйган иде. Мин аны келәме-ние белән куып чыгардым.

— Дөресме? — диде Корбанов, Гозәеровка туры карап.

Гозәеров эшнең бик кискен борылыш алуын аңлап, бәлагә тарудан коты алынып:

— Дөрес түгел! — диде. Моны ул Корбановка туп-туры карап, нык тавыш белән әйтте. — Гобәйдуллин миңа келәм китерергә кушты һәм мин китердем.

— Сез моны чын күңелдән, ышанып әйтәсезме?

— Мин булганны сөйлим. Һәм сезнең Гобәйдуллинны яклаячагыгызны белеп сөйлим.

— Ни өчен без Гобәйдуллинны якларга тиеш?

— Мин кем дә, Гобәйдуллин кем? Минем урынга горком бүген үк бер дистә кеше таба ала. Ә Гобәйдуллин — номенклатурный работник.

— Яхшы. Димәк, сез келәмне Гобәйдуллин үзе китертте дисез?

— Үзе китертте!

Корбанов кыңгырауга басты. Ишектән вак-вак атлап секретарь кыз Әнисә килеп керде.

— Сеңелем, инструктор Шәфиков андамы?

— Әйе. Көтеп утыра.

— Әйтегез әле, керсен.

Әнисә чыгып китүгә, чәчләрен кулы белән баскалап, җыйнак тыгыз гәүдәле, җиңнәрен сызганып куйган ак күлмәкле егерме биш яшьләрендәге егет килеп керде.

— Иптәш Шәфиков,— диде аңар Корбанов, дулкынланып,— тикшерү нәтиҗәсен бюрога хәбәр итегез.

— Инвентарь исемлегендәге 307 номерлы, биш йөз дә житмеш бер сумлык келәм бер йөз сумга төшерелеп списать ителгән. Складта хәзер ул келәм юк. Склад мөдире келәмне иптәш Гозәеровның үзенә алып китүен раслады. Менә белешмә,— диде Шәфиков һәм, кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарып, Корбанов өстәленә китереп салды.

— Рәхмәт, иптәш Шәфиков. Сезгә бүтән йомыш юк.

Корбанов инструкторны яктыра төшкән күзләре белән озатып калды да авыраеп урыныннан күтәрелде, өзеп кенә әйтте:

— Мәсьәлә ачыкланды, иптәшләр. Гозәеровның эшен махсус тикшерүгә куябыз. Аның белән ОРС партоешмасы аерым шөгыльләнер. Каршылар юкмы? Хәзер тәнәфес ясап алырга дигән тәкъдим бар.

Кешеләр, буасы ерылган елгадай ташып, шаулап ишектән чыга башлагач, Корбанов Мөстәкыймовны үз янына дәшеп алды.

— Камил Сәләхович, бер генә минутка калыгыз әле.

Мөстәкыймов чыга башлаган җиреннән кире борылды.

— Моны ничек аңларга, Камил Сәләхович? Утырыгыз, утыр. Сез нигә эшне җентекләп тикшермәдегез? Нигә бюрода агрессив юл сайлап алдыгыз? Әгәр инструктор списать ителгән келәм квитанциясен тапмаган булса, Гобәйдуллин акллануны түбәнлеккә санап, дәшми калса? Без нишләр идек? Гобәйдуллинны партиядән чыгарып ташлар идекме?

Корбанов ачуланмады да, тавышын да күтәрмәде, әмма Мөстәкыймов нибары ярты минутлык сөйләшү вакытында аркасының тирләп чыкканын, башы әйләнә башлавын тойды.

Бюроның калган ягы тагы да шау-шулырак узды. Мөстәкыймов, беткән баш беткән дип, Гобәйдуллинның партизанчылыгына, самосуд ясавына ябырылды. Шофер Дугинцевны эштән кудыртуны ул демократияне кысу, эшчеләр интересы белән исәпләшмәү дип бәяләде, Корбанов исә аны туктатмады. Үзе белән бергә эшләүче секретарьның никадәргә барып җитә алуын белергә тели иде ул. Менә шунда бюро кинәт икегә бүленде. Берәүләр Мөстәкыймовка кушылып, идарә башлыгына дипломат булырга, таякны шарт урталай сындырмаска кирәген әйттеләр, икенчеләре кискен чаралар күрү ягын яклап чыкты. Шофер Дугинцевны эштән чыгару кебек хосуси факт кинәт җитәкчелек стиле турында бәхәскә әйләнеп китте.

— Мин беләм, иптәш Гобәйдуллин партизан булган кеше, сугышта, дошманга каршы көрәштә, бәлки, партизанчылык бик яхшыдыр, иптәш Гобәйдуллинның ул эшчәнлеге өчен орденнары да бар, мин аның биографиясе белән җентекләп таныштым, әмма монда, үзебезнең эшче туганнарыбыз белән партизанча көрәшү бернинди киртәгә дә сыймый, гуманлык тойгыларына, тәрбия принципларына каршы килә,— дип, кайнарланып сөйләде Мөстәкыймов.— Безгә социалистик производство җитәкчесе нинди булырга, аның эш стиле нинди булырга тиеш дигән зур һәм катлаулы мәсьәләне ачыкларга кирәк. Америкада, мәсәлән, идарә башлыкларын әзерләүче, эшчеләр белән ничек мөгамәлә кылырга өйрәтүче махсус институтлар бар. Мин, әлбәттә, капиталистлар моны гуманистик караштан чыгып эшлиләр дип әйтергә теләмим, сарык белән бүре беркайчан да дус була алмый. Капиталист үз табышын арттыру интересын алга сөрә. Ләкин ни генә булмасын, ике антогонистик сыйныф яшәгән илдә дә производство командиры эшчеләр белән дус булырга омтылганда, алар белән «кешечә» мөнәсәбәтләр урнаштырырга тырышканда, безгә, совет җитәкчеләренә, дорфа булу, самосуд белән шөгыльләнү бер дә килешми, бу безне түбән төшерә һәм эшчеләрдә совет властеның гаделлегенә карата шикләнү тудыра.

«Демагогия белән шөгыльләнә. Гаделлек маскасына төренеп эш йөртә. Беренче ялгышыбыздан да сабак алмаган икән»,— дип уйлады Корбанов. Камилнең искергән алымнар белән эш итүе, эшнең асылына төшенергә теләмәве аны бик нык борчый башлады. Бюро членнары да нигә кирәк бу кадәр буш сүз дигәндәй, селкенешеп куялар, көрсенәләр иде.

Мөстәкыймов сөйләп бетергәч, Лотфулла агай сүз сорады. Корбанов аңар утырып сөйләргә дә мөмкин икәнен әйткән иде.

— Юк, мин үземне әйбәт сизәм әле,— дип, чаларган мыегы астыннан сизелер-сизелмәс кенә елмаеп, сүз башлады Лотфулла карт.

Барысы да ихтирам белән аның нәрсә әйтәсен көтә башладылар. Нефть эшендә озак еллар эшләгән булуы, алтмыш биш яшен тутырып килүе — кешеләрдә аңар аеруча бер хөрмәт уяткан, аннары аның картлык зирәклеген, сөйләсә, буш сүз сөйләмәвен беләләр иде.

— Минем дә бар иде яшь чагым, битем дә болай җыерчыклы түгел иде, мыегыма да чал төшмәгән иде. Ут кебек җирән мыеклы идем мин. Тиргәшә башласам, авызымнан утлар чәчә торган идем. Менә мин Камил туганның калай самавыр кебек кайнап-кайнап сөйләвен тыңлап утырдым да, хәйран тамаша аптыраштa калып, үз алдыма шаккатып уйлыйм: их, кая китте синең яшьлегең, кая китте синең, Лотфулла, арслан киек тотардай, авызыңнан ут бөркеп торган заманнарың, дип уйлыйм. Әйе, яшьлек — матур вакыт, гомереңнең алтын чагы, һич сүз әйтмим, ләкин без кирәкмәгән сүз белән мавыгабыз түгелме? Минем әти әйтә торган иде, кибәннең әйләнәсендә йөрмәгез, кибәннең эченә кереп карагыз, ди торган иде. Кибәннең тышы бик матур булырга мөмкин, әмма кибәннең эченә башыңны тыгып карасаң, аның кызып, бурсып, күгәреп ятуы мөмкин. Менә шофер Дугинцев мәсьәләсендә дә уйлап утырам, кибәннең эче хуш исле яшел печәнме? Әллә бурсып, күгәреп яткан тиресме? Шоферга зур эш тапшырганнар, операторларны ул вахтадан ташырга тиеш. Көннең көн буе эшләгән оператор тирләгән, арыган, тиз генә өемә кайтып җитим, җылы ашымны ашыйм да кечкенә мәктәбемә, я булмаса, хатыным белән кино-мазарга барып кайтыйм дип уйлый. Шундый изге ният белән юлга чыга. Чыкса, юлда беркем дә юк. Хуш. Бер сәгать көтә, ике сәгать көтә, юк шофер. Операторлар шоферны гаепләми, юк, Камил туган, нәкъ әнә сез әйткәнчә, совет властен сүгә башлый, властьның эшләгән бер эшендә гаделсезлек күрә башлый. Егерме операторны ике сәгать буена юл өстендә суыкта бастырып тоту — бу җинаять. Һ мин икеләнми әйтәм — Дугинцев җинаятьче. Ул моны белеп, безнең йомшак күңеллелеккә таянып эшли. Белмәскә, аңсыз кеше түгел ул, урта мәктәп бетергән, ун класс белеме бар. Белә торып эш урынын ташлаган, акча күрәп алырга, Чупай карьерыннан кемгәдер таш алып кайтырга китеп барган. Әгәр идарә башлыгы аның аңлы рәвештә эшләгән этлегенә җиңел генә үткәреп җибәрсә, башыннан сыйпап: ай-һай, начар эшләдең син, Коленька, икенче алай эшли күрмә инде, яме, дип, арыш боламыгы изә башласа, нефтьче операторлар Гобәйдуллиннан йөз чөергән булырлар иде. Бер түгел, егерме кеше була бит ул чакта властька рәнҗүчеләр. Пример өчен әйтик, менә мин, эшче кеше, көнемне-төнемне белми, ил өчен файдалы эш эшлим икән, совет властеннан үземә кирәкне таләп итәргә, минем мәнфәгатемә кыек китерүчеләргә җәза бирүне сорарга полный хакым бар. Һ мин үземә тиешлене алырга тиеш...

Мөстәкыймов Лотфулла картның сүзләрен никадәр сабыр тыңларга тырышса да, булдыра алмады, боларның барысын үз бакчасына таш ату дип аңлап, кисәк кенә кабынып китте:

— Сез, Лотфулла Диярыч, Совет властеннан алу турында күп сөйләдегез. Безгә бүген Совет властена бирү турында сөйләргә кирәк. Менә булырбыз җитәкчеләр.

Лотфулла карт, гаҗиз булгандай, бер генә мизгелгә сүзсез калды. Мөстәкыймовның авыр карашлы чиста зәңгәр күзләренә, сакал урыннары пөхтә итеп кырылган йомры яңакларенә күз сирпеп алды да берлинди ачусыз, ләкин үзәккә үтәрлек итеп:

— Соңгы сүзне әйтергә мәҗбүр итәсең син, Камил туган,— диде.— Бирү турында мин түгел, син сөйләргә тиеш. Мин Совет властена биш егет үстереп бирдем. Бишесе биш якта ил хәзинәсен арттыралар. Мин Совет властена ике йөз унбиш скважина бораулап бирдем. Ә син нәрсә бирдең? Син әле алдың гына. Син урта белем ал-

дың — түләүсез. Син югары белем алдың — түләүсез. Син горком креслосы алдың... кһм... менә шулай, туган. Син мине тыйнаксыз булырга мәҗбүр итәсең...— Картның кинәт тавышы өзелде, тамагына төен килеп тыгылды һәм ул, сүзен әйтеп бетерә алмыйча, лып итеп урынына утырды.

Кабинетта кинәт кабер тынлыгы урнашты. Барысына да уңайсыз булып китте. Шәһәр советы председателе Шафонов, көрсенеп, авыр гәүдәсе белән урындыгында кыймылдап куйды, бу нинди тактсызлык дигәндәй. Мөстәкыймовка шешенке күз кабакларын күтәреп, кырыс караш ташлады. Башкаларның да күңеле кузгалган, ярсынуларын көч-хәл белән тыеп утыралар иде.

Корбанов хәлне аңлады. Сөйли торгач, китереп житкерде Мөстәкыймов. Нервыларны тынычландырырга, хәлне ачыкларга кирәк. Ул аяк өсте басты, әкрен, ләкин аңлаешлы итеп:

— Гафу итегез, Лотфулла агай,— диде.

Тагын бер тәнәфес ясамый булдыра алмадылар. Корбанов карт мастерны култыклап читкәрәк алып китте. Мөстәкыймовның уйламый әйтелгән репликасы өчен янә бер мәртәбә гафу үтенде. Дияров аны башын селкеп тыңлап торды.

— Картайдым, Нәҗип туган, картайдым. Син инде мине, зинһар, гаеп итмә. Нервылар бер тиенгә дә тормый,— диде ул, борчылып.— Мин кайтыйм әле, булмаса. Тәүфика әйткән иде аны, йөрмә кеше көлдереп, синнән башка да ерып чыгарлар әле, дигән иде. Кайтыйм әле мин, кәеф бик әшәке, тере жылан йоткан кебек кәеф...

— Ярый, Лотфулла агай, борчылмагыз, сез гыйбрәтле сүз әйттегез,— диде Корбанов, чын күңелдән.— Без бит китап сүзләре сөйләргә өйрәнгән халык, һич котылып булмый шул чирдән.

Бюроның калган ягы күңелсез үтте. Картның бюрода калмавына үзләрен гаепле санап, уңайсызланып утырдылар. Мөстәкыймов кына иреннәрен кысып, кулы белән иягенә таянып, төз утыра иде.

Сарман юлында булган хәлне Арслан үзе сөйләп бирде, әш ничек булган — берсен дә яшермәде. Аның сабан туенда батыр калуына елмаештылар, арба аударуларны сөйләгәндә йөзләре караңгыланды.

Корбанов тәкъдиме буенча Гобәйдуллинга Сарман вакыйгасы өчен шелтә бирделәр. Моңа сөенүче дә, кайгыручы да булмады диярлек. Күңелләрендә һаман карт мастерның рәнжеше утырып тора иде әле.

Бюроны ябар алдыннан Шафонов сүз сорады. Аның кыяфәте кырыс, чырае бик житди иде. Бюроны тиешенчә әзерләмәгәне һәм Гозәеровны яклаганы өчен, ул Камил Мөстәкыймовка да шелтә бирергә дигән тәкъдим ясады.

Аның белән килештеләр. Килешми мөмкин түгел иде.

«Мөстәкыймов үзен ачты бүген,— дип борчылып уйлады Корбанов, соңгы кеше булып кабинеттан чыгып барганда.— Мин-минлеге дә зур икән. Кешенең кем икәнен белергә бер минут та житә шул. Алга таба бергә эшләве кыен булыр...»

## 4

Бер атнадан Корбановка Зозуля шалтыратты. Секретарь трест управляющиеның гадәттәге көйле тавышын ишетергә һәм озаклап хәлэхвәл сорашуны тыңларга җыенган иде, тик бу юлы алай булып чыкмады, Митрофан Апанасович сүзне бик кырт кисеп башлады:

— Нәҗип Мохтарович, сез минем картны нишләтеп кайтардыгыз?

— Кайсы картны?

— Оста Лотфулланы. Бюро утырышыннан кайтканнан бирле сөйләшергә дә теләми. Безгә аны тиздән пенсиягә озатырга кирәк. Юби-

лейга әзерләнәсе бар. Алтмыш биш яшь уен түгел. Ә ул юбилей турында сүз кузгаткач, бөтенләй сырт йоннарын кабартты.

— Нәрсә ди, үткәрмим димә? — Корбанов трубкага елмайды.

— Якын да килми. Үз өемдә, үз семьям белән чүкердәшеп кенә утырам. Мәшәкатьләнеп йөрмәгез, бер кая да бармыйм. Куйбышевтан иске дустым, укытучым Константин Феонич килсә, шул житкән, ди. Тегеләй дә сөйләшеп карадым, болай да... Шундый көйле карт иде. Чыннан да, сез аны нишләтеп җибәрдегез?

— Без аның кәефен кырдык, Митрофан Апанасович. Кәефен кырдык, дим. Картайгач кеше сабый бала кебек: аздан гына хәтере кала, аздан гына күңеле була. Ярый, борчылмагыз, рәтләргә тырышырбыз. Тиздән аңар Герой бирергә тиешләр, обкомнан белештем — документлары Мәскәүдә...

Бер атнадан соң Зозуля тагын шалтыратты.

— Киңәш бир, иптәш секретарь, нишлим?

— Нәрсә бар?

— Һаман шул инде — юбилей мәсьәләсе.

— Әле һаман да киреләнәмени?

— Категорически каршы.

— Соң үзе теләмәгәч, ясамабыз.

— Анысы шулай да... Без бит аны тәрбия чарасы булыр дигән идек: күрсен яшьләр карт гвардияне. Алтмыш биш яшенә тикле хезмәт постында калу, ул бит, беләсеңме...

Корбанов, телефон трубкасын кулына кыскан килеш, уйланып торды.

— Минемчә, бер котылу юлы бар монда. Аның туган көне кайчан әле? Ничә көннән диюем?

— Тугыз көннән.

— Шул вакытка скважинасын бораулап бетерәме?

— Бетермәс шул. Ә нигә?

— Бетертергә кирәк. Нәкъ шул көнне, скважина бетерү сылтавы белән, һәммәбез бергә җыелып барабыз да, бәйрәмне туп-туры кырда, буровой янында үткәрәбез. Синеңчә, ничек?

— Яхшы идея. Әле беркайчан да андый юбилей үткәргән юк. Хәзер үк боерык бирә башлыйм.

— «Татнефть» бүләк әзерлиме?

— «Волга» вәгъдә итәләр.

— Вәгъдә — шәп нәрсә. Коры сүз булып кына калмасын. Үзең белеш, Митрофан Апанасович, тикшереп тор. Башка якларын мин кайгыртырмын.

— Ну, добре, яхшы уйлап таптың, Нәҗип Мохтарович,— диде Зозуля, йомшак калын тавышы белән гөлдерәп.

Лотфулла агай бу хакта үзе белми иде әле. Көн саен ул буровоена бара, буровоеннан кайта, бригада егетләренең ихтирамлы, якты карашларын күрә һәм аңар ул мөнәсәбәттән рәхәт тә, бераз гына моңсу да була иде. Моңсулыгы шуңа — озакламый ул алардан аерылачак. Аның өстенә теге көнне бюро утырышында килеп чыккан күңелсезлек, Мөстәкыймовның йөрәк багыренә кадап әйткән сүзләре аның күңелен әрнетеп тора, карт үзен бик алама хис итеп, тырышканнарым бушка булды микәнни дип, үкенә башлаган иде. Ул бит гомерен «жир боруга» бирде, күпме йокысыз төннәрен шуңа багышлады. Инде ялга китәр алдыннан гына әйтсеннәр, имеш, илгә нәрсә бирдең, дисеннәр. Үзенә булсын, мал-мөлкәтем күп булсын дип тырыштымы ул? Дан-шөһрәт дауладымы? Кемнәрдер бәхет-бәхет дип гвыз суларын корытканда, газит битләрендә журналистлар, галимнәр, хәзерге заман яшьләре бәхет хакында олавы-олавы белән сүз сөйләгәндә, ул шыпырт кына үз эшен эшли бирде, бу аның буш бәхәсләргә җавабы иде. Аның өчен бәхет

бик тә гади: жаның теләгән эш, жылы куыш һәм киң күңел. Шуннан башка аңар берни дә кирәкми.

Алтмыш яше тулар алдыннан Зозуля, ул чакта әле контора директоры, аны үзенә чакырып алып, пенсия турында сүз кузгатып карамакчы булган иде.

— Хөрмәтле Лотфулла Диярыч, син моңарчы хезмәт постында нык тордың. Кырык ел буена армый-талмый, ыңгырашмый-зарланмый зур йөкне тартып бардың. Арыгансыңдыр инде, мөгаен. Ял да итәсең киләдер, балаларыңның сый-хөрмәтен күрергә зарыккансыңдыр. Яз син безгә гариза, һәм без сине тиешле-тиешенчә олылап, персональный пенсионер ясап куйыйк. Карчыгың Тәүфиканы култыгыңа кыстырып, курортлардан-курортларга йөреп кара әле бер...

Лотфулла агай ул чакта ике сөйләшеп тормады:

— Юк, Митрофан,— диде,— минем үз үлемемә үз кулым белән имза куясым килми әле. Чыгарасыз икән инде, анысы сезнең иректә!— диде.

Шуннан соң ул тагын биш ел буена тәпкә җигелеп йөк тартты. Олыгая төшкәч, кыенрак килә икән, шулай да зарланмады, үзе егылган еламас дигәндәй, үзе сорап алды бит, берәү дә көчләмәде аны, берәү дә ирексезләмәде. Инде чама дигән нәрсәне дә белергә кирәк. Тормышның үз законнары бар: аларны син төземәгән, син генә үзгәртә алмассың. Моңарчы ил-көн алдында ким-хур булып яшәмәдең, ялкау аты, булдыксыз даны күтәрмәдең, намусыңа каршы килмәдең, чәчрәп алга да чыкмадың. Җитәр. Яшьләр килә дөньяга, тормышның тоткасын алар кулына тоттырырга да узган гомереңнең истәлекләрен күңелдә яңарта башларга вакыт.

Пенсия көненә әзерләнә башлау Лотфулла агайның күңеленә бик нык кереп утырды. Аны көзге тожымнардай якты бер сагыш биләп алды. Эшкә киләме, вахта автобусында яшьләрнең гөр килеп сөйләшеп кайтуларын тыңлыймы, барысы аңар бер нәрсәне искәртеп торалар: синең монда килеп йөрер көннәрең санаулы гына калды. Газетада басылган некрологларны ул моңарчы укымаска тырыша, өлгерербез әле, дип уйлый иде. Хәзер аларны бик җентекләп укый, ләкин үзенең дә үлеме якынлашу турында уйлап түгел, эштән китәчәге турында уйлап укый иде. Бик тә сәер иде аның некрологларга мөнәсәбәте. Кемдер үлә, кемдер дөньядан китә, кемнедер җирлиләр, кабер өстенә чардуган коралар, баш очына йолдызлы пирамида утырталар. Аларга үлем кагыла, ә сиңа юк. Гүя син алар токымыннан түгел, үлем сине читләтеп узачак.

Аның юбилейны үткәрмәскә теләве дә үпкә-мазардан түгел (үпкәсен инде ул оныткан иде), ә картлыгын якынайтырга теләмәүдән иде. Теге көнне шәһәр комитетында Мөстәкыймовка ярсынып, үзе турында сүз әйтеп ташлавын да ул тыйнаксызлык дип саный иде. Шуңа күрә соңгы көннәрдә ул үзен бик нык кулга алып, бәйрәм турында сүз кузгата башлаган бораулаучыларын каты гына боргычлап, соңгы буровоена (соңгы диген, ә уйлавы ук әллә ничек!) билне буыбрак тотынды. Бу аның ике йөз дә уналтынчы буровое иде. Һәм рәхимсез сан нәкъ әнә шул түгәрәк булмаган җирдә өзеләчәк иде. Ярый, син дигән белән генә түгел, ике йөз дә егерме булса, ник утыз түгел, ник илле түгел, ди башларсың. Шул азаккы буровойны йөзгә кызыллык китермичә бораулап бетерергә дә, кырык биш еллык хезмәт стажыңны төйнәп куярга кирәк.

Август урталары иде. Лотфулла агай дүшәмбе көнне, ялдан соң нык күңел белән эшкә барырга чыкты. Ләкин ул, автовокзалга килгәч, аптырап калды: башка чакта аны төп-төгәл көтеп ала торган бригада бүген анда юк иде. Ичмасам, юри бер генә бораулаучы килсен лә! Мастер көтелмәгән бу хәлгә бик тә гаҗәпсенеп, мазутка буялып беткән

картузын артка чигереп, башын кашып торды. Автовокзалның эченә кереп, буфет тирәләрен урап чыкты. Анда да бригада юк; үзе белән бер мәйданда эшләүче мастер Шмаковтан да сорады, ул да бер сүз дә әйтә алмады.

Картның эченә пошаман төште. «Бу ниткән фокус тагын?» — дип уйлады ул, борчылып. Тагын бер ярты сәгатьләр чамасы көтеп, буровойга барының инде соңгы срогы да узгач, ул, башка бригадалар автобусына утырып, юлга чыкты.

Эш урынына житәрәк ул, чал кашларын жыерып, колакларын торгызып тыңлашып торды. Буровойдан бер генә тавыш та ишетелми. Кыңгыраулы мәйданына, урман эченә урнашкан буровой тып-тын иде. Мастер, автобус ишеге янындагы тимер тоткага тотынып, жиргә уңайсыз гына төште, болай да чиста күн итегенең башларын юл буендагы чирәмгә ышкып, беравык юанып торды, тирләгән, кызышып киткән башыннан картузын салып, ашыкмый гына буровой ягына юнәлде.

Агачлар сирәкләнеп, вышка күренгәч, ул тагын да ныграк гажәпләнде: буровой чыннан да эшләми, ә скважина янына бригада егетләре тигез бер саф булып басканнар. Максим Буянов әнә шул тигез саф каршысында йөренеп, кулларын бутап, нидер сөйли иде. Мастерны күргә кычкырып жибәрде:

— Бригада, смирно! Равнение на мастера!!

Картның соң дәрәжәдә гажәпләнеп, алар янына килеп житүе булды, әле генә үрә катып торган бригада кинәт чәчелде, сибелде, мастерны урап алды да, карт аны-моны әйтеп өлгергәнче, аны күтәреп алып, һавага чөеп жибәрде.

Лотфулла агайның үзе белән бергә картайган күн картузы жиргә очты, күн итеге эченнән чалбар балаклары чыгып, ботлары күренде, тыны кысылды. «Туктагыз, дим, шайтан балалары, туктагыз!» дип ялварып әйткән сүзләрен берәү дә ишетмәде, ишетергә дә теләмәде, ура кычкырып, ярсынып, чөя бирделәр. Жиргә соңгы тапкыр килеп төшүендә, аны кулларына тотып алып, аягына бастырдылар. Пөзе агарып, куркып калган карт, ниһаять, сүзен әйтер хәлгә килде.

— Бу нәрсә бу? Ни кылануыгыз!

— Кадерле Лотфулла Диярович! Без сине герой булуың белән котлыйбыз! — диде Максим Буянов.

— Нинди герой, ниткән герой? — диде Лотфулла ага, күзләрен йомгалап.

Һәркем тизрәк яңа хәбәрне әйтеп калырга ашыкты:

— Бүген иртән әйттеләр!

— Радиодан.

— Указ чыккан!

Котлау өчен, туганлык хисен, шатлык-сөенечне әйтү өчен мастерны уратып алып, аның кулын кысарга тотындылар.

Менә шуннан китте эшләр. Котлау буровойдан Дияровның өенә күчте, трестка, конторага, нефть берләшмәсенә күчте. Төрле яктан телеграмма ява башлады. Куйбышевтан, Сызраньнан, Бакудан, Урал якларыннан — Лотфулла агай озын гомерен кемнәр белән уткәргән, кемнәр белән буровой юлларында йөргән, кайларда бригадалар төзеп калдырган — барысы аны котлыйлар; моңарчы үз мәшәкатьләре белән яшәгән, онытылып барган кешеләрне бер документ, СССР Верховный Советы Президиумы Указы бер төбәккә жыйган — алар туганнары кебек якын итеп, Лотфулла Дияровны зурлыйлар иде. Дорогомиловтан килгән чәчәкле зур телеграмманы кулыннан төшермичә, әле русчалатып, әле татарчалатып карчыгына, Тәүфикасына аңлатты карт:

— Менә күрәсеңме, энисе, ишләгән минем картлач, нинәмә әкәмәтләр кыландырган; старикание, обнимаю, жму лапу, бесконечно раду-

юсь, дигән. Кысып кочаклыйм дигән, аңлыйсыңмы, шатланып бетә алмыйм, дигән.

Аның дулкынлануы Тәүфика түтигә дә күчте. Башта ул иреннәрен мылт-мылт иттереп торды да, яулык чите белән авызын каплап, елап жибәрде. Күз яшьләрен картына күрсәтүдән уңайсызланып, бер почмакка барып сыенды һәм, кечерәеп калгандай, үз алдына тынды.

— Әтисе, бу бит, ни бит... мин соң нәрсәләр әзерлим? Кайчанга әзерлим? — диде ул, хәл алгач.— Үзем генә әзерләп бетерә алырмын микән? Ичмасам, Фәйрүзә киленкәем дә юк бит. Чакырып кына алырең, бигрәкләр дә ерак киттеләр шул, жир читенә китеп бардылар,— дип, кара кайгыга калды.

Иөзенә бик хәтәр эрелек чыгарып:

— Нинди әзерләү, нигә әзерләү? Ә скважинаны кем бораулап бетерер? Куй син, әнисе. Булмаганны...— дигән булды карт.

Ләкин әзерләнми мөмкин түгел иде. Беренче көнне үк картны котларга конторадан делегация килде, тресттан килделәр. Бригада егетләрен әйткән дә юк инде, кич життеме, вахтадан бушадылармы, кулларына ниндидер төнчекләр тотып, эшкә йөртә торган кыр сумкаларына «тегене-моны» салып киләләр дә керәләр. Карт күңелен ничек кенә эшенә беркетеп тормасын, ул әүвәлгечә нык һәм эшлекле киңәшләр бирә алмый, башында төрле уйлары тулып яши иде аның. Диңгез флотында хезмәт иткән Ваһавы да искә төшә, Казанда институтта укып йөргән Сәлимем ишеттеме икән дип тә кайгыра. Булат белән Фәйрүзәдән килгән телеграмманы Тәүфика түтидән таптыра, әллә ничә кабат укыган булса да, тагын бер тапкыр укый, алай хәзер ниндирәк хис кичерәләр икән дип уйлый башлый да, уйлары озаеп, күбәеп, улы белән килененең эшләре ничек барганны үз күзләре белән күрәсе килеп, күңеле жилкенергә тотына. Ниһаять, үзен-үзе тынычландырырга булды — Указ басылган газета белән телеграммаларны хезмәт язулары саклана торган тимер кыршаулы зур сандыкның төбенә үк салып куйды.

Бригада егетләре элеккесеннән дә тәгәлрәк, тәртиплерәк эшләп, картның күңелен бик булдырдылар.

Зозуля аның эш урынына ике мәртәбә килеп, кулы белән ияген сыпырып, буровой тирәләрен урап йөрде, алан читендәге каенлыкның эченә кереп, нәрсәдер исәпләп торды; трест управляющиеның зур кабарынкы мыегы, тулы түгәрәк йөзе ягымлы иде, кашлары астыннан якты зәңгәр күзләре, жыерчыклар белән нурланып, хәйләкәр елтырыйлар. Бер килүендә ул карттан үз итеп:

— Ну, ничек, оста Лотфулла? Герой булуы рәхәтме? — дип сорады.

Лотфулла агай аның дустанә әйткән сүзләренә шаяртып жавап кайтарды:

— Герой булулары, Митрофан Апанасович, бик мәшәкатьле икән. Элек мин берәр дустым килсә, бер ярты простой аракы ала идем дә эше бетә иде. Хәзер бер яртыга канәгать булмыйлар. Өстәвенә «столичный» таптыралар. Син герой, диләр. Тәүфика карчык элек ни кисә, шул ярый торган иде. Хәзер әйтә, картым, ди, син миңа берәр бәрхет күлмәк алырсың инде, герой хатыны башым белән простой күлмәк киеп йөрмәм, ди.

Зозуля мыекны сыпырып елмая һәм якты зәңгәр күзләре белән картка яратып карап тора.

Скважинаның тәгәл бораулашып бетүенә дә ул бик нык ярдәм итте. Вакытында кароттажчыларны жибәрде, сәгате-минуты белән тампонажчыларны китертеп, цемент койдыртты, перфаратордан аттырды. Ике йөз уналтынчы скважина — маңгай тирләрен сыпырып алгач, акыл һәм күңел көчен үзенә жыйган яңа скважина, аның эше дәверендәге соңгы скважина сафка басты.

Иртәнге якта Лотфулла Дияров чистарак киемнәрен киеп алган, скважина бетерү шатлыгына егетләрнең күңелләрен күтәреп җибәрү өчен, уртак шатлыкны һәм моңсулыкны юып алу өчен дип, Тәуфика түтинең хуҗалык сумкасына ризык-мазар һәм шешә-мазар да салып килгән иде.

Төш җитәрәк яңгыр ява башлады. Яңгыр эшне бозып куймагае дип борчылганнар иде, бер сәгать чамасы утырып кына, тымызык кына булып яуды да, болытлар таралып, кояш чыкты. Тузаннан арынган каеннар ак кәүсәләре һәм яшел толымнары белән кояшта ялтырап, җемелдәшеп, дөньяга сөенеч сөйләп утыра башладылар. Күк йөзе чистарып, җете зәңгәр булып калды. Әнә шул зәңгәрлекне, пакьлекне аеруча матур итеп күрсәтергә теләгән сыман, һавада ак каурый болытлар күренде, җинелчә җил исеп, үләннәрне киптерде.

Лотфулла агай, эш төгәлләнер алдыннан, алан читендәге матур бер урынны карап куйды, шунда бергәләп утырырбыз, бергәләп әкрен генә сөйләшербез дә өйләргә таралырбыз, дип уйлады.

Ләкин аның планы сүтелде. Эш сәгате беткән чакта аланга автобуслар, автомобильләр, йөк машиналары җыела башлады. «Волга» машинасында Зозуля белән бергә нинди дер билгесез кешеләр килеп туктадылар. Лотфулла агай, кулларын каш өстенә куеп, аларны танырга маташып карады. «Бу хәйләкәр хохол тагын нәрсә оештырып йөри инде?» — дип уйлап та өлгерә алмады, Зозуля житәкчелегендә берничә кеше, чиста киенгән, галстуклар таккан эшләпәле кешеләр туп-туры аңар таба юнәлделәр.

Зозуля, килеп җитешкә үк, кабарынкы мыегы астыннан ягымлы елмаеп:

— Әллә көтмәгән идегезме, оста Лотфулла? — диде һәм, кул биреп күрешкәч, үзеннән ике-өч адым гына арттарак басып торган ике кеше белән таныштырды. Макинтошлы, чандыр нык битле, урта яшьләрдәге кеше нефтьчеләр профсоюзы Үзәк комитетыннан Харабаров булып чыкты. Икенчесе... бөкрәя төшебрәк атлаган зур гәүдәле, зур яшел эшләпәле, чал мыеклы кешене күргәч, картның тез буыннары йомшап, әллә кайчангы истәлекләре яңарып, тамак төбенә төен килеп утырды. Па, хода, Дорогомилов бит бу!

— Константин...— дип тә әйтеп бетерә алмады ул, Дорогомилов аны бөтенләе белән кочагына керәп алды. Күңел тетрәткеч бу очрашуны, чәчләре, мыеклары агарган ике олы кешенең, бала кебек, сөенеп кочаклашуларын күргән кешеләр сүзсез калдылар. Җилкә аша әкәмәт аппаратлар таккан корреспондент, йөгереп килеп, картларны чалт-чолт рәсемгә төшерә башлады.

Зозуляга мәшәкать күп иде. Иске дуслар, бер-берсенең җилкәләреннән кага-кага, очрашу шатлыгын уртаклашкан арада, ул йөк машиналарыннан өстәлләр, эскәмияләр бушаттырды. Автобустан коелган оркестрантларны кайдарак урнаштырырга, кызыл материяле озын өстәлне һәм бүгенге тантанага дип каккалап куйган зур, авыр эскәмияләрне кая куярга икәнне әйтеп, ду килеп йөрде.

Урман аланына машиналар әледән-әле килә тора. Төрле бригадалардан делегацияләр җыелды. Яңа промыселлар идарәсе начальнигы Арслан Гобәйдуллин үз машинасында килеп төште. Бар нәрсә әзерләнеп бетте дигәндә шәһәр комитеты секретаре Нәҗип Корбанов килде. Корбанов үз машинасында Тәуфика түтине алып килгән, ә тегесе, чук кебек киенгән, татар карчыкларына хас мөлаемлек белән, мондый тантанага бик үк әләккәне булмаганга уңайсызланып, машинадан төшми утыра иде әле.

— Әнисе, карасана, безгә кем килгән?! — диде Лотфулла агай, каударланып. — Күреш әле, танышсыңмы?

— Без инде күрештек,— диде Дорогомилов, Тәүфика түтигә яратып карап.— Тәүфика бер дә үзгәрмәгән. Юк, үзгәргән, яшәргән, чибәрләнгән. Бик кадерләп кенә тотасың, ахры, син аны...

Зозуля командасы буенча оркестр марш уйнап җибәрде. Күңелләрне кузгатып, йөрәкләрне бер ритмга тибәргә мәҗбүр иткән ашкынулы музыка, ташый-ташый, урман аланына, каеннар арасына, зәңгәр күкләргә ашты.

Лотфулла Дияровны, зурлап, өстәл янына утырттылар. Аның бер ягына Константин Феоныч Дорогомилов, икенче ягына Тәүфика түти утырды. Шунда ук янәшә, эш киемнәреннән, бораулаучы егетләр — бөтен бригада берьюлы урнашып алды. Артык дулкынланудан, көтелмәгәндә оешкан бу тамашадан алар аптырабрак калганнар, эш киемнәреннән булуларына бераз гына уңайсызлану һәм шул ук вакытта горурлану кичереп утыралар иде.

Юбилей тантанасын Корбанов ачты. Гадәтенчә сабыр итеп, артык яңгыравыклы сүзләр кулланмыйча, Лотфулла агай Дияровны һәм аның бригадасын котлады. Аланга җыелган халык, аягүрә басып, нефтьче-ветеранны бик озак алкышлады. Лотфулла агай үзе дә аягүрә баскан, карчыгы Тәүфиканың кулын кысып тоткан хәлдә, почетлы каравылда торган солдат кебек, төз басып тора иде.

Корбанов сүзне тантанага дип махсус килгән ВЦСПС вәкиле Михаил Вениаминович Харабаровка бирелүен хәбәр итте. Халык Мәскәү вәкиленең пөхтә көрәнсу костюмын, җитди йөзен, ничек итеп өстәл янында басып торуын зур игътибар белән күзәтте. Харабаров сүзен озаклап сөйләп тормады, зур катыргы тышлы котлау кәгазенә алтын белән язылган сүзләрне укыды. Илнең нефть промышленностенда зур хезмәт куйган ветеранга профсоюз намуслы, фидакарь хезмәте өчен рәхмәт әйтә, аңар озын гомер тели иде. Адресны укып бетергәч, Харабаров картның каты итеп кулын кысты, аннары СССР Верховный Советы Президиумының Дияров Лотфулла Дияровичка Социалистик Хезмәт Герое исеме бирү турындагы указын укыды. Указны инде беләләр, газеталардан укыганнар иде, ләкин бу юлы, барысы бергә җыелган чакта, аеруча зур игътибар белән, радиодан Левитан укыган җаваплы белдерүне тыңлагандай тыңладылар. Харабаров, Ленин ордены һәм Алтын йолдыз медале салынган бәрхет тартмаларны һәм дипломны юбилярның кулына тапшырып, мастерның кулын тагын кысты.

Бораулаучылардан кемдер орден белән Алтын йолдызны шундук Лотфулла агайның пиджагына тагуын сорады, бригада егетләре тәкъдимне ду килеп күтәреп алдылар. Карт, бу бит эш киеме дип, каршы килеп маташса да, егетләр үз дигәннәрен итте: нәкъ менә эш киеменә тагылсын да инде ул, эш өчен алынган бит, уйнап йөргән өчен алынмаган, диделәр. Үз араларыннан бригадада иң озак эшләгән Кара Җәмилне орден тагарга чыгардылар. Җәмил абзый пиджак якасын тишә алмый аптырап бетте. Ничәмә еллар каты җир токымнарын тишкән нык куллы бораулаучының пиджак якасын тишә алмый азаплануы, кешеләрдә аңар карата үтә самими тойгы уятып, тантананы бигрәк тә чынга әйләндереп җибәрде.

Зозуля «Кәлимәтбурнефть» трестының Лотфулла Дияровны «Волга» машинасы белән бүләкләвен хәбәр иткәч, бригада тагын ярсынды, мастерны машинага утыртып, буровой тирәли әйләндереп йөртүне, почетлы йөреш үткәрүне таләп итте.

Арслан Гобәйдуллин халык арасында иде. Лотфулла останың тыйнаклыгы, еллар буена җыйган зур тәҗрибәсе, зирәклеге турында Митрофан Зозуля сөйләгәндә, шуны ук икенче сүзләр белән, ләкин ихлас күңелдән контора директоры Сафуанов кабатлаганда, бригада егетләренең барысы берьюлы аяк өсте басып, картка рәхмәт әйтүен тыңлаганда, Арслан күңеленнән бер хис кичереп утырды.

«Илгә хуҗаларның нииндиләре генә килмәгән. Берәүләр үзен сөйгән, үз шәхесен күтәргән; икенчеләре, шул шәхеснең йомшак ягын сизеп алып, халык исеменнән авантюрага барганнар; өченчеләре белмәгәнне беләбез дип, юк-бар акылларын халыкка көчләп тагарга тырышканнар. Ләкин илнең чын хуҗасы гомер-гомергә халык булган. Лотфулла Дияров кебек, үз-үзен аямыйча, үзенә күп нәрсә таләп итмичә, чын күңеленнән хезмәт итүче фидакарь кешеләр — менә ул кем — хуҗалар...»

Нәҗип Корбанов соңгы сүзне юбилярның үзенә — Лотфулла агай Дияровка бирде. Карт шундук урыныннан торып басты, ике куллап, ныгытып, кызыл материяле өстәл читенә таянды, аның өчен ут йотып утырган Тәүфика түтигә карап, ягымлы итеп бер елмайды да, әле үз янында тезелгән бригадасына, әле каршыда, урман аланында утырган, аны хөрмәтләргә килгән халыкка күз салып, тонырак тавыш белән башлап китте.

— Рәхмәт, туганнар, сезгә, килгәнсез, эшебез кала димәгәнсез. Остазым-өйрәтүчем, мине кеше иткән Константин Феоныч алдында чал башымны иям. Бүген монда бик күп торбалар кычкырттылар, бик күп мактау сүзләре әйтелде. Моның барысының мәгънәсен мин үземнең кара акылым белән болай дип аңлыйм: бу минем бүгеннән пенсионер булуым дигән сүздер инде. Мондый тантана, бәлки, безнең ише карткорының күңелен төшермәс өчен эшләнә торгандыр. Кһм... Мин, туганнар, сездән бер генә нәрсә сорар идем, әгәр минем кирәгем чыкса, тартынмагыз, чакырыгыз, көчемнән килгән кадәр булышырмын.

Нефть ветеранына җавап итеп, озаклап кул чаптылар. Оркестр туш уйнады. Зәңгәр күкләр, каен урманнары ашкынулы музыканы кайтаваз итеп кабатлап торды.

Кыңгыраулы мәйданында бәйрәм тантанасы якты йолдызлар кабынганчы гөрләде, кайнар сүзләрне, ярату һәм олылау тойгыларын табын өстәлләре янында, кулларга мөлдерәмә тулган тустаганнар тоткан килеш әйттеләр.

Автобусларга, йөк машиналарына, җинел «Волга»ларга төялеп, Кәлимәткә кайтырга чыкканда, таң беленә башлаган иде инде.

Алан уртасында, таң нурларына коенып, кеше фидакарьлегенә һәйкәл булып, буровой вышкасы басып калды...

## 5

Тагын бер айдан бәйрәм тойгысы Арслан Гобәйдуллиннар өенә күчте. Ләкин бу бәйрәмнең карт оста бәйрәменнән зур гына аермасы бар: монда оркестр да, котлаулар да юк, монда чамадан тыш тыенкы җитди эшлеклелек хөкем сөрә иде. Кичтән Арслан Сәгыйдәгә яңа күлмәкләрен әзерләп куярга кушты, костюмнарын үзе үтүкләде, гадәттәгедән иртәрәк йокларга ятты. Иртән иртүк, ул, дәүләт комиссиясе составында, яңа заводның беренче установкаларын кабул итәргә барырга тиеш иде. Җаваплылык хисе, еллар буена хыялында йөрткән заводның сафка басачагы, аның тирә-якка җан өреп, яңа каланың өйләренә җылы бирәчәге Арсланны тоташ дулкынландырып тора һәм, беренче сынау уңышлы үтәрме дип, өркетә дә иде.

Таң белән уянды Арслан. Бик җентекләп кырынды, чәй эчте, яңа костюмын, макинтошын, көл төсендәге киң кырлы эшләпәсен киеп юлга чыгарга җыенгач:

— Я, Сәгыйдә, хәерле юл телә миңа,— диде, хатынының маңгаеннан үбеп, кысып кочаклады.

— Эш киемнәреңне алмыйсыңмы? — диде Сәгыйдә.

— Эш киеме идарәдә бар, кирәк булса, шуннан алырмын.

— Юлларыңа ак җәймә, Арсланкаем, барысы да син дигәнчә булсын,— диде Сәгыйдә, аерылырга теләмичә.— Чәчрәп алга чыкма, яме, матурым...

Инде чыгып китәм дигәч тә ул аны әллә ничә мәртәбә туктатып, сак бул, яме, дип кат-кат киңәшләрен әйтте.

Арслан китеп баргач, ул, байтак вакыт нинди эшкә тотынырга белмичә, кухня ягында болганып йөрде, улы Рәфикъ белән кызы Элфиянең битләрен юдырып, тамакларын туйдырды, өсләренә кигән күлмәкләрен бик төпченеп, кат-кат күзеннән үткәрде — бүген этиләренең сөенечле көне, бүген барысы тегәл, барысы пөхтә, барысы бәйрәмчә булырга тиеш иде.

Сәгыйдә бүген көндез эшләми, больницада ул кич белән дежур торырга тиеш. Шуңа күрә көндез ул үзләренең бакчасына барып килергә, этиләре кайтканчы өй тутырып чәчәкләр куярга тели иде. Иренең күңелен җиде ел бергә торган дәвердә белеп бетергән иде Сәгыйдә, аңар ярашуны, аның күңелен табуны үзе өчен бик рәхәт бер эш итеп саный ул.

Балалар бакчасында санитар көн үткәрергә булганнар икән, бакча ябык иде. Аңар да бик артык борчылмады, улын үзе белән бакчага алып китәргә булды. Әйдә, бәләкәй дә бер дөнья күреп, чәчәкләр арасында, кояшта уйнап, ирек ачып кайтсын әле. «Менә, этисе, улың нинди дәү егет булды, сиңа чәчәкләр алып кайтты»,— диярбез. И сөенер этисе, и сөенер...

Автобус тукталышында Сәгыйдә бер сәгатьләр чамасы басып торды. Рәфикъ баш түбәсендә үк кыздырган август кояшыннан тирләп шыңшый башлагач, малайның бер кат күлмәген салдырды — автобус һаман юк иде әле. Автобус килмәгәнгә бүтәннәрнең дә эче поша башлады. Кешеләр борчылып юлга чыгалар, башларын сузып, урам чатына карап-карап алалар, шәһәрдәге тәртипсезлекләрне, автотранспорт конторасы түрәләрен тиргиләр иде.

Брезент киемле мыеклы бер нефтьче, вахта машинасына утыра алмый калуына үкенеп, әрле-бирле йөренә. Яулыгын маңгай турысына козыреклап бәйләгән рус карчыгы, зур яшел кәрҗинен әле бер, әле икенче беләгенә күчереп, парк рәшәткәсенә сөялгән икенче карчыкка, ахирәтенә, мондый чакта чыгып та йөрмәскә кирәк, автобуслар барысы бергә обедка туктыйлар да мәхшәр куба, дип сөйләп тора. Аның тешсез авызын мүкелдәтеп сөйләве Сәгыйдәнең борчылуын тагын да арттыра төшә иде.

Кулларына эмальле чиләкләр, китмән-көрәкише нәрсәләр тоткан бакчачылар иренеп кенә сөйләшәләр, куләгәлерәк урыннарга сыенырга тырышалар һәм төрле тавышка әкрен генә зарланалар.

Юлчыларның сабырлыгы төкәнеп килә иде инде. Автобус тукталышына сары чәчләре иңенә таралып төшкән уникe-унөч яшьләрендәге бер үсмер кыз килеп чыкты. Кызның битe, ялангач беләкләре, кыска күлмәге астыннан озын булып сузылган ботлары кояшта янып, бакыр төсенә кергән һәм бу кызкайның дөньяда бер генә дә гаме юк кебек тоела иде. Кулына бүрәнкәләп төргән газета тоткан иде кызый, әнә шул төргәк эченә ул исе китеп карап тора: бер караганда кояшта уңган аксыл кашлары җыерыла, ул да булмый, үсмерләргә хас зур авызы колакларына хәтле җәелеп, иреннәре тыелгысыз елмаю белән елмая башлыйлар. Аның янына ук туры килгән брезент киемле нефтьче, үрелеп, төргәк эченә күз салды, абзыйның ачулы йөзе кинәт алмаштырып куйгандай үзгәрде. Аксыл чичүнчә костюмлы, кырма сакаллы татар карты да төргәк эченә үрелеп карады — ул да сабый балага әйләнеп калды. Юлчы халык, дөнья мәшәкатен онытып, сары чәчле кызны урап ала башлагач, Сәгыйдә дә түзмәде, Рәфикъны кулына күтәреп, халык арасына барып керде. Төргәк эчендә бәләкәй

генә керпе баласы утыра, ул шундый да сабый, шундый да гөнаһсыз, анар карагач, елмаймый калу һич мөмкин түгел иде.

Үсмер кыз, төргәген Рәфикъка якынрак китереп:

— Мә, аласыңмы? — диде.

Рәфикъ сөенеп кулын сузды һәм шундук кире тартып алды. Кешеләр аның хәрәкәтеннән рәхәтләнеп көлештеләр.

— Минем малай бик сораган иде,— дип сүзгә кереште нефтьче.— Туры килгәне юк. Скважиналар карап йөргәндә, урманда берсе очраган иде, карт керпе булып чыкты — инәләрен тырпайтты да йомарланып ятты. Тимәдем...

— Сөт ярата ул, сөт эчертерсең, яме, кызым,— дип киңәш бирде яулыгын козырекла п бәйләгән рус карчыгы.

Сары чәчле кыз керпе баласын каян алуы хакында сөйләргә тотынды:

— Бишәү иде алар. Дүртесе шунда калды. Курка да белми әле ул, күрәсезме, борынын да яшерә белми...

Көтмәгәндә автобус килеп туктады. Талаш юк, дәгъва юк. Нәни бер керпе баласы уяткан хисләрдән йомшарып, бер-берсенә карата үзләре дә сизмәстән ихтирамлырак булып, кешеләр автобуска кереп утырдылар.

Сәгыйдә бакчаны сагынган икән, автобус тәрәзәсеннән яшел куакларны һәм төрле төстәге умарта оялары кебек бәләкәй өйләрен күргә җаны рәхәтләнеп, хәсрәт-борчулары юкка чыкты.

Аның үз кулы белән юктан бар иткән бакча шул бу. Беренче елларны Кәлимәт кибетләрендә яшелчә-мазар да, җиләк-җимеш тә булмады, базардагысы бик кыйбат иде. Бәләкәйләргә — Әлфия белән Рәфикъка витамин бик кирәк чак. Сәгыйдә балалары рахит белән авырып китмәгәйләре дип курка иде. Нефтьчеләргә бакча участогы бирә башлагач, ул Арсланга чат ябышты. Алыйк бакча, утыртыйк кура җиләге белән карлыган, син йөрмәссең, үзем йөрермен, диде. Арслан көне-төне буровойда ятканга күрә, аның бу гозеренә буш хыял дип кенә караган иде, әмма Сәгыйдә үз сүзле, тәмле телле булуы белән җиңде аны. Арслан бакчалык җир алды, коллектив мәйданның капка-коймасын тотышты, көзен карлыган белән кура җиләге утыртып бирде. Я, менә кемнекеннән ким хәзер бу бакча? Әйдәле, улым, без менә шулай чүәкләрне чия төбенә яшереп куйыйк. Термос белән чәйне өйгә кертик. Минем үскән улым бит ул: чия җыеп бирimме? Әллә үзең җыеп ашыйсыңмы? И, минем улым булдыра ул, бик дәү егет бит инде, бик дәү...

Сәгыйдә, әледән-әле улына күз салгалап, керпе баласы уяткан матур хисләрдән дулкынланып, кичкә тикле бакчада эшләп йөрде. Кишер түтәлләренең чүбен утады, суган төпләрен йомшартты, кызарып пешкән помидорларын таяк кадап әйбәтләп бәйләде, «үксез» яфракларын өзеп-өзеп ташлады.

Эшләве рәхәт иде аңа бүген, нәрсәгә генә барып тотынмасын, нигәдер ул Арсланны искә ала. Бәлки, Арсланның бу бакчага бик өнәми тотынуы сәбәпче булгандыр, ул үҗәт бер тырышлык белән үстерде бакчаны. Кешеләр, такта-мазар кайгыртып, дача йортлары җиткезделәр, верандалар ясадылар, бәрәңге базы казып, анда яшелчәләрне кыш буена саклап чыга торган иттеләр. Арслан боларның берсен дә эшләргә теләмәде.

— Йорт сал, веранда яса, син тагын суганны бауга тез дип әйтергә дә күп сорамассың. Бала чакта үстергән суганнарым искә төшсә, әле хәзер дә суган исенә күңелләрем болгана башлый,— диде ул Сәгыйдәгә.

Ләкин Сәгыйдә эшне суганнан башламады. Беренче елны яздан ук иртә өлгерә торган чәчәкләр утыртып үстерде, Арслан буровойдан кайтышка аның өстәленә чәчәк куя торган булды. Игътибардан кемнең

күңеле йомшамас! Хатынының хәйләсен сизә иде Арслан, ләкин шул бәләкәй һәм эчкерсез хәйләгә бирелү үзе үк рәхәт иде бугай аңа, шул хәйлә-игътибар аның каты күңелен йомшартырга, Сәгыйдәнең гозерен үтәргә җитә кала иде.

Сәгыйдә Арсланны бакчага көндез кояш эссесендә түгел, кичләрен, рәхәт салкынлык җәелгәч кенә алып килергә тырыша; серле кыштырдаулар, ерактагы аҗаган яктылары белән тулып торган җәйге тамызык төн аларны үз кочагына ала. Көзгә таба көннәр шактый ук салкыная башлагач, бакча өенең дә кирәклеге сизелә башлады. Арслан агач эшкәртү комбинатыннан өч кубометр калдык-постык сатып алды да бәләкәй генә бер будка ясап куйды. Тирә-якта коену өчен су юк иде, зур бер бактан душ сыман нәрсә әмәлләп бирде. Рәхәтләнде Сәгыйдә белән балалар. Тирләгән саен юыналар.

Икенче елны Бөгелмә питомнигыннан унбер төп алмагач алып кайтып утырттылар. Әле генә, кичә генә булган кебек югыйсә, алмагачлар быел инде алма да күрсәтте. Карасана, Рәфикъка бер яшь тулган елны утыртканнар иде бугай — алтын китайкалар каракучкыл яфрак арасыннан гәрәбә төсле сары, үтә күренмәле булып күзләрне кызыктырып торалар. Рәфикъка җыеп бирергә кирәк әле. Сәгыйдә күтәрелеп улы ягына карады. Улының чия төбендә таш тәтиләр белән тавышсыз уйнап утыруын күргәч, күңеле тынычланды. Рәхмәт яугыры, белә бит әнисенең эше күп икәнен, шыңшып йөрми.

«Киләсе язга парник та ясатып алам әле,— дип уйлады Сәгыйдә.— Парниклы кешеләр әнә помидорны ике атна элек ашый башладылар». Ләкин бюро утырышында Арсланның шелтә алуын исенә төшергәч, ул уеннан кире кайтты. Арсланның үз акылы үзе белән. Сәгыйдә кебек очанак түгел ул, сүзен уйлап кенә сөйли, эшен уйлап кына эшли. Синең теләгеңне ул билгеле бер чиккә кадәр генә үти, чикне уздыңмы — бетте. Теге чакта зур хәтфә келәмне Гозәеровка кире бирер жибәргәнгә Сәгыйдә атна буе иренә рәнжеп йөрсә дә, хәзер аңлады: Арслан хаклы булган икән. Әгәр ул аны, Сәгыйдә әйтә дип, алып калган булса, күрер идең хәзер күрмәгәнеңне. Китер партбилетыңны, коммунист булырга хакың юк синең, диерләр иде.

Сәгыйдә Арсланның партбюро каршында кара тиргә батып басып торуын күз алдына китерде — тәне эсселе-суыклы булып китте. Ярый әле Арсланга акыл биргән ходай, алдын-артын уйлап, тикшереп эшли торган иткән. Сәгыйдә иренең Мәскәүдән кайтып төшкән көнен, Гозәеров белән икәүдән-икәү генә коньяк эчеп, бик якын дуслардай сөйләшеп утыруларын күз алдына китерде. Гозәеровның келәмне нигә китерү сәбәбен тәки әйттерде бит. Усал, усал! Сәгыйдә иренә сокланып та, беркадәр хәвефләнеп тә әйтеп куйды күңеленнән. Син аны кыек юлга өстерәп кара. Ике төрле сөйләшеп тормый ул, кырт итеп кенә өзә. Нык куллы аның Арсланы, күңеле чиста булмаган кешеләргә карата каты бәгырьле. Ләкин ул коры кеше түгел, эчкерле кеше дә түгел. Гозәеровны эшеннән алдырмады, аңа кырын күз белән дә карамады. Юк, әйбәт кеше аның Арсланы, чын кеше...

Бәхете тулы иде бүген Сәгыйдәнең. Кояш нурында күкрәп утырган бакча түтәлләре дә, үтә күренмәле алтын китайкалар да — бүген аңа барысы да матур, барысы да тере булып күренәләр, гүя аның тулышкан күңелен, аның Арсланга карата булган назлы ярату тойгыларын аңлыйлар, уртаклашалар кебек тоела иде.

Кояш шактый түбән төшеп, бакча гөлләре башларын күтәрә башлагач, Сәгыйдә, туфлиләрен салып ташлап, көне буена кызган җылы туфракка ялан аяк баса-баса, чәчәкләргә, яшелчәләргә су сибеп йөрде. Патша кәдрәләре белән баяр чәчәкләре бер метрга күтәрелгәннәр. Миләүшә чәчәкләренә су тамчылары эленеп, зебәрҗәттәй җемелди башлауга бөтен бакча хуш ис белән тула. Гладиолосларның инде ике-

се чәчәк атарга да өлгергән, алар шундый нәфис, шундый аппаклар, хәтта өзеп аласы да килми.

Яшелчәләренә, гөлләренә су сибеп бетергәч, Сәгыйдә ике литр сыешлы бәләкәй тырыска кура җиләге җыеп алды, бик пөхтәләп, бәрәмтекләп кенә бакча ромашкалары, күгәрчен күзләре, баяр чәчәкләре өзде. Шулар янына берничә бөртек мәк кыңгыравы кыстырып куйды, иң соңыннан гладиолосның ап-ак чәчәкле бер бутонын сак кына кисеп алып, чәчәк бәйләменең нәкъ уртасына кадап куйды. Искиткеч букет булып чыкты!

Соңгы тапкыр бакча өстен күздән үткәргәч, бер кулына җиләк тырысы белән чәчәк букетын тотып, икенче кулы белән Рәфикъны житәкләп, кайтырга чыкты. Автобус тукталышында кеше күп иде, аның борчылып көтеп торасы килмәде, «Яшьләр» поселогына чаклы бер чакрым араны ул җәяүләп кайтырга булды.

Озакламый аны бер солдат куып житте. Ул ялга кайта иде бугай, өстендәге киемнәре дә өр-яңа, бил каешын да бик хәтәр ныгытып, матур итеп буган. Кулындагы чемоданы, аркасындагы юл капчыгы, сиздереп сәлам бирүе һәм бик тырышып татарча сөйләшүе егетнең туган-үскән якларында күптәннән булмавын һәм сагынып кайтуын әйтеп торалар иде.

Солдатның күңеле булсын дип, Сәгыйдә аның кая кайтуын сораштырды. Бигәшкә кайта икән егет, узгынчы машинага утырып килгән. Кинәт Сәгыйдә сагаеп, хәтта куркып калды. Егетнең күз карашы аның букетына өздереп, төбәп карый, шул караш хәтта җилкәсе аша да Сәгыйдәгә тоела иде. Ул, ялт итеп, солдатка борылып карады.

— Сатыгыз әле,— диде егет, бик кыю итеп.

— Сатмыйм.

— Алайса... ике генә чәчәк бирегез.

— Агын бирмим.

— Менә боларын,— диде солдат һәм Сәгыйдәнең чәче янына ук иелеп, өч бөртек кыңгырау чәчәкләре суырып алды.

...Автобустан төшкәч, Сәгыйдәнең кинәт күңеле сүрелде. Бүтән чакта аларны елмаеп каршы ала торган Арслан бүген юк иде. Күрше хатыны Шәмсия Әлфияне бакчадан алып кайтып куйган икән. Рәфикъ сеңелесенә бакча хәлләрен берьюлы әйтеп бирергә теләп:

— Әни солдат абыйга чәчәк бирде, чәчәк бирде! — диде.

— Ә без керпе баласы күрдек.

Вакыт шактый соң иде инде, Сәгыйдә Арсланның һаман да кайтып житмәвенә борчылып, күршеләргә керде:

— Шәмсия, күршекәем, сине тагын борчып йөрим бит әле мин. Әллә нишләп ирем озаклады. Әллә бер-бер хәл булып, кайтмый калуы инде... Ходаем, дежурга барырга вакытым житте. Балаларны сездә калдырып торсам, бик мәшәкатьле булыр микән?

— Ниткән сүз ул? Нинди мәшәкать ди! Булмаганны! Без күршеләр ләбаса! Бер дә генә борчылма, Сәгыйдәкәем, кайгырмый бар эшеңә,— диде алчак табигатьле, кече күңелле Шәмсия, алъяпкыч итәгенә кулын сөртә-сөртә.— Бик әйбәтләп карармын балакайларыңны. Бездә беренче кунулары гына түгел бит, үз балаларым кебек алар миңа. Әйбәтләп тамакларын туйдырырмын, йоклатырмын. Бер дә генә борчылма, ичмасам. Арсланың да кайтыр, эшләре генә бетеп житмәгәндер. Әгәр инде өй ялгыз кала дип шикләнсәң, сезгә кереп тә йоклый алам...

Күңелен никадәр нык тотарга тырышса да, эшенә борчылып китте Сәгыйдә. Арслан төгәл кеше, вакытында кайта торган иде, ни булды икән, дип кайгырды. Авыруларның бүлмәләрен барлап, аларга чәй бирел, урыннарын рәтләп йөргән чакта да гел Арслан турында уйлады. Артык борчылуданмы, аның күз кабагы алмаш-тилмәш тарта башлады. Әнисенең бала чакта әйткән сүзләре исенә төште. «Күз кабакла-

рым тарта әле»,— дип борчыла торган иде Мәйсәрә түти. Уң кабагы тартса — сөенечкә, сулы тартса — кайгыга дигән идеме?

Төн урталары узып, авырулар йоклап беткәч, больницаның аулак, тын коридорларына дәһшәтле бер сүз килеп керде:

— Пожар! Кыңгыраулы заводы яна!

## 6

Төгәл приборлар сферик шарларда һәм җир өстенә сузып салган гигант корыч баллоннарда утыз җиде мең кубометр газ җыелганны күрсәтәләр иде. Ничәмә еллар зарыгып көткән, көрәшеп алган Кыңгыраулы заводы әнә шул чистартылган әзер газны яңа каланың өйләренә, үзәктән ягып җылыту котельныйларына куа башларга тиеш. Кышка таба теплица өлгерә, «Нефтяник» совхозы хуҗалык эшләрен тәртипкә сала — аларга да газ шуннан киләчәк. Ул көннәргә бик якын инде. Ниһаять, Арсланның хыяллары тормышка ашты! Катлаулы җайланмалар, мичләр, диспетчерлык системасы — барысы да әйбәт эшлиләр. Чехословакиядән килгән техник белгечләр дә, үзебезнең инженер-төзүчеләр дә сынау нәтиҗәләреннән канәгать булып калдылар. Көннең-көн буена аяк өстендә булып, эштән һәм дулкынланудан арыган дәүләт комиссиясе членнары, сынауның хәвеф-хәтәрсез барып чыгуына күңелләре булып, завод аякка басу белән бер-берсен тәбрикләп, төнге сәгать берләргә өйләренә тарала башладылар.

Арслан Гобәйдуллин юлдашлары Таҗи белән Атнабайга, өйгә кайтыр алдыннан завод ашханәсенә кереп, тамак ялгап алырга тәкъдим итте.

— Түзәр хәлләрем калмады, дусларым. Эчтә ач бүреләр улый,— диде ул, хәлсез генә елмаеп.— Шатлыгыбызны юып алсак та ярар иде, әллә ничек анысы башка килмәгән.

— Әйе шул! — диде Атнабай, мут елмаеп.

— Анысы өйгә кайткач булыр инде, иртәгә...— дип куйды Таҗи.

Алар завод ашханәсен ачтырып кереп, төнге сменага килгән Нәсимә ападан чәй кайнатып бирүен үтенделәр.

— Кайнар аш булса да әчне тишмәс,— дип, Атнабай үз сүзен кыстырып куйды.

— Була, туганкайларым, теләсәгез кайнар пәрәмәч пешереп бирәм. Камырым да бар, итем дә әзер. Шатлыклы да көнегез бугай... Сыйлыйммы кайнар пәрәмәч белән, Арслан Шәвәлиевич?

Арслан болай да вакытсыз борчып йөргәнгә уңайсызланып:

— Кирәкмәс, апа, мәшәкатьләнмәгез. Кичтән калган кәбестә шулпасы җылытып бирсәгез, безгә шул җиткән,— диде.

Алар чәй кайнаганны һәм аш җылынганны көткән арада табигать үзенең мәкерле эшен эшләде. Моңарчы гел үз иркендә, ачык кырда янган газ, корыч баллоннарга тыгызлап тутыргач, гүя ирегеп чикләү белән килешергә теләмичә, зур басым астында коллектордагы задвижканы бәреп чыгарды. Задвижка, юлында очраган беренче тимергә бәрелеп, очкын чәчрәтте, юл тапканга куангандай, ажгырып килеп чыккан газ, янар таулардан атылган ташкын сыман, кинәт шартлап кабынды да һавага ут өермәсе чөйде.

Моны беренче булып Атнабай күрде.

— Пожар! — диде ул, агарынып.

Өчесе берьюлы тәрәзәгә капландылар. Өермәләнеп күтәрелгән ярсулы ялкын, тирә-якны балкытып, йөрәккә шом салып, дулый-котырына, заводның челтәр-челтәр корпуслары, конус түбәләре, аның яктысында җете кызыл төскә кереп, барысы берьюлы яна төсле тоела иде.

Тажиның төсе качты. Ул Арсланга күз төшереп алып, каушап, урындыкта яткан плащын киярга тотынды, поднос белән аш күтәреп чыгып килгән Нәсимә апаны чак кына бәреп екмыйча, плащының бер җиңен кигән, икенчесен кимәгән килеш ишеккә ташланды.

— Кая? — дип кычкырды аңар Арслан. Тажи кире борылып керде. Арслан командирларча коры тавыш белән:

— Паника куптармаска! — диде.— Син, Атнабай, машинаңны барла, хәзер үк монда алып кил. Бер җирдә дә тукталма, берәүне дә тыңлама. Машина безгә кирәк булачак, аңладыңмы? Ә син, Тажи, чехлар киткәнме-юкмы, шуны белеш. Берсен дә утка якын җибәрмәскә. Беркемне! Эшчеләр заводны туктатсыннар да хәзер үк чыгып бетсеннәр. Мин пожар командаларына шалтыратам!

— Шәһәргәме?

— Башта идарәгә.

Бу минутта Арсланның акылы гаҗәп бер ачыклык белән эшли иде. Телефоннардан шалтыраткан арада, ул хәвефнең кайсы яктан килгәнен һәм беренче чиратта нәрсә эшләргә кирәген чамалап өлгерде. Пожар — завод белән газ склады арасында. Утны туктату өчен газ килү каналын — коллекторны ябарга кирәк. Хәзергә бу мөмкин түгел. Махсус киемнәр һәм асбест мендәрләр килеп җитми торып, ут эченә ташлану — янып үлүдән башкага илтмәячәк. Иң яхшысы — зур командалар килеп җиткәнче утны таратмый тотып тору.

Әнә шул фикерләр белән ашханәдән чыкканда, Кыңгыраулы Чишмәдән пожар командасы килеп җитте. Ачы кычкыртулары һәм котырынып чапкан хутлары белән, ут янына жыела башлаган завод операторларының котын алып, җиде машина килеп туктады. Беренче машинадан җиргә җиз каскалы капитан Имаев сикереп төште.

Гобәйдуллин аны үзе каршылады. Тиз генә киңәшеп алдылар.

— Әзер продукция складындагы газ янып бетми торып, янгын туктамаячак. Баллоннар кыза, аларның шартлау куркыныч бар,— дип кыска гына аңлатты Арслан.— Беренче чиратта баллоннар, шарлар өстенә су сиптереп, аларны кызудан саклап торырга кирәктер.

Капитан аның белән шундук килеште, җиде машинаның икесен завод ягына, бишесен склад янына урнаштырды, су колонкаларының кайда икәнен сорашып белде. Биш-алты минут үтүгә янгынчылар газ складын һәм заводны су белән коендыралар иде инде. Ләкин ут өермәсе шундый да көчле, кайнарлык күзгә күренеп арта бара, аны басарга идарә пожар командасының гына көче җитәрлек түгел иде.

— Кәлимәт машиналары ярты сәгатьсез дә килеп җитә алмас, халыкны күтәрергә кирәк,— диде Имаев Арсланга.

— Ни өчен?

— Канаулар, траншеялар казыйсы бар. Бер өч чакрымнан балчык тавы белән әйләндереп алырга кирәк. Янгынның урылып бетмәгән игеннәрне, бөтен промыселны чолгап алу куркынычы бар. Күтәрә аласызмы халыкны?

— Күтәрәбез! — Арслан өзеп кенә җавап бирде дә, Тажи белән Атнабайны үз машинасында Кыңгыраулы Чишмәгә чаптырды, үзе Имаев машинасында якын-тирә авылларга чыгып китте.

...Янгын бөтен Кәлимәтне аякка бастырды. Шәһәрнең төрле якларыннан, каты кычкыртып, чинап, шашкын тизлек белән пожар машиналары чапты, берьюлы дистәләгән урыннарда телефоннар чылтырый башлады. Үзәк телефон станциясендә дежур кызлар — молния белән — Казанны, Лениногорскины, Бөгелмәне тоташтырдылар; Кәлимәт пожар депосы шундук Мәскәүгә хәбәр итте.

Әйләнә-тирәдә нинди гадәттән тыш хәл килеп чыга — иң әлек горком секретаре җаваплы. Нәҗип Корбанов, янгын турындагы хәбәрне Арсланнан ишетү белән, шундук Мөстәкыймовка шалтыратты, хәзер

ук, сәгате-минуты белән, янгын булган җиргә барып җитәргә, пожар башлыклары һәм Арслан Гобәйдуллин белән бәйләнешкә керергә кушты. Тәртип өчен, кешеләрнең иминлеге өчен беренче чиратта сез җавап бирәсез, диде. Аннары ул, Кәлимәтнең үзәк больницасына шалтыратып, баш врачны белеште, янгын урынына врачлар, сестралар җибәрергә, беренче ярдәмне күрсәтү өчен нәрсәләр кирәк, барын да алырга кушты.

Һәм менә баш врач Капитонов белән өч сестраны утырткан ашыгыч ярдәм машинасы төнге асфальт юлдан томырылып алга чаба. Машина фарыннан төшкән яктылык төнге август урманын айкап уза, ачык кырга килеп чыккач, ике озын тасма әллә кайларга чаклы сузылып, Кыңгыраулы мәйданында кабынган пожар ялкыннары белән барып тоташа төсле тоела иде.

Сәгыйдә йөрәгенең тамак төбенә килеп җитүен, гәүдәсенең уттай януын тоеп, арткы утыргычка башын салды. Ул бүген больницада дежур тора иде, аны пожарга барырга бирәү дә кыстамады, ул үзе ялынып сорады; алырга теләмәгәч, ярсынып, ачыргаланып, иренең, Арслан Гобәйдуллинның, анда булуын, аларның аны алып бармаска хаклары юклыгын күз яше белән аңлатырга тотынды.

Машина пожар урынына якынайган саен, ярты күкне иңләгән янгын шәүләсе җете кызыл таң төсенә кереп барган саен, аның куркуы арта төште, сулышы кысылды; вакыт-вакыт ул машина тизлегеннән һәм уйларының кайнарлыгыннан аңын җуяр дәрәҗәгә килеп җитә иде. Арслан бер генә минутка да аның уеннан китми; ул аның холкын, батыр йөрәкле икәнен белә, беркем барып кермәгәндә, беркем тәвәккәллек итмәгәндә, ул беренче булып ут авызына барып керер, балаларымны ятим калдырыр дип, йөрәге өшеп, котлары алынып уйлый, аның пожарда янган үле гәүдәсен күз алдына китерә, шуннан соң, ихтыярсыз башын күтәреп, пожар ялкыннары дулаган якка карый, машинаның тизрәк барып җитүен тели; аның күңелендә бер генә, тик бер генә теләк — әгәр инде ул ут авызына барып керергә өлгермәгән булса, шул акылсызлыкны эшләмәгән булса, аны һәлакәттән саклап калу, муенына асылынып, җылап-үгетләп, балалары хакына, Рәфигы белән Әлфиясе хакына аны утка якын җибәрмәү иде.

Аларны ике мәртәбә, йөрәк яргыч ачы тавыш белән кычкыртып, пожар машиналары узып китте. Сәгыйдәгә алар аның ирен, Арсланны күмәргә баралар кебек тоелды.

Пожар урынына барып җиткәч тә, дөресрәге барып җитәргә ике чакрымнар кала, аларны җәмәгать патруле туктатты. Сәгыйдәнең никадәр күңеле ашкынмасын, Арсланның исәнме-юкмы икәнен никадәр генә белергә тырышмасын, аларны эчкә уздырмадылар. Сәгыйдә монда бөтен нәрсә сугыштагы кебек ныклы тәртипкә буйсынганын аңлап алды. Аның машина эчендә тыныч кына утырып торырлык хәле юк иде, ул машинадан тышка чыкты, баш врач Капитонов белән сөйләшеп торган кызыл тасмалы патрульдән:

— Арслан кайда? Ник безне җибәрмисез? — диде.

— Нинди Арслан?

— Гобәйдуллин! Идарә башлыгы! Минем ирем! Ул монда булырга тиеш! Ничек инде сез аны белмисез? — дип Сәгыйдә, калтыранган куллары белән патрульнең җиңенә тотынды.

— Сонечка, тынычланыгыз, сөйләшергә комачаулыйсыз,— диде Капитонов, уңайсызланып.— Патруль каян белсен, ул бит шушы участокка куелган, үз участогын гына белә, аның эше — машиналарны регулировать итү... Барып җиткү белән ачыкларбыз...

Шуннан соң Сәгыйдә, бераз гына тынычлангандай булып, кирeдән машина эченә кереп утырды. Икенче постка килеп җиткәнче бер сүз дә дәшмәде.

Ашыгыч ярдәм машинасы патруль күрсәткән урынга басу өсләре, түмгәкләр буйлап, чокырларга төшә-менә барды. Сәгыйдә хәзер күзләрен йомып бара алмый, ул бөтен барлыгы белән пожар мәйданына төбәлгән иде. Ул өермәләнеп янган утны күрә, кып-кызыл стена булып тезелгән пожар машиналарын күрә, өч чакрым тирәсе мәйданны уратып алып, атакага барган гаскәрләр кебек, тоташ стена булып алга омтылучы халыкны күрә, алар аңа киноларда күргән яу кырын, һөҗүм картиналарын хәтерләтәләр иде. Сәгыйдә тагын сабырсызлана башлады. Капитоновның җиңенә кагылып:

— Анатолий Ефримович, ник килгән шул тамаша халык? Нишлиләр алар? — диде.

Баш врач, аңар таба борылмый гына:

— Ут белән көрәшәләр,— диде.

— Ничек көрәшәләр?

— Сез, Сонечка, пәрәме бала кебек. Күрмисезмени, балчык таулары өяләр. Пожарның урылмаган игеннәргә кабынып, бөтен промыселны чолгап алуы мөмкин.

Икенче постта аларны бил турысы кызыл тасмалы милиция машинасы каршылады. Машинадан каракучкыл-зәңгәр кительле өлкән лейтенант чыгып, Капитонов белән кыска гына исәнләште дә үз машинасы артыннан барырга боерды.

Алар ун минутлар чамасы пожар мәйданы читеннән бардылар. Тимер лафетларын туп көпшәседәй күккә чөйгән, ялкын төсле кызыл, ут янып торган пожар машиналары барысы бердәм күккә су аталар, су, томан булып, галәмәт дәү шарлар өстендә эленеп тора, пожар шәүләсендә салават күпере булып аллы-гөлле төсләргә кереп балкый иде.

Ашыгыч ярдәмне пожардан ерак түгел генә урында туктаттылар. Капитонов сестраларга аның рөхсәтеннән башка беркая да китмәскә, үз белдекләре белән бер нәрсә дә эшләмәскә кушты.

Машина янына зур бер палатка китереп кордылар. Палатка эченә, җиргә матраслар җәйделәр. Кыр госпитале, медицина ярдәме күрсәтү пункты шуның белән әзер булды. Озак та үтми, брезент киемнәре төтәп торган бер кешене ут эченнән күтәреп чыгардылар. Сәгыйдә, йөрәге ачыргаланып, кычкырып җибәрде:

— Арслан!

Юк, бу Арслан түгел, бу мәхшәр эченнән әле генә чыккан пожарник иде.

## 7

Янгын башланганга өч сәгатьләп вакыт узды.

Беренче каушау, ашыгу-каударлану чоры инде узган, нефть шәһәрләренең пожар командалары инде җыелып беткән, янгын сүндерүгә җаваплы кешеләр, үз вазифаларын яхшы аңлап, табигать стихиясенә каршы һөҗүмне, фронттагы кебек, корыч тәртип белән, методик рәвештә алып баралар иде.

Арслан Гобәйдуллин тәүге бурычның дөрес билгеләнгән булуын аңлады. Ут ялкынында зур монумент кебек басып торган завод, үз-үзләрен аямыйча, кара тиргә батып эшләгән янгынчылар, аларга ярдәмгә күтәрелгән нефтьче операторлар һәм әледән-әле пожарниклар урынына баскан таза яшь егетләр аның күңелендә заводның исән калуына нык ышаныч уяттылар. Һәм шушы зур, авыр сынау сәгатендә ул бүгенге яшьләргә, комсомолларга карата кайчандыр туган уңайсыз фикеренең экренләп юкка чыга баруын, «Зәңгәр ут» кичәсендә булган гамьсезлек, битарафлык, сүлпәнлекнең эзе дә калмавын күрде.

Аның үзенең кыяфәте танымаслык: завод ачу тантанасына дип киеп килгән яңа костюмы балчыкка, мазутка буялып беткән, эшләпәсе белән галстугын салып, башына Атнабайның ямьшәйгән кепкасын чәпәп куйган иде. Утка каршы көрәшүчеләр белән бергә, теләсә нинди авыр участокка ташланырга, теләсә нинди заданиене икеләнми-нитми үтәргә әзер иде ул: тик завод кына исән калсын.

Казаннан вертолет белән очып килгән полковник Белоусов — үз гомерендә иң хәтәр ялкыннарны сүндергән кеше — янгын командалары башлыкларын һәм партия-хуҗалык җитәкчеләрен үз янына җыйды. Кәлимәт янгын командасыннан майор Алимов, яңа заводның директоры Медведев, горком секретаре Мөстәкыймов, алар белән бергә Арслан Гобәйдуллин, баш врач Капитонов, стройдагы солдатлар кебек, Белоусовның командасын көтеп, тынып калдылар. Уң яңагында кайчандыр сүндерелгән пожарның җуелмас яра эзе утырып калган, чал кашлы Белоусов үзе сөйләмәде, хәлләрне генә сорашты. Аңардагы кырыс-җитдилек һәм хәрби командир төгәллеге кешеләрне кыска итеп, кирәген генә сөйләргә мәҗбүр итте.

Капитонов янгыннан дүрт кеше зыян күрүен әйтте: икесе җиңелчә яралы, икесенең битләре пешкән.

— Шәһәргә озаттыгызмы? — диде Белоусов.

— Юк әле, палаткаларга урнаштырдык.

— Бер минут кичекми шәһәргә озатырга.

— Тыңлыйм, иптәш полковник.

Алимов янгынның инде өч сәгать дәвам иткән булуы, пожар сүндерүдә алтмыш өч машина, бер йөз егерме сугышчы катнашуын әйтте.

— Складтагы газ тагын ничә сәгатькә җитәрлек?

Монысына Медведев җавап бирде.

— Ким дигәндә ике сәгать яначак.

— Складның шартлау ихтималы зурмы?

— Әйтүе кыен, иптәш полковник. Минутына җитмеш тонна су койдырабыз. Су шундук парга әйләнеп бара.

Полковник калган ягын сорашмады. Тәҗрибәле янгынчы обстановканы ачыклап өлгергән иде инде. Мөстәкыймовны ул уттан зарарланган кешеләр янына беркетте, майор Алимовка складлар янына көчне күбрәк тупларга кушты, Арслан Гобәйдуллин белән завод директоры Медведевны үзе белән алды: алар газ килү каналын ябу буенча аның төп консультантлары булырга тиешләр иде.

Тагын ярты сәгатьләр ут белән көрәшкәннән соң хәлләрнең кискенләшә баруы билгеле булды: сферик шарлар һәм баллоннар янында ялкын кызуы арта, янгын сүндерүчеләрнең хәле мөшкелләнә бара иде. Тагын ике кешенең медицина пунктына китерелүен хәбәр итте Мөстәкыймов. Газ каналын ябу — төп проблемага әйләнде. Вертолет белән алып килгән асбест плащларны киеп, бер-бер артлы өч янгынчы ут эченә кереп чыктылар, ләкин алар ярты юлдан борылалар, ут эчендә озак калу мөмкин түгел, ә газ бәргән урынны таба алмыйлар иде. Ут чыганагын эзләүне хәзергә туктатып торырга, янгынның сүрелә төшүен көтәргә булдылар. Ләкин шул мәлне коточкыч хәл булды: янгынга иң якын торган баллон гөрселдәп шартлады да, ракета кебек, артыннан ут өермәсе сузып, очып китте.

Шартлау дулкыны ике янгынчыны, аларга ярдәмгә ашыккан бер сестраны бик хәтәр читкә алып аткан, врачлар килеп җиткәндә алар аңнарын җуйганнар иде.

Шартлау дулкыны алып ташлаган кешеләр арасындагы сестраның Арслан Гобәйдуллин хатыны икәнен белгәч, Мөстәкыймовның коты алынды. Нәҗип Корбановның: «Кешеләрнең иминлеге өчен сез җавап бирәсез»,— дигән дәшһәтле сүзе исенә төште. Бу хакта ул Гобәйдуллинга бер сүз дә әйтмәскә дип врач Капитоновны бик нык кисәтеп

куйды. Аның җуйган кешеләрне палата эченә урнаштырдылар, шәһәргә озатканчы бераүгә дә күрсәтмәделәр.

Хәзер газ каналын ябу кичектергесез иде инде, юкса, шарларның һәм баллоннарның бер-бер артлы шартлап, эшләгән бөтен эшне юкка чыгарулары, аннан да бигрәк завод өстенә барып төшеп, икенче пожар чыганагы булдыруы мөмкин иде.

Арслан бөтен ачыклыгы белән аңлап алды: соңгы сынау сәгате сукты. Сузу — җинаять, дистәләгән кеше гомерен өзүдән, заводны юкка чыгарудан бүтәнгә илтмәячәк. Аның иреннәре кысылган, күңелен тыелгысыз ашкыну, тәвәккәллек биләп алган иде.

Полковник ут эченә керергә яңа ирекледәрне сайлый башлагач, Арслан, соңга калудан курыккандай, ашыгып, аның каршысына килеп басты:

— Рөхсәт итегез, иптәш полковник!

Белоусов, борын канатлары киерелгән, таштай нык чырайлы, таза, нык гәүдәле Гобәйдуллинны күздән кичереп:

— Ут сүндергәнегез бармы? — диде.

— Бар, иптәш полковник. Күп мәртәбә... Рөхсәт итегез...

Мөстәкыймов яралыларның хәлен әйтергә килгән иде.

Ул кинәт Гобәйдуллинның нишләргә җыенганын аңлап алды. «Булыр ул партизаннан,— дип коты алынды.— Аннары мин җавап бирергәме?»

Атылып Белоусов янына килде.

— Уйламагыз да! Уйламагыз да!! — диде ул, ашыгып, каушап.— Горком исеменнән боерам: Гобәйдуллинны утка якын җибәрмәскә! Нәтиҗәсе өчен башыгыз белән җавап бирәсез!

Белоусов икеләнә калды. Чыннан да! Зур бер идарәнең начальнигын һәлак итү — заводтан кыйбатракка төшәчәк. Ләкин Гобәйдуллин шул мәлне, солдатларча нык басып, аның каршысында калыкты:

— Иптәш полковник, заводны да, кешеләрне һәлак итәбез. Ут чыганагын ябарга кирәк. Рөхсәт итегез. Әгәр... юк, сузарга ярамый, мин рөхсәтсез керәм!

Полковник аның бүртеп чыккан яңак сеңерләренә, акыллы тәвәккәл күзләренә карап, Гобәйдуллинның рөхсәтсез дә керәчәген аңлап алды һәм махсус команда тупларга боерды.

Су сиптерүче куәтле лафетларны ут чыганагына таба бордылар. Өсләренә асбест плащлар кигән, гаять зур асбест җәймәне як-ягыннан тоткан унөч кеше, шулар белән бергә Арслан Гобәйдуллин, лафетлар яңгыры астында, дөрләп янган ут эченә кереп киттеләр...

## 8

Яңгыр ява. Тимер каскалы, усал йөзле кешеләр аның өстенә яңгыр яудыралар. Лафет көпшәсеннән атылып чыккан кайнар агынты, ут булып, аның битен, күзләрен пешерә. Ул битен капламакчы була — куллары күтәрелми, кычкырырга, ярдәм сорарга тели — тавышы ишетелми.

«А-а-а...» — дип ыңгырашып җибәрә ул һәм күзләрен ача. Битенең марля белән уралганын, өстенә кемнеңдер иелгән булуын тоя.

— Арслан абый... Хәлең ничек?

Чамадан тыш әкрен әйтелгән, үтә дә якын, үтә дә таныш тавыш аны аңына китерә.

— Атнабай, синме? — ди ул, кипшенгән иреннәрен көч-хәл белән кыймылдатып.

— Мин, Арслан абый. Чәй биримме?

Ул йотлыгып чәй эчә. Хәле китеп:

— Сүндеме? — дип сорый.

— Сүнде, Арслан абый.

— Ә завод?

— Завод исән.

Ул шундук мендәр өстенә авып төшә. Ике сәгать буена, үлгән кешедәй, селкенми йоклый.

Икенче мәртәбә күзләрен ачканда, ул Атнабайның һаман үз янында утыруын аңлый. Битенең кайнар сулама япкандай сулкылдап торуын, колакларының шаулавын тоя.

— Сәгыйдә кайда?

— Залда ул...

— Керсен әле.

Атнабай дәшми. Арслан терсәкләренә таянып күтәрелә.

— Ник дәшмисең?

Атнабай аның марля арасыннан утлы күмердәй көйгән күзләрен күрә.

— Керә алмый шул...— ди әкрен генә.

Арслан мендәрдән башын күтәрә, өстендәге ак җәймәне читкә алып ташлый, аны яткырмакчы булып каударлана башлаган Атнабайны кул хәрәкәте белән җиңел генә читкә этәрә һәм идәнгә төшә. Пижамадан, ялан аяк, бите-башы марля белән уралган хәлдә, тотрыксыз адымнар белән ишеккә юнәлә, хәлсезләнеп, ишек яңагына сөяләә. Атнабай аңар йорт башмагы кидерә, ятып торырга үгетли. Арслан ятмый, сүзсез генә кабинетына уза, язу өстәле янына утырып, машиналь рәвештә иске бер журналны актара, марля белән уралган битенә куллары белән баскалап карый да, китап киштәсенә төбәлеп, бик озак хәрәкәтсез утыра.

Аннары, нидер исенә төшеп, урыныннан тора, тәрәксез урындыкта яткан чалбарын кия башлый. Атнабай аңар киенергә булыша-булыша, хәвефле уйларын уйлый: «Сәгыйдә турында әйтим микән? Хушы китеп егылмасмы? Юк, әйтми торыйм әле, әкренләп әзерләрмен...»

Арслан өстен киенеп бетереп, кабинеттан чыга. Атнабай аны иңеннән алып, иплэп кенә кухня ягына алып чыгарга тели.

— Тамакка ашап алабызмы, Арслан абый?

Арслан дәшми. Туп-туры залга таба юнәлә. Атнабай, каршы килү мәгънәсезлек икәнен аңлап, аны бүтән үгетләми, тик, ул-бу булса дип, аңардан бер адым да калмыйча, саклап кына бара.

Зал ишеген ачып җибәрүгә ак халатлы ике хатын, сискәнеп, башларын күтәрәләр. Залның урта бер җирендә, биек өстәл өстендә, кызыл материя белән тышланган табут тора, табут эчендә Сәгыйдә ята. Идәндә — сулы ләгән, урындыкларда — сабын, губка, төрле зурлыктагы шешәләр. Ак халатлы хатыннар — Сәгыйдәнең больница иптәшләре — мәрхүмәнең гәүдәсен әле генә юып, яңа киемнәрен киендергәннәр булса кирәк. Түрдәге трюмоны, татар гадәте буенча, җәймә белән каплаганнар. Бүлмә бик тын. Одеколон катыш дару исе, почмакка өйгән ылыслардан таралган нарат исе килә. Төнлә булып узган дәһшәттән соң гүя монда бөтен нәрсә ял итә...

Арслан ашыкмый гына табут янына килә. Башын кыңгыр салып, бер кулын чалбар кесәсенә тыгып, хатынының кәфен төсле ак йөзенә, йомык күзләренә һәм очлайган иягенә карап тора. Гәүдә буена сузып салган, салкын ак кулларын алмаш-тилмәш үз учында тотып, ашыкмый гына кире сала. Кергәндәге кебек салмак, тотрыксыз адымнар белән залдан чыгып китә.

Аның бөтен халәте, салмак атлап йөрүе, әйберләргә тотынып, хәлсезләнеп торуы, вакыт-вакыт нәрсәгәдер бик озак төбәлеп каравы аның әле йокылы-уяулы булуын, кешеләрне тораташ итеп катыра торган үлем дәһшәтенең аңына барып җитмәвен әйтеп торалар иде.

Төштән соң кешеләр килә башлады. Веноклар алып килделәр. Баш киемнәрен салып, табут янына бастылар. Хатын-кызлар үксеп җибәрмәс өчен, авызларын каплап, кызарган күзләрен куллары белән сөрткәләп алалар иде.

Нәҗип Корбанов белән Лотфулла агай Арслан янында бик озак утырып тордылар. Арсланны сөйләштерергә, аз гына булса да аның хәлен җиңеләйтергә кирәк иде. Арслан алар белән кул биреп күреште, сорауларына җавап бирде, үлем турында да, күмү хәсрәте турында да, янгын турында да сүз кузгатмады.

Тик бер генә мәртәбә ул Атнабайдан:

— Телеграмма бирдеңме? — дип сорады.

— Бирдем,— диде Атнабай.

Берәр сәгатьтән Арсланнар квартиры халык белән тулды. Промыселда эшләүче операторлар, инженерлар, Арсланны һәм Сәгыйдәне якыннан белүчеләр, мәрхүмә белән хушлашырга, идарә начальнигының хәлен җиңеләйтергә, кайгысын уртаклашырга җыела башладылар.

Таҗи Вилданов, халык арасыннан кысылып, эчкә узды. Нәҗип Корбановка, хәзер оркестр килеп җитәчәген, каберне инде казылган булуын, анда Арсланның энесе Габделхәй калганын хәбәр итте. Арслан янына керергә кушты аңар Корбанов, ул сине ярата, янында утыр, беркая да китмә, кешеләрне аның янына кертмә, диде.

Арсланны күрүгә Таҗиның йөрәге өшеп киткәндәй була. Марля белән уралган йөзенең нинди тойгылар кичерүен күрми ул, әмма бергә эшләүче иптәшенең, сабыр табигатьле, батыр холыклы дустының бөкрәя төшеп, койка читендә утыруыннан, хәрәкәтсезлегеннән, аның никадәр арыган, миңгерәүләнеп калган икәнен аңлый. Кул биреп күрешкәч, юатыр сүз таба алмыйча, бу фаҗигадә үзенең дә гаебе бар сыман, тынып кала, көрсенеп куя. Йокы бүлмәсендәге өнсезлек, якында гына, күрше бүлмәдә генә ишетелеп торган сөйләшүләр, ишекләрнең ачылып-ябылуы аның күңелендә тормыш белән үлемнең янәшә яши алуы турындагы уйны кузгата. Ничәмә еллар завод өчен көрәште Арслан, ничәмә еллар кешеләргә тынгылык бирмәде. Завод әзер, аны пожардан йолып алып калдылар, ул җылы бирәчәк, шаулап-гөрләп эшләячәк...

Урамда кинәт мәтәм маршы уйнап җибәрделәр. Тынлыкны, өнсезлекне әрсез рәвештә җимереп кергән бу аваз Арсланны чынбарлык дөньясына кайтарды. Ул, урыныннан кисәк торып:

— Туктатыгыз музыканы! — диде.

Музыка аңар үлемнең чынлыгын, килеп туган хәлнең төзәтеп булмастай, кире кайтарып булмастай ачылыгын, дәһшәтен китереп җиткерде, хатынын күмәр вакыт җиткәнне аңлатып, балаларын исенә төшерде. Кайда алар? Кайда балалар? Рәфикъ белән Әлфиягә әниләренең үле гәүдәсен күрсәтергә кирәк. Моны ул, Арслан, үзе эшли алмаячак. Кем күрсәтер балаларга әниләрен, кем саубуллаштырыр? Кайнарланып, ачылып киткән аңы бер кешене күз алдына китерде:

Мөнәвәрә!

Әнә шул минуттан башлап, сабырсызланып һәм ашкынып, ул Мөнәвәрәне көтте. Таҗи белән Атнабайдан минут саен:

— Килмәдеме әле? — дип сорады.

Бу яңа тойгы мәрхүмәне озатырга килгән кешеләргә дә күчте. Кешеләр урамга чыгалар, юлларны карыйлар һәм, Арслан кебек үк ашкынып һәм борчылып көтәләр иде. Ишек алдын тутырган чуар киемле халык тыенкы гына гүли, оркестрантлар җиз торбаларын муеннарына киеп, барабаннарын җилкәләренә асып, бер читтә тәмәке тарталар, бортлары ачып куелган, кузовына зур хәтфә келәм җәелгән йөк машинасы, моторын

кабызган килеш, китәргә әзер булып тора, көткән кеше һаман юк иде әле.

Күрше хатыны Шәмсия кайгылы һәм үтә борчылган кыяфәт белән:

— Балаларны алып керергә ярыймы инде, аларга күрсәтәсезме? — дип киңәшләшергә кергәч, ишек алдындагы халык хәрәкәткә килде, әкрен генә ике якка аерылып, озын бер коридор ясады. Башына ике катлап зур яулык бөркәнгән, хәсрәтеннән тагын да кечерәебрәк калган, төенчек кадәр гәүдәле, сабыр йөзле Мәйсәрә түти; өстенә кара күлмәк, битен яртылаш каплап, кара яулык бәйләгән Мөнәвәрә халык ачкан коридордан үтә башлагач, көрсенеп куюлар, сак кына әйткән сүзләр ишетелә:

— Әнисе микәнни? И бичаракаем...

— Кара киемлесе апасыдыр инде...

Арслан килүчеләргә каршы чыкты. Атнабай аңар хәлне кереп әйткән иде. Әнисен җитәкләп килүче Мөнәвәрәне күрүгә — шып туктады. Мөнәвәрә дә бер генә мизгелгә туктады, Арслан белән баш кагып кына исәнләште дә, әнисен җитәкләгән көе, мәрхүмә яткан бүлмәгә кереп китте.

---

Ике айдан җир туңды. Беренче кар яуган йомшак иртәдә Мәйсәрә түти Рәфикъ белән Әлфияне җитәкләп, урамга чыкты. Балалар кара җирне каплаган, күкне иңләп коелган кар күбәләкләренә нәни учларын сузып, сөенеп, чыр-чу килделәр. Кар җилпәзәләре эченнән тоныклы кына булып гудок тавышы ишетелде.

— Завод кычкырта, әби, әнә завод...— диде Рәфикъ. Сеңелесе дә шуны ук кабатлады.

Ятим калган бу сабыйлар әтиләре өстенә нинди кайгы килгәнне аңламыйлар иде шул...

*1966—1967.*
*Әлмәт.*

□ □

## Камил Мостафин

### Төз наратлар утка аумасыннар

Безнең җирне яңа ак кар япкан,—
яңа кышның тәүге түшәге.
Төз наратлар гына көздән калган,
һәм без генә гүя — кичәге.

Ләкин карда инде күпме эз бар! —
Кичәгедән кергән эз ич ул.
Кар өстенә яңа сукмак салган,—
бүтән кеше түгел, без ич ул...

Без кичәге көннән үстек, дөрес,—
кышларыбыз булды буранлы.
Эпоханың көрәш янгыннары
яктырттылар безнең чырайны.

Без атлаган юлда корбаннар күп,
курганнар күп безнең юлларда,—
ул курганнар булып без ятабыз,
мылтыкларны кысып кулларга.

һәм наратлар булып без калганбыз,
күтәрелеп актык сулышта...
Ак кар яткан туган җиребезгә,
ә без, ә без һаман сугышта.

### Урманнарга тагын ялкын капкан...

Урманнарга тагын ялкын капкан,
яфракларны тагын ут алган.
Көзге урман, бар дөньясын онытып,
үзен үзе тыңлап тын калган.

Мин дә тыңлыйм әле бу тынлыкны
һәм сулышын алтын урманның.
Табыйм әле серен буш аланның,
гүзәллеген моңсу юлларның.

Белим әле: күзнең сары төсе —
үз төсеме, кояш төсеме!..
Эх, аңларга иде тулысынча
урманнарны, җирне, кешене!

## Кешеләр, китмәгез!

Кешеләр, китмәгез тәмугка,
кешеләр, китмәгез оҗмахка,
бөтенләй китмәгез, калыгыз,—
бу Җирдә — тәмуг та, оҗмах та!
Китмәгез!
Сез кирәк, кешеләр,
күлләргә, тауларга, юлларга.
Бигрәк тә сез кирәк,
сез кирәк
кызларга, улларга.
Эх, ничек йолырга үлемнән,
юл куймый кайгылы хәбәргә!..
Бер җылы елмаю чаткысын
алыштырмаячак һичкайчан
иң гүзәл мәрмәр дә.
Китмәгез...
Китәсез, китәсез!..
Калалар домналар, сарайлар.
Калалар,
күз яшен яшергән,
сезгә иң кадерле малайлар.
Малайлар үйлыйлар,
малайлар
тормышның серенә төшенә.
Малайлар үсәләр,
һәм Җирдә
мәңгегә калалар кешеләр.

## Күңелемдә сабый малай яши...

Күңелемдә сабый малай яши.
Үзем үстем, ә ул кечкенә...
Ерак юлым мине алып чыкты
Урал биргән җырлар дөньясына
һәм кояшлы таулар өстенә.
Ә тегендә,
юлым сукмак кына
булган җирдә, нәни адашым
әле һаман ашыга әллә кая,
әле һаман йөри адашып...
Саба тыкрыклары буйлап йөри,—
ялан аяк атлый чирәмнән.
Аны, ахры, әние: — «Бар, улым,— дип,—
язмышыңны тап»,— дип, җибәргән.
һәм ул юлда әле,
белми әле

хыянәтнең нәрсә икәнен,
тәүге мәхәббәтнең пакь икәнен.
Ул тапмаган әле бу тормышның
татлы балын, кара икмәген.
Без бер кеше, тик мин үстем менә,
ә ул, сабый, һаман кечкенә.
Борынын тартып миңа карап тора,
иске күлмәк кигән өстенә.
Саба тыкрыклары буйлап йөри,—
ялан аяк атлый чирәмнән.
Аны, ахры, әние: «Бар, улым,— дип,—
язмышыңны тап»,— дип җибәргән.
Һәм ул эзли, күрә, белә бара
кояш нурын, язны, яктыны...
...Тик мин генә белмим:
ул, ниһаять,
үз язмышын эзләп таптымы!..

●

Мин — бер кеше, шуңа күрә миңа уртак
кешеләрнең өметләре, язмышлары.
Мин бит кеше, шуңа менә йөрәгемдә —
кешеләрнең язмышлары, сагышлары.

Янгын — афәт, давыл — дәһшәт, үлем — хәсрәт,
нинди җилләр бәрми минем ишегемә.
Ләкин миңа барлык кайгы-хәсрәтләрнең
иң авырын алып килә кеше генә.

Үзем уйлыйм: кырлар матур, таулар матур,
гөлбакчамда бүген шомырт исе генә,
ләкин җирдә миңа барлык шатлыкларның
иң гүзәлен бүләк итә кеше генә!

■ ■ ■ ■

## Сафа Сабиров

# ГӘРӘЙНЕҢ БЕР ҖӘЕ

хикәя

I



Менә, ниһаять, укулар да бетте. Имтиханнарны әйбәт тапшырдылар. Барысы да шат, күнелләр күтәренке.

Гәрәй дә яхшы тәмамлады. Аның да күнеле, менә шушы кояшлы матур көн кебек, аяз һәм якты.

Бер караганда, тормыш дигәнең гаҗәп икән. Әле кайчан гына Гәрәй, күрше кызы Нәсимә белән икесенә бер төсле өр-яңа форма киеп, китап-дәфтәр тулы зур сумка тотып, беренче тапкыр мәктәпкә барган иде. Нәсимәнең бер кулында чәчәк иде. Икесенең дә әниләре урамга чыгып озатып калдылар. Нәсимәнең әнисе Гөлсем апа бик борчылган иде: «Гәрәй, син малай кеше, күз-колак бул, яме, малайлар Нәсимәне кага-суга күрмәсеннәр»,— дигән иде.

Барысы да, әйтерсең, әле кичә генә булган. Уйлап карасаң — ун ел үтеп тә киткән. Бүген мәктәпне тәмамлау кичәсе, бүген өлгергәнлек аттестаты бирәчәкләр.

Гәрәй сәгатенә карап алды. Әле төш вакыты гына. Кич җиткәнче ул Нәсимә белән Иделдә су кереп, көймәдә йөреп кайтырга сүз куешкан иде. Гәрәй инде баядан бирле тәрәзәдән күзен алмый: сигнал күренүен түземсезлек белән көтә. Элек алар бер-берсе янына тартынмыйча йөрешә торганнар иде. Икенче ел инде Нәсимәнең әнисе Гөлсем ханым Гәрәйгә кырын карый, кызының Гәрәй белән дус булуын теләми. Гәрәйне урамда очраткан чакта да күрмәмешкә салынып узып китә.

Нәсимә белән Гәрәй, аңар карап, әлбәттә, очрашмый калмыйлар, элеккедән дә битәр бер-берен күрергә атлыгып торалар. Мәктәптә алар һаман бергә. Өйдә чакта тиз генә күрешергә кирәксә, хәбәрләшү өчен үзләре генә белгән яшерен сигналлары бар... Менә хәзер дә Нәсимәләрнең почмак тәрәзәсеннән ак пәрдә яртылаш ачылып, кызыл чәчәкле кына гөле күренүгә, Гәрәйгә канат куйгандай булды, һәм ул, дөньясын онытып, кичтән сүз куешкан урынга — бакча артына чапты.

Ул барып җиткәндә, Нәсимә инде чыгып өлгергән һәм, шаярып, сәрви агачлары арасына посып, авыз эченнән ишетелер-ишетелмәс кенә нидер көйләп тора иде. Гәрәй яшел яфраклар арасыннан аның ак эшләпәсен һәм җәйге сары күлмәген күреп алды. Нәсимәне үсендереп җибәрү өчен, юри күрмәгән булып: «Күк-күү, күк-күү, сине эзләргә мөм-

кин күпмү,— дип,— кая качтың соң син, сары күбәләгем?» — дип, әкрен генә тавыш биреп, ярату һәм сагыну хисләре белән аны эзләп йөрде.

Нәсимә, кош кебек пырхылдап, куаклар арасыннан очынып килеп чыкты да:

— Сонга калабыз ич, көймәләрне алып бетергәннәрдер инде! Нишләп шулкадәр озак эзлисең? — дип шаулатып көлеп җибәрде, һәм алар, кулга-кул тотышып, биек таудан йөгереп төшеп киттеләр.

Су буе, кырмыска оясы кебек, гөж килеп тора. Сары ком өсте кояшта кызынучы халык белән тулы. Вышкадан сикерәләр, пароходлар кузгаткан дулкыннарга чайкалалар, көймәләрдә йөзәләр. Басмаларга бәйләп куйган җиңел көймәләр янында бер төркем яшьләр чират тора. Гәрәй белән Нәсимә дә шулар янына барып чиратка бастылар.

Озак та үтмәде, пристань каршындагы кафедан бер кыз белән ике матрос килеп чыкты да, чиратсыз-нисез алга үтә башладылар. Күренеп тора: матрослар кызмача. Бигрәк тә озын буйлысы бүртенгән. Чират торучылар ачулана башлагач, кыз белән янәшә үк баручы икенче матрос уңайсызланып шундук туктады. Ә теге колгасар матрос, куллары белән кешеләрне аралый-ера, һаман алга узмакчы булды. Бу хәлгә кинәт ачуы кузгалган Гәрәй тиз генә капка янына барып басты да:

— Күрмисезмени, кешеләр чират тора бит!? — дип, тегенең юлын бүлде.

Матрос башта бер генә мизгел аптырап калды. Чират торучыларның исерек белән бәйләнергә теләмәвен күргәч, тагын батырая төште һәм, Гәрәйне читкә этәреп, капканы ачарга сузылды. Гәрәй тагын аның каршына килеп басты — капканы ачарга ирек бирмәде. Тарткалаша торгач, ул, ялгыш элэктереп, матросның күлмәк җиңен төбеннән үк умырып чыгарды.

Чираттагылар тынып калдылар. Матрос, иелеп, өзелгән җиңен кулына алды, чынмы бу, әллә төш кенәме дигәндәй, җиңне әйләндереп карады да, кинәт кабынып китеп, җиңсез кулы белән яман кизәнә-кизәнә:

— Ни эшлисең син?.. Беләсеңме, моның өчен мин сине...— дип Гәрәйгә ташланды. Ләкин ул, Гәрәйгә сукмакчы булып селтәнгәндә, ялгыш көймәче картка китереп бәрде.

Эш болайга киткәч, башкалар да түзмәде. Моңарчы бу ызгышка катнашырга теләмичә бер читтә карап торган ике таза егет, Гәрәйгә ярдәмгә килеп, дулаган матросның кулын артка бик тиз каердылар. Кайдадыр якында гына кемдер колак тондыргыч ачы тавыш белән сызгырып җибәрде. Шау-шуга халык җыела башлады. Исерек матросның иптәше якынрак килде дә:

— Халит, милиционер килә, элэктергәнче, әйдә, үкчәне күтәрик,— диде һәм тизрәк китәргә борылды.

Әмма алар китеп котыла алмадылар. Шул арада бер милиционер белән дружинниклар килеп җитте. Күп сөйләшеп тормастан, ике матрос белән бергә Гәрәйне дә бүлеккә алып киттеләр.

## II

Гәрәй чыгарыш кичәсенә әнисе белән барды.

Бәйрәмчә киенгән классташлары һәм кунаклар тулы зур якты залга килеп кергәч, ул ничектер аптырап калды. Үз өендә туган-үскән йорт кебек иялэшеп, күңелгә үз булып җиткән бу залга бүген соңгы мәртәбә килүен уйлагач, анар моңсу булып китте. Ихтыярсыз, әйләнә-тирәсенә күз төшерде. Бер ул гына түгел, бу минутта бүтәннәр дә үзләрен шулай хис итәләр, ничектер җитдиләнеп калганнар иде.

Гәрәй, әйләнә-тирәгә каранып урын эзләгәндә, бераз алдарак утыручылар арасыннан Нәсимәнең кояш кебек балкыган йөзен күреп алды. Ул, матур ак кулын болгап:

— Гәрәй-й!.. Безнең янга кил, мин сиңа урын алып куйдым,— дип дәшә иде. Ул Гәрәйнең үзе генә булмавын күреп, әнисе янына кысылыбрак утырды.

Нәсимә көндезге сары күлмәген алыштырган — ак ефәк күлмәк кигән, куе коңгырт чәчен артка яткырып тараган; муенындагы яшькелт мәрҗәннәре, кузгалган саен, су өстендәге вак дулкыннар кебек җемелди иде.

— Ярый әле, килеп җиттең,— диде ул, Гәрәй килеп утыргач.— Юкса мин монда бик борчыла башлаган идем... Башка әллә нинди уйлар килеп бетте... Шундый шатлыклы көн... Ә сине ябып куйсалар. Уф! Ничек җибәрделәр?

Гәрәй, аның әнисеннән уңайсызланып, милиция идарәсендә нилэр булганын сөйләп тормады, чөнки Гөлсем ханым алар белән ым кагып кына исәнләште. Ул Нәсимәнең Гәрәйне күрүгә кинәт җанланып киткәнен һәм аңа таба борылып елмаеп сөйләшкәнен өнәп бетермәде булса кирәк, ризасыз бер төс белән тамак кырып куйды. Ә Нәсимәнең моңа исе дә китми, аның үз кырыгы кырык. Классташларыннан берәрсе күзенә чалынды исә, искитмәле ачыш ясагандай:

— Илдусны күрегез әле, Илдусны...— дип гаҗәпләнә.— Нинди важный утыра, министрмыни!.. Әтисен күрсәң, әтисен! Үзе — милиционер, үзе шук малай кебек, шаярып-көлеп кенә йөри.

Илдус Абдуллин белән дус булса да, Гәрәй аның әтисен якыннан белми иде. Көндез милиция бүлегендә очрашканнан соң, аны монда тагын күргәч, Гәрәйгә бераз уңайсыз булып китте һәм шул якка бүтән карамаска тырышты.

Тиздән сәхнәгә мәктәп директоры Шәрифҗан Вәлиевич, укыту бүлеге мөдире, класс җитәкчеләре, ата-аналар советы членнары чыгып кызыл постау җәелгән зур өстәл янына утырдылар. Шәрифҗан Вәлиевич унынчы класс укучыларын мәктәпне тәмамлаулары белән тәбрикләде:

— Алда сезне зур тормыш, зур эшләр көтә. Тормыш дигәнең гел ал да гөл булмый, сикәлтәләр, төрле киртәләр дә очрый. Әмма, аңар карап, чигенергә ярамый. Нык булырга, кыенлыкларны җиңә белергә кирәк. Шунсыз зур максатка ирешеп булмый,— диде.

Гәрәй бу кичәдә үзен ничектер икегә бүленгәндәй хис итеп утырды. Идел буендагы күңелсез вакыйга онытылды. Күзе сәхнәдә булды, чират җиткәч, аттестатын барып алды. Болар бар да ихтыярыннан тыш, үзеннән-үзе эшләнде. Ә колагында Нәсимәнең әледән-әле пышылдап кына әйткән сүзләре булды...

Кичәнең беренче өлеше беткәч, ата-аналар, укытучыларның күбесе өйләренә кайтып киттеләр. Тәнәфес вакытында эскәмияләрне коридорга, күрше бүлмәләргә чыгарып, стена буйларына күчереп куйдылар. Иркенәеп калган залда оркестр уйный башлауга, күпләр шундук парпар чыгып биергә тотындылар. Барсының шатлыгы йөзенә чыккан, бу шатлык һәркемнең күләмсәр карашында, оча-куна йөрүләрендә сизелә иде. Бер-берсенә карашып алуга, Гәрәй белән Нәсимә дә, алдан сүз куешкандай, шундук кулга-кул тотышып җиңел көйгә бии башладылар.

Бала чактан бергә уйнап, бергә укып үскән бу кызның үзен дә, тормышын да Гәрәй яхшы белә. Әнисе аның мәгариф бүлегендә эшләү белән бергә, тиздән диссертация якларга, галим булырга җыена. Аны бик тәкәббер кеше, мәктәп директорлары аның белән сүзгә килмәскә тырышалар дип сөйлиләр. Нәсимәнең әтисен Гәрәй бары бер тапкыр, былтыр пароходта үтеп китешли кызы янында булган чакта гына күреп калды. Кешеләр әйтә, имеш, ул, хатынының тәкәбберлеге белән киле-

шә алмыйча, өеннән чыгып китәргә мәҗбүр булган да шуннан әйләнеп кайтмаган. Мәскәүдә гыйльми эштә икән. Гәрәй аны бер күрүдә яратты: бик ачык, кече күңелле кеше. Нәсимә төскә-биткә әнисенә тартым булса да, холкы белән нәкъ әтисе: һәркайчан ачык йөзле, шат күңелле булыр.

Биеп туйгач, барысы бергә залны янгыратып җыр җырладылар, уеннар уйнадылар. Түгәрәк уен вакытында Гәрәйне уртага тартып чыгардылар да: «Җырла да җырла» — дип кыстый башладылар.

Гәрәй каушады, кып-кызыл булып кызарды, җырлый белмим ич мин, дип тизрәк уртадан чыгып китәргә теләде. Кызлар, бер-берсенә куллары белән тотышып, аны чыгармадылар.

— Беләбез, беләбез! Сиздермәгән булып йөрмә,— диделәр.

Гәрәй җырламый калу мөмкин түгеллеген аңлады. Ләкин ул тагын оятка кала язды, бу минутта аның бар белгән җыры кинәт онытылган булып чыкты, һәм ул, ни башкарырга белмичә, аптырап калды: «Алдап хәзерләп куярга башка да килмәгән»,— дип, кашларын җыерып бер мәлгә уйланып торды. Менә ул Нәсимәнең дустанә күз карашын күрде, шуннан соң җиңел сулап, елмаеп куйды һәм эчке дулкынлану белән җырлый башлады:

Күктә кояш, җирдә гөлләр,
Алда юллар, юлда мин.
Күктә йолдыз, җирдә син —
Җан сөйгәнем гөлгә тиң.
Дөнья матур, дөнья киң!

Гаҗәп хәл, һәркемгә таныш булган һәм еш башкарыла торган бу җыр бөтен залның игътибарын үзенә җәлеп итте. Үзара сөйләшүләр дә, уен-көлкеләр дә кинәт бетте, барысы да, Гәрәйне әле генә күргәндәй, сәерсенеп тынып калдылар.

Гәрәйне чынлап та танырлык түгел: ул үз җырына үзе дулкынлана һәм эченә сыймаган шатлык хисләрен иптәшләре белән уртаклаша иде. Бу хисләр башкаларга да якын тоелган булса кирәк, кинәт башкалар да бер тавыштан аңар кушылып җырларга тотындылар.

Җыр кузгаткан хисләр шундый күп иде, мәктәп белән саубуллашканда һәрбер класска аерым-аерым кереп йөрделәр, парталар арасына утырып карадылар.

Аннары алар төркемнәре белән Идел буена төшеп киттеләр. Әле кояш чыкмаган, еракта, Каравыл таулары турысында офык чите алсуланып кына килә, тынып калган Идел өстендә, хыял кебек билгесез һәм өмсендергеч матур булып, таң шәүләсе ята иде.

Һәркемнең аеруча якын күргән дусы бар икән. Әле бер, әле икенче пар төркемнән ничектер сиздерми генә аерылып китә яки су өстендә чайкалган көймәләр янына тукталып кала иде. Икәү генә калып бер мәл сүзсез баргач, Нәсимә иң яраткан укытучысы — әдәбиятчы Галия апасын мактап сөйләде һәм үзенең дә әдәбият укытучысы булырга теләгәнен әйтте. Аннары ул:

— Гәрәй, ә син кем булырга телисең? — дип сорады.

— Минме?.. Мин... җырчы булам,— диде Гәрәй һәм кинәт әйтеп ташлаган бу сүзләрдән хәтта үзе дә уңайсызланып калды.

Дөресен генә әйткәндә, үзенең киләчәге, кая укырга барасы турында ачык итеп уйлаганы, нинди дә булса төпле бер фикергә килгәне юк иде әле Гәрәйнең. Аның күңеле әллә кайларга ашкына... Биек яр өстеннән Иделгә карап хыялга чумып утырган минутларда мәһабәт пароходлар да йөртәсе, галәм дәрьяларын гизүче космонавт та буласы килә. Ә соңгы вакытта аны бүтән теләк, үзенә-үзе атап әйтергә дә базымы җитмәгән яңа бер хыял дулкынландыра, ерактагы якты маяк уты кебек, үзенә чакырып тора башлады. Концертларда, радио тапшыруларында

ул үзенең яраткан жырчыларын тыңлый һәм, аларга ияреп, үзе дә гел жырлап йөри иде.

— Бик дөрес итәсең, Гәрәй. Сиңа жырчы булырга кирәк. Синең тавышың матур, моңлы... Мин моны күптән сизеп килэм, син әллә ничек менә рухланып жырлый беләсең. Тыңлаучыларның да күңелен кузгатасың...— диде Нәсимә.— Мин үзем менә жырлаган чакта кемне дә булса уйлап, кемгәдер атап жырлыйм... Син дә шулаймы?.. Әгәр шулай булса, әйт әле, син бүген теге жырны кемгә атап жырладың?..

Гәрәй кызның ике кулыннан тотып:

— Әйтимме?.. Дөресен әйтсәм, ачуланмассыңмы? — дип аның күзләренә карады.

— Әйт, әйт. Тик дөресен әйт... Билгесезлектә газапланганчы, хәзер үк әйт, берьюлы ачыклансын...

— Алайса бел: мин сине уйлап жырладым, сиңа гына атап жырладым... Мин һаман сине уйлап жырлыйм,— диде Гәрәй, ул кинәт Нәсимәне кочаклап алды һәм, күзләрен йомып, аны битеннән үпте...

Су буйлап алар озак йөрделәр. Иртәгә тагын шунда очрашырга сүз куешып, таң алдыннан гына кайтып киттеләр.

## III

Пристаньнан берничә километр түбәндәрәк, елганың уң як ярында, биеклеге һәм мәһабәтлеге белән бөтен Идел буена атаклы Каравыл тавы тора. Хәзерге Кызыл яр поселогы урнашкан урында борынгы заманнарда болгарның зур крепосте булган диләр. Дошман яулары кинәт килеп төшмәсен өчен, сигналчылар әйләнә-тирәне шул тау башыннан күзәтә торган булганнар, тауның исеме дә шуннан калган дип сөйлиләр.

Гәрәй белән Нәсимә иртәгесен әнә шул текә кыяташ төбендә очраштылар. Нәсимә, башын күтәреп югары карауга:

— Әбәү, бигрәк текә, өскә җимерелеп төшмәгәе...— дип хәйран калды һәм ихтыярсыз артка чигенде.

— Әле түбәннән шулай ул. Әгәр түбәсенә менеп карасаң, бөтенләй исең китәрлек...

— Минем анда бер дә менгәнем юк бит әле. Гәрәй, әйдә меник...

Тарихи риваятьләрдә телгә алынган бу атаклы тау башына Гәрәйнең моңарчы да берничә тапкыр менгәне һәм, түбәндә салмак кына чайкалып аккан киң Иделгә карап, озак-озак уйланып утырганы бар иде. Нәсимә әйткәч, ул тагын җилкенеп китте һәм озак уйланып тормастан:

— Әйдә менәбез... Киттек! — диде.

Каравыл тавы, су төбеннән үсеп чыккандай, текә кыяташ булып күтәрелгән һәм аның елгага караган ягы җил-янгыр ашаудан, картлар бите кебек, җыерчыкланып беткән. Аның түбәсенә турыдан гына һич тә менәрлек түгел. Гәрәй белән Нәсимә уңга борылдылар һәм, тирән тарлавык эченнән бераз барганнан соң гына, сөзәгрәк яктан күтәрелә башладылар.

Болай да бөркү көн тиздән тагын да кыза төшкәндәй булды. Гәрәй рюкзакка салып бәрәңге, икмәк, термос белән салкын су алган иде. Башта сизелмәсә дә, үргә менә торгач, ул да авыр тоела, иелеп калку ташларга, тал-чыбыкларга тотынганда әле бер, әле икенче якка авышып йөдәтә башлады. Кызудан Нәсимәнең дә битләре алсуланды, мангаена, күз төпләренә вак-вак тир бөртекләр бәреп чыкты. Тарлавыктан чыгып тауның беренче кәрнизенә күтәрелгәч, тын алырга туктаган бер арада, ул кыя читенә якынрак барып карамакчы булган иде.

— Юк, юк, моннан карама, бераз гына түзә күр,— диде Гәрәй, аны туктатып.— Бу әле тауның яртысы гына. Әнә теге өркәч түбәне күрә-

сеңме? Шунда менеп житкәч карарсың. Аның бөтен кызыгы да шунда: иң югарыдан карауда...

Бераз ял итеп алдылар да тагын юлга кузгалдылар. Тауның бу ягы артык текә булмаса да, зур-зур ташларны һәм ишелеп төшкән урыннарны читләтеп үтәргә туры килә иде. Калку ташларга, җир астыннан чыгып торган агач тамырларына тотына-тотына, тирләп-пешеп күтәрелә торгач, алар, ниһаять, Каравыл тавының түбәсенә менеп җиттеләр һәм күз алларында ачылган чиксез-кырыйсыз күгелҗем киңлеккә хәйран калып озак карап тордылар.

Тау башы вак чикләвек агачы белән капланган. Тауның нәкъ уртасында, куе ботакларын як-якка җәеп, бакырдай саргылт кәүсәле мәһабәт нарат үсеп утыра. Шуннан сулдарак текә киселеп төшкән кыяташ итәгендә салмак кына тибрәлеп һәм кичке кояш нурларында иркәләнеп Идел ага. Аның өстендә ак тасмадай күбекле эз калдырып үткән теплоходлар, кәрваннар моннан караганда тартмадай гына булып күренә иде. Аларның бер-берсенә юл бирешеп кычкырткан гудоклары таш кыялар, тарлавыклар арасында бәрелә-сугыла югарыга менеп җиткәнче хәлсезләнеп бетә һәм тонык кына булып ишетелә иде. Кайдадыр еракта яңгыр ява булса кирәк, аргы яктагы күгелҗем урманнар артыннан бөтен офыкны каплап өер-өер кара болыт күтәрелеп килә иде.

— Нинди киңлек... Иге дә юк, чиге дә... Әллә ниләр уйлата, күңелләрне җилкетә,— диде Нәсимә, күзләрен зур ачып бер мәл карап торганнан соң.— Кара әле, Гәрәй, җыр да шулай бит: күңелне әллә кайларга алып китә, әллә ниләр уйлата... Шулаймы?..

— Әйе, дөрес әйтәсең, җыр да шулай,— диде Гәрәй, аны кулыннан алып.— Мин шуңа гаҗәпләнәм, бер үк фикер ике кешенең башында берьюлы ничек туа икән?

Тауның Иделгә таба авышкан ягында, теге баһадир нараттан сулдарак, яртылай җиргә иңеп кергән зур салпы таш бар. Гәрәй белән Нәсимә, коры чыбык-чабык җыеп, шул таш янында учак ягып җибәрделәр. Бераз көл төшкәч, бәрәңге күмделәр. Төрле сүз арасында Нәсимә бүген монда чыгар алдыннан әнисе белән үпкәләшкәнен әйтте:

— Шуны һич аңламыйм, синең белән дуслашканны яратмый, шуның өчен ачулана,— диде.— Ә мин, үч иткән кебек, сине күрми тора алмыйм, һаман синең хакта уйлап кына йөрим...

Учак янында шулай сөйләшеп утырганда кинәт кайдадыр югарыда дөбердәп күк күкрәп үтте. Күтәрелеп карасалар, Идел аръягыннан каты яңгыр килә икән. Бая урманнар артыннан күтәрелеп килгән кара болыт күк йөзен яртылаш каплап өлгергән, көнбатыш якта әле сүнеп бетмәгән шомлы кызгылт шәфәкъ яктысы гына тонык булып балкый, һава бик бөркүләнгән иде. Әйләнә-тирәдә бар табигать, барча җан иясе ничектер тынып, сагаеп калган. Каршыдагы баһадир нарат кына, бернигә исе китмәгәндәй, караңгы күк фонында горур басып тора иде...

Менә көнбатышта соңгы шәфәкъ балкышын да болыт каплады. Каяндыр бәреп чыккандай, чикләвек агачларын шаулатып һәм учак утларын тузгытып кинәт дымсу җылы җил исә башлады. Тагын күк күкрәде һәм агач яфраклары өстендә шыбырдап эре яңгыр яварга тотынды.

Гәрәй белән Нәсимә башта теге баһадир нарат төбенә барып посмакчы булганнар иде. Яңгыр бик каты бәреп ява башлагач, анда барып җитәргә вакытлары калмады. Әйберләрен тиз генә рюкзакка җыеп алдылар да әлеге таш астына кереп ышыкландылар.

Тиздән караңгылык тагын куера төште һәм тирә-юньдә берни дә күренмәслек булды. Шомлы төн карасын телгәләп, күзләрне чагылдырырлык ялт-йолт итеп баш очыннан гына яшен камчысы чыкылдап үтте, аннары тау-ташларны тетрәтеп тагын күк күкрәде һәм шундук

якында гына жир астыннан янар таудай ут фонтаны бәреп чыкты. Каты җил аның очкыннарын йолкып алып әйләнә-тирәгә тузгыта башлады. Бу хәлдән тәмам коты очкан Нәсимә:

— Гәрәй, бу нинди тамаша?! Мин куркам...— дип кычкырып җибәрде һәм калтыранган куллары белән Гәрәйгә тотынды.

Гәрәй башта үзе дә куркуга калган иде. Яраткан кызның шул хакта әйтеп, җылы тәне белән дер-дер килеп сыңа сыенганда, куркуының белдерергә ярыйммы соң! Өстенә коелган утлы очкыннар муенын, битен пешерә башлагач, ул, зиһенен җыеп, югарыга карады һәм баягы баһадир наратны яшен сукканлыгын аңлап, җинел сулап куйды. Нарат төбеннән очына кадәр дөрләп яна, давыл аның утлы күмергә әйләнгән тармакларын, ылысларын әйләнә-тирәгә тузгыта икән. «Ярый әле шул нарат төбенә ышыкланмадык, югыйсә һәлак буласы икәнбез»,— дип шомланып һәм сөенеп уйлады Гәрәй.

Ул Нәсимәне тынычландырырга өлгермәде, ут өермәсенә әйләнгән нарат, төптән киселгәндәй, җил уңаена янтая башлады һәм меңнәрчә чаткылар чәчрәтеп һәм тончыктыргыч кызу төтен бөркеп, утлы ябалдашы белән гөрселдәп ауды. Куркудан миңгерәүләнеп калган Нәсимә еламсыраган тавыш белән:

— Ух, харап булдык...— дип кенә әйтә алды һәм хәлсезләнеп сыгыла башлады.

Гәрәй аны чак кына тотып калды һәм, башыннан, калтыранган иннәреннән сыйпый-сыйпый:

— Курыкма, Нәсимә, куркырлык берни дә юк,— дип тынычландырырга тырышты.— Нарат кына ауды, бары шул гына. Тынычлан, матуркаем, тынычлан инде. Әнә давыл да басыла. Хәзер, туктагач та кайтабыз да китәбез...

Давыл, дөрестән дә озакка бармады. Күк күкрәве һәм яшен яшьнәве таулар артына, далага таба үтеп китте. Аргы яктан искән җил болытларны куып таратты да тиздән үзе дә хәлсезләнде, тынды. Яңгыр да туктады. Аяз күк йөзенә йолдызлар калыкты, су өстендә пароход утлары, йөзмә маяклар җемелдәп күренде. Куаклыкта кыюсыз гына кош-корт черкелди башлады. Дәһшәтле давыл корбаны — янып бетмәгән нарат кына, яуда яраланган батыр сыман соңгы сулышын алып — әле һаман чатнап куя, янган ылыс һәм чәер исле ачы төтен бөрки иде.

— Менә әйттем ич, үтте дә китте,— диде Гәрәй, Нәсимәне юатып.— Я, үксемә, тынычлан... Өс-башыңны рәтлә дә, өйгә кайтабыз... Ишетәсенме, әйдә кайтабыз дим...

Әмма Нәсимә аны ишетми дә, аңламый да. Аркасы белән ташка сөялгән хәлдә исәнгереп тик тора һәм әледән-әле сискәнеп куя иде. Әйтеп-әйтеп тә төшендерә алмагач, Гәрәй дә шомга төште һәм, ахыр чиктә, аны култыклап алып кайтырга чыкты. Нәсимә, миңгерәү кеше кебек, аяк астына карамыйча, абына-сөртенә атлады, һаман үкси-үкси кайтты. Тау башыннан төшкәндә берничә тапкыр чак кына егылып харап булмый калдылар, бөтен өс-башлары буялып бетте.

Алар поселокка кайтып кергәндә вакыт бик соң түгел иде әле. Урамнарда чокыр-чакырлар яңгыр суы белән тулы, кайбер йортларның рәшәткәләре, капкалары аударып ташланган, һәркайда каты давыл эзе күренеп тора иде.

Олы урам чатыннан үткәндә Гәрәй Нәсимәнең өс-башын магазин уты яктысында күреп аптырап калды: кызның сары күлмәге дә, ак эшләпәсе дә балчыкка былчыранып ала-кола төскә кергән һәм манма су булып чыланган. Юеш чәче маңгаена, битләренә төшеп ябышкан. Йөзендә җан әсәре юк. Күзләре ничектер мәгънәсез карый, үзе һаман бөтен гәүдәсе белән калтыранып үкси иде.

Гәрәй аны өйләренә хәтле озатып куйды. Әмма кыз, кайтып житкәч тә, үз өен танымагандай, капка төбендә тик тора бирде. Гәрәй аны

урамда ялгызын калдырырга арусынмыйча, капканы үзе шакыды һәм, эчке яктан Гөлсем ханымның өйалды ишеге ачканын ишеткәч кенә, аның күзенә күренмәс өчен, ашыгып китеп барды.

## IV

Бик нык йончылган һәм шомга төшкән Гәрәй өйгә кайту белән ятып авыр йокыга талды. Албасты баскан кебек куркыныч төшләр күреп газапланды, бернichә мәртәбә сулышы кысылып уянды, тирләп бетте. Бераз тынычланып тагын йокыга китте исә, күз алдына кабат шул коточкыч давыл килеп баса, тагын шул яшен суккан ялгыз ут-нарат өстенә ава башлый һәм, аягы-кулы бәйләнгәндәй, талпына алмыйча гаҗиз булып кала иде. Менә аны тагын кемдер уята кебек тоелды. Әмма бу юлы саташу түгел, баш очында әнисе басып тора иде.

— Тор әле, Гәрәй, өстенә киен,— диде ул борчулы тавыш белән.

Әле таң атмаган, бүлмә эче караңгы, ярым ачык ишектән түр якта ут яктысы күренә, кемнәрнеңдер сөйләшкәне ишетелә иде. Гәрәй, йокыдан уяна алмыйча:

— Иртә ич әле, таң да атмаган... Йоклыйсым килә,— дип стенага таба борылып ята башлаган иде.

— Гәрәй, әйдә тор әле. Әнә анда сине сорап килгәннәр,— дип, әнисе тагын аның иңбашына кагылып алды.

Шул арада түр яктан әтисенең ачулы тавыш белән:

— Нәрсә ул анда иркәләнеп ята?! Тәрт тә уят үзен,— дип кычкырганын ишетеп, йокыдан тәмам айныды һәм, шундук барысын да абайлап, йөрәге жу итеп китте.

Тиз генә торып, җиңсез майкасын, әле кибеп тә өлгермәгән чалбарын киде дә, калтыранган куллары белән чәчләрен рәтли-рәтли, түр якка чыкты. Эре шакмаклы сары эскәтер җәелгән өстәлнең бер ягында Нәсимәнең әнисе Гөлсем ханым белән милиция лейтенанты Абдуллин, каршы якта Гәрәйнең әтисе утыра иде. Аны да хәзер генә уятканнар күрәсең: өстендә буй-буй сызыклы пижама гына, әле йокысы да ачылып җитмәгән.

— Менә шул үзе,— диде ул, Гәрәйгә ачулы карап.— Әнә сине эзләп килгәннәр. Сөйләп бир: син ничек шул хәлгә төштең?.. Син сабый түгел инде, үзең өчен үзең җавап бирергә тиешсең...

Гәрәй аптырап калды һәм, бер мәл ни әйтергә белмичә уйлап торганнан соң:

— Ни өчен җавап бирергә? Мин... берни дә аңламыйм,— диде.

— Кара син аны, артистмыни, ничек килештереп кылана!..— дип, кинәт Гөлсем ханым кабынып китте: аның матур йөзенә зәһәре чыккан, күзләре көйдереп алырдай карый иде.— Син монда аңламаган булып кыланып утырма, җинаятенне барыбер яшерә алмассың...

— Гөлсем апай, ни сөйлисез сез?.. Нинди җинаять? Тиктомалдан шулай ярыймыни?...

— Бу нәрсә, җинаять эзе түгелмени?.. Менә чалбарың үзе әйтеп тора, кызыл балчыкка буялып беткән ләбаса...

— Буялса соң? Яңгыр яуганга мин гаеплемени?..

— Я, житте, диванага салышып утырма монда...— Гөлсем ханымның ачудан бөтен гәүдәсе калтырый, ул көч-хәл белән генә тыелып тора иде.— Бу нәрсә, җинаять эзе түгелмени?.. Нәсимәнең күлмәге дә нәкъ шундый кызыл балчыкка буялган. Димәк, сез бергә булгансыз, син, юлбасар, аның котын алгансың, куркытып көчләгәнсең...

Гөлсем ханым сүзен әйтеп бетерә алмыйча, ярсуыннан сулышы кысылып, өстәлгә сыгылып төште һәм кычкырып елап җибәрде. Ә Гәрәй тик шунда гына, ни турында сүз барганын аңлап, өялүдән җир астына кереп китәрдәй булды.

— Шулай мөмкинмени? Ни сөйлисез сез? — диде Гәрәй һәм гаепсез икәнен кабат исбат итә алмаячагын тоеп, коелып төште: — Юк, Гөлсем апай, һич тә алай түгел, уйлый да күрмәгез. Инә очы хәтле дә гаебем юк. Әгәр ышанмасагыз, әйдәгез, Нәсимәнең үзеннән сорагыз...

— Ничек сорыйсың... Син аның котын алгансың. Телдән яздыргансың син аны, бер авыз сүз әйтә алмый ул. Стенага борылып яткан да үкси дә үкси.

Моңарчы сүзгә катнашмыйча тыңлап утырган милиция лейтенанты Гәрәйгә берничә мәртәбә гаҗәпләнеп карап алды, тамак кырып куйды. Әмма телдән аны-моны белдермәде. Өстәлдә яткан кара күн портфеленнән бер бит кәгазь, авторучка тартып чыгарды.

— Ярар, хәзер монда ызгышып торудан мәгънә юк,— диде ул, Гәрәйгә беравык игътибар белән карап торганнан соң.— Сине, егеткәем, хәзер үк кулга алырга кирәк иде дә, ярар инде, вакыт бик соң, бүгенгә өеңдә кун. Иртәгә сәгать унга милиция бүлегенә кил, шунда сөйләшербез. Ләкин, кара аны, беркая да чыгып китәсе булма, шул хакта менә монда кул куй...

Үзләре генә калгач, Гәрәй өйдәгеләргә барысын да сөйләп бирмәкче булган иде. Әтисе тыңларга да теләмәде, ышанычсызлык белән кулын селтәде дә йокы бүлмәсенә кереп китте. Соңгы вакытта ул гомумән еш кына кызып китүчән, юкка-барга бәйләнүчән булып киткән иде.

Ә Гәрәй бу нахак бәладән гаҗиз калды һәм йокыга китә алмыйча газапланып бетте. Бер-ике тапкыр күзенә йокы керә башлаган кебек булса да, шундук сискәнеп уянды һәм, бизгәк тоткан кебек, бөтен гәүдәсе белән калтыранып ятты. Аннары кисәктән генә күңеленә шик төште: милиция лейтенанты тагын килер дә бүлеккә илтеп ябып куяр кебек тоелды. Вакыт-вакыт ул хәтта аның аяк тавышын да ишеткәндәй булды һәм тиз генә торып тәрәзәдән карады. Әллә ничә тапкыр бер торып, бер ятып тәмам алҗып бетте, нервалана башлады.

Шулай газапланып ята-ята йокыга талган бер арада өйалдында кыңгырау шалтыраганы ишетелде. Түр яктан әнисе кузгалып ишек ачарга чыкканчы Гәрәй инде сикереп торган, йокыдан арынып өлгергән иде. Кинәт аның йөрәге тагын жу итеп куйды: димәк, аны кулга алырга килгәннәр... Озын-озын уйланып торырга вакыт юк, хәзер үк чыгып качарга кирәк... Әйе, хәзер үк...

Һәм ул шулай эшләде дә. Кем килгәнен ачыклап тормады. Әнисе тышта ишек ачып тегеләрне керткән арада, Гәрәй күлмәген, чалбарын тиз генә киде дә саклык белән генә тәрәзәдән бакчага сикерде. Таң әле беленеп кенә килә иде. Куркудан күзенә ак-кара күренмәде. Башын ия төшеп, юеш агачлар арасыннан җан-фәрманга чапты да чапты. Биек яр читенә килеп чыккач та туктамады, сукмак-фәлән дә карап тормады. Әңгер-меңгердә сөзәгрәк күренгән бер җирдән түбән ташланды һәм, мәтәлеп төшә-төшә, чак кына аягын-кулын сындырмады. Әмма үзе бу минутта авырту сизмәде, яр төбенә тәгәрәп төшеп житү белән, тиз генә аягына басты да абына-сөртенә чапты.

Идел аръягыннан дөньяга беренче нурларын сирпеп кояш чыкканда, Гәрәй инде Каравыл тавы башына менеп житкән иде. Ул бик алҗыган, басып торырлык та хәле калмаган иде. Бераз ял итәргә теләп, ташка аркасы белән сөялеп утырды... «Тукта, мин монда ник мендем соң әле?» — дип, гаҗәпләнеп үзеннән-үзе сорады, әмма нинди дә булса җавап таба алмады.

Кояш югары күтәрелгән саен яктырак балкый, катырак җылыта. Бар табигать яңа туып килгән матур иртәне шатланып каршылый. Әйләнә-тирәдә күбәләкләр оча, чәчәктән-чәчәккә кунып, умарта кортлары бал җыя. Чыр-чу килеп төрле кошлар, чикерткәләр черкелди. Кичә кич давыл аударган чикләвек куаклары, үләннәр, тураеп, яшәреп тора. Бары тик төнге дәһшәтле давыл корбаны — яшен сугып кара күмергә

әйләнгән бәхетсез нарат кына алан уртасында җансыз ята иде. Бу кояшлы матур иртә дә, шифалы саф һава да — хәзер инде болар берсе дә аның өчен түгел иде.

Бу минутта Гәрәй дә үзен әнә шул бәхетсез нарат хәлендә хис итте. Әле кичә кич кенә дөнья матур, дөнья киң иде. Шушы биек тау башында киләчәк тормыш юллары турында хыялланып утырдылар. Бөтен юллар ачык, барысы да мөмкин, бөтен дөнья шатлык һәм бәхет белән тулы иде.

Менә болар һәммәсе дә бер төн эчендә чәлпәрәмә җимерелде. Хәзер ул зур һәм якты дөньяда япа-ялгызы торып калды кебек...

## V

Шул чак аны куа килүчеләр тавышы ишетелә башлады. Алар күбәү бугай, этләре дә бар кебек. Үзләре күренмәсәләр дә, Гәрәй аларның якынаюларын сизә, әле бер, әле икенче якка ташланып котылырга тырыша, әмма куркудан тез буыннары калтырый, бар көченә чапса да, ерак китә алмый. Тиз арада аны, өч яктан камап алып, кыя читенә кысрыклап китерәләр. Башка чара калмагач, ул күзен йомып кыя таштан төпсез упкынга ташлана һәм куркып... уянып китә.

Гәрәй күзен ачып тирә-юньгә караганнан соң да бер мәл аңына килә алмыйча утырды. Ул күңелсез уйларга талган хәлдә аркасы белән ташка сөялеп утырган көе, үзе дә сизмәстән, изрәп йокыга киткән икән. Аркасы тирләгән, йөрәге дөп-дөп кага, сулышы кысыла. Әмма шунысына шат: берниндн куа килүче юк, барысы да авыр төш кенә булган икән.

Бераз тынычлангач, таудан төшеп Иделдә су керде, күлмәген чайкап таш өстенә киптерергә җәеп куйды, чалбарын, туфлиләрен чистартты һәм, кая барырга, нишләргә белмичә, аптырап калды. Өйгә кайтып күренү турында хәзер уйларга да ярамый, шундук тотып ябачаклар. Иң яхшысы — Казандагы Җәмилә әбисе янына ычкыну, ләкин юлга бер тиен дә акчасы юк...

Пристань белән Каравыл тавы арасында Паром пристане дип атала торган бер култык бар. Гәрәй, күңелсез уйларга чумып, каңгырып йөри торгач, шул култык читенә килеп чыкты һәм анда «Бурлак» исемле кечерәк кенә буксир пароходы күрде. Яр буенда зур-зур якорьлар, чылбырлар, тимер чыбыктан үрелгән юан арканнар өеме тора; бер төркем матрос шуларны пароходка төяп маташа иде. Гәрәй пароход турысыннан тиз генә үтеп китәргә тырышты. Бераз баргач, пристань ягыннан яр буйлап килүче бер кешене күреп алды: әлеге кешенең кулында чемодан, янынннан зур бер эт килә иде.

Гәрәй курка калды. Тизрәк шыларга кирәк. Ләкин кая? Бер якта су, каршы якта текә яр. Кирегә чапса, тагын теге пароход яныннан үтәргә туры киләчәк. Яхшылабрак караса, сул якта текә ярны кисеп чыккан тарлавык бар икән. Гәрәй тарлавык буйлап йөгерде дә зелпе куаклары арасына кереп посты.

Әмма ул тын алырга да өлгермәде, аның эзеннән иснәнә-иснәнә, бөтен тарлавыкны яңгыратып өрә-өрә, теге кешенең кара эте килеп чыкты һәм ярсып өрә башлады.

Ул арада этнең хуҗасы да килеп җитте.

— Ярамый! — дип кискен итеп дәште ул.— Я, Пират, җитте, тынычлан... Артык шаяра башладың әле син. Болай булсаң, бел аны, бәйдән ычкындырмам.

Чын спортчы кебек төз, таза гәүдәле, киң җилкәле, утыз яшьләр чамасындагы кеше иде бу. Киеменә караганда, елгачы булса кирәк. Өстенә зәңгәрсу китель, башына соры эмблемалы биек фуражка кигән.

Бөтен кыяфәтеннән үзенә ныклы ышану һәм тормышыннан канәгать булуы күренеп тора иде.

— Син монда нишләп йөрисең? — диде ул, Гәрәй агач башыннан төшкәч.

Гәрәй ни әйтергә белмичә бераз уйланып торганнан соң:

— Эм... болай гына,— дип ык-мык итеп куйды һәм бөтенләй теле бәйләнеп башын түбән иде.— Берни дә эшләмим, болай гына йөрүем. Су кереп кайтып килә идем...

Елгачы аның хәлен сизенде бугай, бүтән сораштырып тормады. Игътибар белән карап алганнан соң:

— Нишләп торабыз әле без монда?..— диде.— Әйдә чыгабыз...

Ерганактан чыккач, ул Гәрәйне тагын бер тапкыр баштанаяк күздән кичерде һәм, үзен генә калдырып китәргә теләмәгәндәй, яр күләгәсенә утырып бераз ял итеп алырга булды. Зур чемоданын ачып бер кирпеч кара икмәк, колбаса чыгарды, хәнҗәр хәтле зур пычак белән аларны телем-телем турады. Әйберләр арасыннан бер шешә аракы, стакан табып алды да:

— Бүген рәтләп ашаган да юк әле, вакыт тими. Әйдә утыр, бераз тамак ялгап алыйк,— диде һәм, бер стакан аракыны бушаткач, чыраен сытмый гына тамак кырып куйды.

Гәрәйнең беркайчан да аракы эчкәне юк иде. Мондый киң күңелле кеше ярты стакан салып биргәч, кыстатып торырга арусынмады. Кулына колбаса кисәге алды да, нәкъ аның кебек итеп, берьюлы голт итеп йотып җибәрде һәм, кинәт сулышы кысылып, катып калды. Тамак төбен, бөтен эчен, ут йоткандай, нидер яндырып үтте, күзләреннән яшь бәреп чыкты һәм колбаса кисәге кабып җибәргәннән соң гына көчкә тын алды. Елгачы үзе әйткәч кенә, Гәрәй моның аракы түгел, су кушылмаган чиста спирт икәнлеген белде.

Эчкәндә кыен булса да, спирт кызуы тиздән Гәрәйнең бөтен тәненә таралды, ничектер рәхәт, җиңел булып китте. Елгачыны Галләм Галиев дип йөртәләр икән. Үзе яр буенда торучы «Бурлак» пароходында беренче штурман булып эшли, хәзер аның авылда үлгән энисен күмеп кайтып килеше икән. Сүз арасында Гәрәй дә, теле ачылып китеп, нинди авыр хәлгә эләккәнлеген сөйләп бирде. Гәрәй сүзеннән туктагач, Галиев үзалдына сөйләнгәндәй:

— Шулайдыр, кыяфәтең бик мөшкел... Күрү белән сизеп алдым. Ярдәм итәсе иде бит сиңа...— дип әйтеп куйды һәм, кашларын җыерып уйланып торганнан соң, чырае яктырып китте: — Әйдә безнең пароходка, безнең бер матрос җитми, капитанны күндереп булса... бик үзсүзле кеше инде болай...

Алар «Бурлак»ка кайтып җиткәндә, команда яр буендагы йөкләрне палубага төяп бетергән һәм юлга кузгалып китәргә җыена иде. Гәрәйнең күзенә ташланганы шул булды: Галиевне берәүләр коры гына исәнләшеп, икенчеләре, киресенчә, чын күңелдән кайгысын уртаклашып, хәл-әхвәл сорашып каршыладылар. Пиратның да командага мөнәсәбәте шундыйрак булса кирәк; хуҗасы белән кул биреп күрешүчеләргә ул койрыгын дустанә селкеп җавап бирә, коры гына исәнләшүчеләргә йоннарын тырпайтып карап тора иде. Пароходта Гәрәйне белүче дә бар икән. Алгы палубада трап янында җыелган матрослардан берсе бик гаҗәпләнгән тавыш белән:

— Менә гаҗәп... Күрегез әле: танымыйсызмы бу асыл кошны? — дип кычкырып җибәрде.

Шул якка борылып карауга, Гәрәй хәйран калды: аның каршында өченче көн көймә алырга чират көткәндә бәрелешкән һәм бергә милициягә эләккән колгасар матрос Халит басып тора иде. Штурман Галиев, капитан белән сөйләшә-сөйләшә кызыл почмакка кереп киткәч, палубада калган Гәрәйне кичәге танышлары камап алдылар һәм

төрлечә шаярта башладылар. Арада иң әтәчләнүче һаман шул Халит булды.

— Синең белән кабат очрашуга әйтеп бетергесез шатмын! — диде ул.— Шундый тәртип саклаучы булгач, мин аны чынлап та рәтлерәк бәндә дип уйлаган идем, ә ул безнеңише бер штрафник икән...

— Кем әйтте аны, нишләп штрафник булыйм мин? — диде Гәрәй.

— Һи, кара син аны, ялганларга да өйрәнеп алган. Хәер, бездә беркем дә үзен штрафникка санамый, ничек итеп булса да әйбәтрәк пароходка китәргә тырыша. Ярар, зыян юк, әгәр капитанга тәлинкә тота белсән, син дә монда озак күгәреп ятмассың, бу әҗәл тагарагыннан тиз котылырсың.

Шул чак Гәрәйне кызыл почмакка капитан янына чакырттылар. Барып керсә, газета-журналлар җәеп куелган өстәл янында штурман Галиев белән капитан нәрсә турындадыр җанланып сөйләшеп утыралар. Капитан чигә чәчләренә чал кергән, зур күз тирәләрен вак җыерчыклар баскан, киң, калку маңгайлы, илле яшьләр чамасындагы кеше иде.

— Син безгә матрос булып керергә телисеңмени? — диде ул, Гәрәйгә түгәрәк күзләре белән бер мәл карап торганнан соң.— Тик шунысы уңайсыз, янында документларың юк икән... Гәрчә Галләм Галиевич әйтә, сине яхшы беләм, ди. Алай булгач, ярар инде, документларыңны соратып алдырырсың. Ә хәзергә эшли тор. Югыйсә хәзер безгә, сал йөртергә керешкәч, матроссыз кыен булачак.

Эшнең болай тиз җайлануына Гәрәй җиңел сулап куйды һәм ярдәм иткән өчен Галиевкә рәхмәт тулы күзләре белән карап алды. Ә штурман корт чаккандай:

— Нинди сал тагын ул? — дип кинәт кабынып китте.— Нинди акыллы башы уйлап чыгарган аны? Без сал йөртүче түгел ләбаса. Приказларын алмаска, яхшылап сөйләшергә кирәк иде.

— Сөйләшеп тә карадым, барыбер риза булырга туры килде... Анда урманчылык зур бәлагә тарыган. Кыш буе әзерләгән салларының Пөгерек елгада утырып калу куркынычы бар икән. Иделгә чыгара алмыйлар, су сай, ди.

— Калса соң. Без гаеплемени!.. Сал йөртә торган пароход җибәрсеннәр.

— Барырга булгач, барырга инде. Бүтән пароходларга су сай, бары без генә керә алабыз...

Капитан бүтән берни дә әйтмәде. Фуражкасын батырып киде дә кызыл почмактан чыгып китте. Ә штурман исә, Гәрәйне алгы палуба астына алып төшеп, алты кешелек кубрикта аңа буш карават һәм урын-җир күрсәтте:

— Менә монда безнең рулевойлар, матрослар тора, син дә шулар белән булырсың. Кайсы вахтага чыгасын мин үзем әйтермен,— диде.

Гәрәй кубрикта бер үзе генә калды. Ул әле рәтләп урнашырга да өлгермәгән иде, тышкы яктан пароход көпчәкләре шаулый башлады, аяк астында палуба чайкалып куйды. Гәрәй түгәрәк иллюминатордан тышка карады һәм тау битенә урнашкан җиләк-җимеш бакчалары, поселок урамнары, пристань складлары бер якка — артка таба агылуын күрде. Димәк, пароходның кузгалып китүе шушы иде. Ниһаять, әләкмичә исән-сау котылдым бугай, дип, җиңел сулап куйды ул.

## VI

«Бурлак» Наратлы пристанена кич кенә барып җитте.

Урманчылар поселогы Пөгерек елганың сул як ярына, сөзәк тау битенә урнашкан. Ул өч яктан урман белән каплап алынган. Олы

урамы түбән очы белән елгага килеп терәлгән турыда бер генә катлы кечерәк дебаркадер тора. Каршыдагы такта рәшәткә белән уратып алынган агачлар арасыннан — ул поселокның ял паркы иде булса кирәк,— күңелле музыка, шаярган-көлгән тавышлар ишетелә иде. Дебаркадердан бераз югарырак саллар рейды башлана: бөтен су өстен диярлек каплаган саллар рәт-рәт тезелеп, ерактагы борылыш артына кадәр сузылып киткән, аларның исәбе-хисабы юктыр шикелле. Дымсу-талгын һавада ылыс исе, чәер исе аңкый. Елганың уң ягында, кичке тынлыкка талган моңсу тугайлар өстендә, ак томан күтәрелеп килә иде.

Пристаньга житәрәк «Бурлак», поселок белән исәнләшкәндәй, сузып кына гудок кычкыртты. Аның көр тавышы йокымсыраган тугайлар, урманнар өстеннән яңгырап үтте. Шундук каршыдагы өянке башларына кунаклаган каргалар, куркып уянып, колакларны тондырырлык итеп кычкыра башладылар, яр буе бала-чага белән тулды.

«Бурлак»ны монда көтеп торганнар икән. Дебаркадер янына туктауга, пароходка зур таза гәүдәле, сары мыеклы, урта яшьләрдәге бер кеше килеп керде.

— Исәнмесез, дуслар, сау-сәламәт килеп життегезме?.. Иң элек танышыйк әле, рейд начальнигы Митрофанов булам мин,— диде ул, капитан белән кул биреп күрешеп.— Яшерен-батырын түгел, безнең бар ышаныч сездә. Әгәр дә бер ай эчендә бу салларны Иделгә чыгарып бетермәсәк, болар барысы да монда киләсе елга хәтле торып калачак...

— Нигә үз буксирыгыз белән тарттырмыйсыз? — диде капитан, пристаньнан чак кына түбәндәрәк ярга борыны белән терәлеп торган кечерәк кенә пароходка күрсәтеп.

— «Урманчы»ны әйтәсезме?.. Тарттырабыз, бер генә сәгать тә тик тормыйбыз. Әмма су бик кими. Ул үзе генә көзгә хәтле дә ташып бетерәчәк түгел.

Ул бик ашыктырса да, «Бурлак» командасы килү белән үк эшкә керешә алмады. Әйләнә-тирәдә күтәрелеп килгән куе томан юлга чыгарга мөмкинлек бирмәячәк. Аннары «Бурлак» командасы таныш булмаган сай сулы, гаять бормалы елгада сал тагып төнгә каршы беренче рейска барыбер чыга алмас иде.

— Алайса сезнең кешеләр без алып килгән якорь һәм лотларны, чылбырларны бушата торсыннар,— диде капитан, үзара киңәшкәннән соң.— Безнең егетләр бераз ял итеп алсын. Әнә яр буенда парк ачык бугай, вахтадан буш булган кешеләргә йөреп керергә мөмкин. Салны иртәгә яктыргач буксирга алырбыз... Ләкин кисәтеп куям, егетләр, әйбәт кенә йөрегез, бер көнге кебек, артыгыздан жалоба килерлек булмасын.

Командага шул житә калды. Вахтадан буш булган кешеләр, шундук өс-башларын алыштырып, поселокка ашыктылар. Гәрәй башта пароходта калырга уйлаган иде, әмма рулевой Шәүкәт аңа күп сөйләнергә бирмәде:

— Безгә яр буена чыгу гел эләкми, жае туры килгәндә, әйдә, бераз жилләнеп керик,— дип, ирексезләп алып чыкты.

Пароходта шапшак кына киенеп йөргән матросларны, кочегарларны, майлаучыларны хәзер танырлык та түгел иде: барысы да киң балаклы кара чалбар, кайтарма зәңгәр якалы, ачык изүле ак күлмәк кигән. Йөзләре дә ничектер ачылып киткән.

Пристань каршындагы яр өстендә «Урман шавы» дигән кафе бар. Пароходтан төшкәч, бер төркем бурлакчылар, папирос, шырпы алырга дип, шунда кереп киттеләр. Повар Зәйнәп белән Гәрәй, эчкә кермичә, аларны тышта көтеп торырга булдылар һәм, икәү генә калгач, бер-берсенә сынаучан карашып алдылар.

Киң ак халат киеп йөргәнгәме, Гәрәйгә Зәйнәп пароходта гәүдәгә юанрак һәм елак чырайлырак булып күренгән иде. Хәзер ул ак күлмәк-

тан ничектер жыйнакланып калган. Калку күкрәге өстендә комсомол значогы җемелди. Күз карашымы, тешләрен елтыратып елмаюымы шунда, Нәсимәне хәтерләтә иде.

— Кичә Кызыл ярда бу Халит белән тәмам харап булдык, ояты ни тора,— диде ул.— Безнең Халит шул инде ул, кешечә генә йөри белми. Әтәч кебек сугышырга гына тора.

Бераздан кафедан бурлакчылар килеп чыктылар. Алар анда бер уңайдан азрак төшереп тә алганнар булса кирәк, йөзләре кызара төшкән, тавышлары көр. Ә Халитны танырлык та түгел. Күкрәген киергән, авызында папирос, фуражкасын кыңгыр салган иде. Зәйнәп янына килеп туктагач та, ул иптәшләренә борылып күз кысып куйды һәм бик хәйран калган кыяфәт белән:

— Әмма өлгер дә соң безнең Зәйнәп, чуртаннан һич ким түгел,— диде.— Яңа егет килеп урнашырга да өлгермәгән, ул аны сихерләргә дә керешкән. Кешесе адәм рәтле булса, бер хәер иде, ичмасам, тапкан бит кемгә кызыгырга...

Зәйнәп аның болай сөйләшүенә күнегеп беткән булса кирәк, аз гына да каушамады һәм ачуланып та тормады. Нәкъ үзе кебек итеп:

— Ярар, ярар, телеңә салынма,— диде.— Бу тикле дә сыек булырсың икән. Башкалардан әллә ни сизелми дә, ә син шундый гәүдәң белән бөтенләй җебеп төшкәнсең, ни сөйләгәнеңне дә уйламыйсың...

— Зыян юк ла, күп уйласаң, тиз картаерсың диләр ич.

— Ә син күп булмаса да, бераз уйла. Югыйсә кичәге кебек, тагын сайга утыруың бар.

Барысы да шаулашып көлеп алдылар. Халит үзе колагына да элмәде. Тартып бетергән папиросын ташлап, икенчесен кабызды да:

— И, куйсана, көйсез кайнана булма әле,— диде.— Әйдә, тизрәк паркка барып җитик, юкса соңга калабыз, ябылуы мөмкин.

Урман кебек куе парк халык белән тулы. Капкадан кергәч тә үзәк аллеядан ук, якты итеп яктыртылган мәйдан уртасында, бөдрә чәчле, чандыр гына гәүдәле бер егет тырышып-тырышып баянда уйный, аның тирәсендә парлашып яшьләр бөтерелә, әмма биючеләрнең күпчелеге кызлар икәнлеге күренеп тора иде. Халит моны мәйданга килеп керүгә абайлап алды һәм күтәренке тавыш белән:

— Менә кайда җәннәт! — дип, телен шартлатып куйды. Хатын-кызлар да шундук игътибар иттеләр һәм, баянчы яңа көй уйный башлауга, әле берсе, әле икенчесе килеп, үзләре матросларны биергә чакырырга тотындылар. Халит башта Зәйнәп белән биемәкче булган иде, әмма кыз ничектер эләкмәде.

— И соңга калдың ич, без монда бергә биергә сүз куешкан идек. Син гафу ит инде,— дип җавап бирде һәм бераз аптырап калган Гәрәйне биергә үзе алып чыкты.

Халит телдән берни дә әйтмәде, кашларын җимереп карап калды. Ә Гәрәй, бии башлауга, тагын Нәсимәне хәтерләп авыр сулап куйды.

Моннан соң инде ул үзен ничектер авыраеп калгандай хис итте, теләр-теләмәс кенә биеде. Аның кинәт кәефе китүен тиздән Зәйнәп тә сизде һәм, рәшәткә читенә килеп туктагач:

— Җитте, бүтән биемибез,— диде.— Егетләр, теләсәләр, биесеннәр. Әйдә, без пароходка кайта торыйк.

Паркта биек наратлар арасында кичке салкын сизелми, әле һаман җылы иде. Капкадан чыккач, Гәрәй кинәт чирап куйды. Ачык яр буенда һава салкыная төшкән, үләннәргә чык кунган һәм бөтен дөньяны караңгы бушлык йоткан шикелле. Шулай да пароход тормышы, кешеләр турында Зәйнәпнең дусларча сөйләгәнен тыңлап бару, әледәнәле беләге белән кагылып киткәнен тою аңа ничектер рәхәт иде.

Караңгыда ниндидер чокыр аша үткәндә, Зәйнәп, абынып егылмас

өчен, Гәрәйнең беләгенә тотынды һәм шуннан соң инде яр өстенә чыккач та һаман шулай култыклашып бара бирде.

— Син безнең матросларга гаҗәпләнмә,— диде ул.— Нишләмәк кирәк, алар шундый бераз адашкан халык, кыскасы, штрафниклар инде.

— Ничек инде, ни өчен?

— Дөнья булгач, төрлесе була. Купчелеге ниндидер гөнаһ өчен яхшы пароходлардан куып чыгарылган халык. Арада башка җиргә эләгә алмаучылар, булдыксызлар да бардыр.

Зәйнәп барысыннан да хәбәрдар, һәркемнең ни өчен «Бурлак»ка эләккәнен яхшы белә икән. Көтмәгәндә Гәрәй аннан:

— Син үзең ничек эләктең соң? — дип сорады.— Гафу ит, болай гына, үзең башлагач кына соравым. Әгәр әйтергә ярамаса, кирәкми, әйтеп торма.

— Миңа нәрсә, миңа барыбер...— Бераз уйланып торганнан соң, Зәйнәп узалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды: — Хәер, анысын миннән башка җиткерерләр әле, безнең пароходта сер саклап тормыйлар...

## VII

Гәрәй әле генә башын мендәргә төрткән шикелле иде, ни арада яктырып та өлгергән соң! Ул кемнеңдер төрткәләвенә сискәнеп уянып китте һәм бер мәл аңына килә алмыйча ятты. Күзен ачып караса — каршында Халит басып тора.

— Күрегез әле бу йокы чүлмәген, әбисенә кунакка килгәнмени!..— диде ул, брезент бияләйле кулы белән биленә таянып.— Тегендә бөтен команда тирләп-пешеп салны буксирга тагып йөри, ә бу аксөяк монда йокы симертеп ята... Тор әйдә, тизрәк кыймылда, синең өчен анда буксирны мин ташымам бит.

Аның өстендә кояштан уңып беткән җиңсез майка, башында иске соры беретка, биленә җиз якорьлы киң кара каеш салган. Кичәге типтерүнең нәтиҗәсе булса кирәк, күз төпләре шешенке, чырае чытык иде. Ул өстәлдәге чәйнектән бер стакан чәй агызып эчте дә, тагын да яманрак җикеренә-җикеренә, кубрик ишеген ачык калдырып чыгып китте.

Гәрәйне вакытында дәшәргә онытканнар яки берәрсе юри уятмаган булса кирәк, югыйсә бөтен команда авралга катнашкан вакытта кубрикта йоклап калмас иде. Ул тиз генә киенеп палубага чыкканда, кояш инде шактый югары күтәрелгән, пароход сал янына килеп туктаган иде. Беренче штурман белән рейд начальнигы салның аргы башында бүрәнә бәйләмнәрен исәпләп, аркылы-буйлы тарттырылган корыч арканнарның ныклыгын тикшереп йөриләр иде.

Бөтен халык эшләгәндә түбәндә йоклап калуы өчен Гәрәйгә уңайсыз булып китте, бу минутта һәммә кеше аңар шелтә белән карыйлар кебек тоелды. Әмма телдән аны-моны әйтүче булмады. Мостикка менеп баскан капитан җиз рупорын алып кешеләрне әледән-әле ашыктыра, һәркем үз эше белән мәшгуль; Халит арткы палубадан корыч буксирны салга күчереп маташа иде.

— Нәрсә хәйран калып торасың, бар салга төш,— диде ул.— Мин буксирны моннан биреп торам, ә син салдан торып тарттыр.

Гәрәй салга сикереп төште дә буксирны икенче башыннан тарта башлады. Бик тиз тирләп чыкты. Беләктән юан корыч буксир гаять авыр һәм, җитмәсә, энә очыдай тырпаеп торган тимер чыбык очлары кулны чәнчә иде. Аның хәлен капитан да сизеп алды һәм башка матросларга да салга төшәргә кушты. Бишәүләп тотынгач, эш җиңеләя төште, буксирны салга бик тиз эләктерделәр.

Ул арада якында гына гудок тавышы ишетелеп, урманнар, әрәмәләр өстеннән яңгырап үтте. Борылып карасалар, пристаньнан түбәндәрәк «Урманчы» пароходы сал тартып юлга чыгып бара икән.

— Озак кыймылдыйбыз, егетләр, озак,— дип, капитан ашыктырырга тотынды.— Әнә кешеләр китеп баралар инде, ә без әле һаман рейдта казынабыз. Кәлимуллин, Мортазин, тизрәк булыгыз, тизрәк!

Пароходта капитанны яратмыйлар бугай, Гәрәйгә шулай тоелды. Әйткән сүзен тыңлыйлар, кушканны эшлиләр, әмма берсе дә жылы сүз белән телгә алмый. Ә Халит аны үзе юкта: «Аяклы устав»,— дип кенә йөртә һәм жае чыккан саен аның исеменә усал сүз әйтми калмый:

— Бу хәтле дә формалист, бу хәтле дә үз сүзле булыр икән. Юк кына нәрсә өчен шелтәли-шелтәли тәмам теңкәгә тиеп, саруны кайнатып бетерә бит.

Хәер, Гәрәй дә аны күрүгә ничектер каушап кала, мөмкин кадәр аның күзенә чалынмаска тырыша. Түгәрәк күзләре белән сынаучан караган минутларда капитан аны үтә күрәдер һәм хәтта күңелендәгеләр ятканын да сизәдер кебек иде.

Салны кабул итеп барысы да палубага күтәрелгәч, капитан кулына рупор алды да:

— Хәзер кузгалабыз, һәркем үз урнында булсын! — диде һәм, гудок кычкыртып, салчыларга якорьны күтәрергә сигнал бирде.

Пароход агым уңаена борылып, түбәндә көпчәкләр әйләнә башлагач, корыч буксир тиздән скрипка кылы кебек зыңгылдап тартылды, һәм ярты елганы биләп алган кәрван акрын гына кузгалып китте. Яр буена жыелган урманчылар, сал бәйләүчеләр кәрванга хәерле юл теләп озатып калдылар.

«Бурлак» пароходының капитаны да, штурманнары да Пөгерек елгада эшләгән кешеләр түгел, монда фарватерны белмиләр иде. Аларга ярдәмгә урманчылар үзләреннән лоцман бирделәр. Наратлыдан Иделгә чыкканчы кырык километр чамасы арада шул кеше юл күрсәтеп барачак.

Саллар, төрле баржалар, баркаслар шыгрым тулган кысынкы рейдны артта калдырып, ачык фарватерга чыккач, «Бурлак» бар куәтенә эшли башлады, корыч буксир тагын да катырак тартылды. Пароход көпчәкләре кузгаткан үйнак дулкыннар бер-берсен ашыктырып артка тәгәриләр, як-якка жәелеп, ярларга кагалар: кичерәк кенә пароходның бөтен елганы уятып шундый зур салны тартып баруын күреп һәркем үзендә көч арткандай сизә, күңелендә горурлык хисе уяна иде.

Вахтадан буш кешеләр, аврал беткәч, кызыл почмакта иртәнге ашны ашадылар да ял итәргә таралдылар. Халит рубкага менеп штурвал көпчәге янына басты. Гәрәй палубаны себереп, юеш швабра белән сөртеп чыкты. Эш арасында авыр уйларга бирелергә вакыт юк иде. Бераз бушаганнан соң, арткы палубада ял итәргә утыргач, тагын Кызыл ярны, давыллы төндә яшен суккан наратны, куркудан телсез калган Нәсимәне, үзенең туган-үскән өеннән качып китүен хәтерләп авыр сулап куйды.

Шул чак камбуздан ике кулына ике чиләк тотып Зәйнәп килеп чыкты. Ак халат, калфак кигән, кызу плитә янында йөрүдән бит урталары алсуланган. Гәрәйне күргәч, ул кинәт туктап, чиләкләрен саклык белән генә палубага куйды да бер мәл сүзсез генә карап торды. Аннары иелеп учы белән чиләгеннән су алды да Гәрәйнең муенына чәчрәтте һәм, кемгәдер охшатып булса кирәк, үтә житди кыяфәт белән:

— Вахтада торганда йокларга рөхсәт ителми,— диде.

Көтмәгәндә су чәчрәтүдән Гәрәй, чынлап та кинәт йокыдан уянгандай, сикереп торды һәм Зәйнәпнең шаяртканын күреп, чак кына уңайсызланып:

— Юк, йокламыйм ла. Болай ничектер онытылып утыруым гына,— диде.

— Барыбер ярамый, вахтада онытылып утырырга да рөхсәт ителми... Белегез аны, моннан соң күрәсе булмыйм.

Зәйнәп шулай дип әйтте дә үз сүзеннән үзе көлеп җибәрде һәм ике чиләген ике кулына алып койрык якка китеп барды.

Аның артыннан Гәрәй дә елмаеп калды һәм: «Менә бәхетле кеше, һәрвакыт шат күңелле. Моңаюның нәрсә икәнен дә белми»,— дип уйлап куйды.

## VIII

Йөгерек елга үзе болай зур булмаса да, исеме җисеменә бик туры килгән: куе урманнар, әрәмәләр арасыннан алкынып ага. Монда Иделдәге төсле фонарьле маяклар юк. Шулай да сай урыннарын күрсәтә торган калкавыч билгеләр куелган, көндезләрен шуларга карап фарватер юнәлешен чамалап барырга мөмкин. Шунын өстенә юл күрсәтүче махсус лоцман да булгач, «Бурлак» хәвеф-хәтәрсез әйбәт кенә бара бирде.

Елга туры гына аккан участокларда салчыларга да, пароход командасына да эш юк диярлек. Кызыл почмак куләгәсендә үз тирәсенә җыелган бер төркем матросларга Халит башыннан кичкәннәрне сөйләп бара иде.

— И дуслар, бәхетең бер булмаса булмый икән,— диде ул, авыр көрсенеп.— Менә мин хәзер, үзегез күрәсез, гади бер рулевой булып эшлим. Кайчандыр минем дә пароходта беренче кеше булган чакларым бар иде. Менә бит язмыш нишләтә кешене, ул чакларны хәзер инде сагынып сөйләргә генә калды.

Гәрәй аны ихтыярсыз кызганып куйды һәм аны-моны уйлап тормастан:

— Ничек инде беренче кеше, башыңа бәла төштемени? — дип сорады.

— Ул вакытта минем пассажир пароходында матрос булып эшли башлаган җаем генә иде,— диде Халит, һаман шулай кызганычлы кыяфәт белән.— Күп тә үтмәде, авылдан минем хәлне белергә эти килде. Үз күзе белән күрәсе килгән: ничек яши, ничек эшли, янәсе. Ни әйтсәң дә, әти бит! Үземә аны-моны әйтмәсә дә, сизеп торам, гел күзәтә бу мине. Мин якорьлы фуражканы киеп чыккан чакларда, нәни малай кебек, сокланып туя алмый бу. Кыскасы, бу бездә Ульяновскидан әйләнеп кайтканчы ике тәүлек торды, бик канәгать булып китте. Өйгә кайткач, мине мактап бетерә алмый, безнең Халит — бөтен пароходта беренче кеше дип сөйли икән. Авылдашлардан кайсыдыр ышанмаган булса кирәк: каян беренче кеше, моны ничек аңларга? дип сораган. Әти бер дә каушап калмаган: «Нигә беренче кеше булмасын, Халит бәйләмәсә, пароход туктамый, әгәр ул чалканы ычкындырмаса, кузгалып та китә алмый. Шулай булгач, сиңа нәрсә, атаң башымыни? Мин боларны барысын да үз күзем белән күреп кайттым ләбаса»,— дип җавап биргән.

Түбәннән шундук:

— Есть самый полный! — дип җавап кайтардылар, пароход тагын да куәтлерәк эшли башлады, корыч буксир тагын да катырак зыңгылдап тартылды.

Сал хәзер елга аша салынган йөзмә күпергә охшап калды. Пароходтан караганда аның аргы башындагы кешеләр бәләкәй генә булып күренәләр; алар анда ничектер кабаланалар, берсен-берсе ашыктыралар иде. Сал атауның югарыгы очы белән тигезләнде, кешеләр, кинәт сихерләгәндәй, баскан җирләрендә хәрәкәтсез калдылар. Менә арадан

берсе кинәт фуражкасын салып һавада болгый башлауга, бинокльдән карап барган капитан:

— Үттек... Хәвеф-хәтәрсез үттек,— дип белдерде һәм тирләп чыккан маңгаен кулъяулыгы белән сөртеп алды.

Кешеләр, өсләреннән авыр йөк төшкәндәй, жиңел сулап куйдылар. Капитан салчыларга лотларны күтәрергә боерды, түбәндә машина нормаль режимда эшләүгә күчте; туры фарватерга чыккач, «Бурлак» тагын салмак кына чайкалып юлын дәвам итте.

Кич житкәч, кояш таулар артына төшеп баеган чакта «Бурлак» Кызыл яр турыннан үтте. Моңа пароходта беркем дә игътибар итмәде, бары тик Гәрәйнең генә йөрәге ешрак тибә башлады, сулышы кысылгандай булды. Һәм ул, кеше күзенә чалынмас өчен, кубрикка төште дә туган-үскән поселогына иллюминатордан йотлыгып карый башлады. Әнә пристаньнан ундарак тау өстендә аларның өе, әнә Нәсимә белән очраша торган бакча арты. Их, белсәң иде, ничек икән аның хәлләре...

Гәрәй Кызыл яр күздән югалганчы карап барды. Менә Каравыл тавы текә кыялары белән өскә жимерелердәй шомлы булып тора. Төн урталарында пароход Усай ярлары буеннан — дачалар, пионер лагерьлары урнашкан турыга житте. Гәрәйләрнең, Нәсимәләрнең дә участоклары шунда. Хәзер анда барысы да йоклыйлар булса кирәк, утлар күренми диярлек.

Иртәгесен көндез «Бурлак» чирек тәүлеккә срогыннан элек Тарлык рейдына төшеп житте һәм, туктау белән, алып килгән салын агач эшкәртү заводына тапшыра башлады.

Шул чак һич көтмәгәндә юлда салның бер бәйләме югалганлыгы беленде. Завод вәкиле, бөтен йөзен жирән сакал-мыек баскан тәбәнәк кенә карт, шуны күрсәтмичә кабул итү актына кул куюдан баш тартты. Башта моңа ышанмадылар, ялгыш санагансыңдыр, без киткәч иркенләп тикшерерсең дип ачуланып та, үгетләп тә карадылар. Берничек тә күндерә алмагач, салны тагын бер кабат бергәләшеп тикшерделәр, әмма картның сүзе дөрес чыкты; илле кубометр чамасындагы бер бәйләм чыннан да юк булган иде. Салчылар бригадиры бу хакта: юлда сүтелеп таралган булса кирәк, ләкин төнлә карангыда без күрмәгәнбез, дип кенә әйтә алды.

Моннан соң инде капитан завод вәкиле белән бахәсләшеп тормады. Актка кул куйганнан соң, бу хәл турында Кызыл ярга милиция бүлегенә телефоннан хәбәр итте дә юлга кузгалырга команда бирде.

## IX

Йөксез генә барган чакта «Бурлак» пассажир пароходларыннан һич тә ким йөрми, авыр баржалар белән барган буксирларны әледәнәле куып житеп, гудок бирә дә жиңел генә узып китә. Команда членнарына да эш юк диярлек. Көндезге кызудан соң кичке салкынча һавада жиңеләеп калган кешеләр кызыл почмакта телевизордан футбол карыйлар. Футболны Халит кебек яратучы һәм дулкынланып караучы юктыр. Ул уйнаучыларның һәр хәрәкәтенә үзенчә аңлатма биреп, мактап яки ачуланып бара. Менә пароход борылган бер арада экран тоныграк күрсәтә башлауга, ул ишек янында утырган Гәрәйгә түземсезлек белән:

— Син ник анда йоклап утырасың? — дип кычкырды.— Начар күрсәтә бит. Бар, тизрәк өскә мен дә антеннаны турыла.

Гәрәй мостикка менеп антеннаны пароход курсы авышкан якка акрын гына бора башлады һәм түбәннән Халит: «Булды, булды, бик әйбәт. Тизрәк төш, иң кызык жирен күрми каласың,— дип хәбәр иткәч кенә туктады.

Әмма Гәрәй футбол белән моңарчы да әллә ни кызыксынмый, үзе дә уйнамый, башкалар уйнаганны да мавыгып карамый иде. Менә хәзер дә ул кызыл почмакка кермәде, бераз ялгыз калырга теләп арткы палубага чыкты. Анар кинәт бик ямансу, күңелсез булып китте...

Шул чак кемдер сиздермичә арттан килеп күтмәгәндә аның күзен каплады һәм ничектер ясалма, юри үзгәртелгән тавыш белән:

— Бел кем икәнен, юкса җибәрмим,— диде.

Гәрәй аны сизелер-сизелмәс кенә камыр исе килгән йомшак кулыннан шундук танып алса да, белмәмешкә сабышты.

— Кем булыр икән бу? — дип, аптыраган кыяфәт белән ирексездән елмайган булды.— Менә гаҗәп, кулы бераз таныш та кебек, әмма тавышы белән һич тә күргән-белгән кешегә охшамаган...

Зәйнәп аның таныганын көтеп тормастан, кинәт үзе кулын ычкындырды.

— Чү, ни булды сиңа, елыйсың түгелме син?! — диде ул бик гаҗәпләнеп һәм Гәрәйнең күзләренә төбәп карады.— Кара инде, күзләрен яшь баскан, чынлап елап утыра.

Ул тагын нидер әйтмәкче, кызганып сораштырмакчы, юатмакчы кебек иде. Әмма телдән берни дә әйтмәде. Иңбашы белән сүзсез генә Гәрәйгә елышып утырды да үзе авыр сулап куйды.

— Тормыш ник болай икән, башыма сыйдыра алмыйм,— диде ул, бер мәл уйга талып утырганнан соң.— Күңел һаман каядыр җилкенә, нидер көтә... Кыш көннәрендә тизрәк яз җиткәнне, Иделгә чыгар көннәрне түземсезлек белән көтәсең. Пароходта бераз йөргәч тә, тагын күңел кайта, кешеләрдән туеп бетәсең, тормыш бер төрлегә әйләнә, тагын шәһәргә, халык арасына кайтасы килә. Анда нәрсәдер көтәдер, чакырадыр шикелле... Хәер, бер тапкыр мин үз бәхетемне тапкандай булган идем, тәмам җаным-күңелем сөйгән идем, аны бер генә көн күрмәсәм дә, авыруга сабыша идем. Аның кебек чибәр, үткен, булдыклы егет бөтен дөньяда юктыр шикелле иде. Бактың исә, иң гадәти эчкече һәм бозык кеше, һәр юбка артыннан сөйрәлеп йөрүче булып чыкты... Мин моны өйләнешеп бергә тора башлагач белеп алдым... Шуннан бирле бөтен тормышыннан гарык булдым. Беләсеңме, дөньяда бер генә минут та яшисе килмәгән минутларым була минем.

Зәйнәп бу сүзләрне, үзалдына уйлаган сыман, ашыкмыйча, ишетелер-ишетелмәс кенә сөйли башлаган иде. Сөйли торгач, ул тәмам хәлсезләнде, күзләреннән яшь бәреп чыкты, ничектер ярдәмсез, кызганыч булып калды. Гәрәй аны, үз хәсрәтеннән айнып, эчке бер аяну белән тыңлады. Колакларына ышанмагандай, зур ачылган күзләре белән бик гаҗәпләнеп Зәйнәпкә берничә мәртәбә карап алды. Кызганудан нишләргә белмичә:

— Алай ярамый, нык булырга кирәк. Бер бирешсәң, хәсрәт тиз сыга ул,— дип, Зәйнәпне калтыранган иңбашыннан сыйпап-сыйпап юатырга тотынды һәм кинәт эчтән генә уйлап куйды: «Ә мин үзем ничек соң?.. Миңа да нык торырга, ирләр булырга кирәк бит!»

Һәм шул фикер ничектер аның хәлен җиңеләйткәндәй итте. Телдән Зәйнәпне юату белән бергә аның үз күңелендәге өметсезлек каядыр чигенә башлады, үз-үзенә ышаныч, ихтыяр көче өстәлгәндәй булды. Тиздән Зәйнәп тә тынычланды һәм күз яше аша елмаеп куйды. Аннары ул әйләнә-тирәгә тиз генә каранып алды да:

— Әйдә мин сиңа бер китап күрсәтим әле,— дип, Гәрәйне үз каютасына алып керде.

Зәйнәп өске палубада койрык якка караган кечерәк кенә каютада бер үзе тора. Моңарчы Гәрәйнең монда аяк басканы юк иде әле. Килеп керү белән ул бөтен каютаны сокланып күздән кичерде. Ишектән кергәч тә уң якта — ак мендәрләре күпертеп матур итеп җыелган карават. Турдә тәрәзә буендагы кечерәк кенә өстәл өстендәге сулы вазага бер

бәйләм кыр чәчәге утыртылган. Каршыдагы стенада китап тулы киштә. Гәрәй аларны кызыксынып карый башлауга:

— Болар барысы да шигырь китаплары икән ич. Син шигырь генә яратасыңмыни? — дип гаҗәпләнде.

— Әйе, шигырь яратам. Бик яраткан шигырьләремне аерым дәфтәргә күчереп җыя барам мин.— Зәйнәп иллюминаторның калын пәрдәсен төшерде, ишекне эчтән бикләп куйды да киштәдән китап кебек калын дәфтәр алып Гәрәй янына килеп утырды.— Менә алар, минем яраткан шигырьләрем, җырларым, һәммәсе дә менә шушы дәфтәрдә... Беркөн шушы дәфтәрне карап утырганда, бер үзгәрешне күреп бик гаҗәпкә калдым мин. Элегрәк, яшь кыз чагында, мин гел канатлы, күңелне җилкендерә торган шигырьләр генә укый идем. Ә соңгы вакытта, үзем дә сизмәстән, ямансу, сагышлы шигырьләр белән мавыга башлаганмын...

Сөйләшеп утыра торгач, Зәйнәп дәфтәрен ачып кыз вакытта яраткан шигырьләрен укырга тотынды һәм тагын җанланып, бөтен йөзе яктырып китте. Дөресрәге, дәфтәренә ара-тирә карап кына ала. Шигырьләрне ул күңелдән белә һәм җырлагандай башын чайкап ала, күзләрен бераз сузып укый иде. Аны мавыгып тыңлый торгач, Гәрәй дә, онытылып, әллә кайларга киткәндәй булды, кайчандыр Нәсимә белән бергә йөргән бәхетле көннәрне тагын хәтерләп ихтыярсыз елмаеп куйды. Зәйнәп аны үзенчә аңлады булса кирәк:

— Ничек? Шәп әйтелгәнме!.. Чын мәхәббәт менә нинди була ул, дускаем,— дип көлемсерәп, дәфтәрен ябып өстәлгә куйды.

Гәрәй, кинәт йокыдан уятылган кешедәй, уйларыннан көч-хәл белән арынып, чак кына сискәнеп куйды һәм чыгып китәргә теләп урыныннан кузгалды. Шундук Зәйнәп тә аның каршына килеп басты һәм кулларыннан алып сүзсез генә бер мәл төбәп карап торганнан соң:

— Гәрәй, ник син бүтәннәр кебек түгел! Шундый егетләр дә була микәнни? — дип сорады.— Минем хакта берәр гайбәт ишеттеңме әллә?..

— Юк, Зәйнәп, аннан түгел.— Гәрәй нәни баланы иркәләгәндәй, аның иңбашыннан сыйпап алды.— Минем бернидә ишеткәнем юк. Вакыт соң инде, вахтага чыкканчы бераз ял итеп алырга кирәк. Син дә ят, тыныч йокы сиңа.

Гәрәй чыгып китәргә өлгермәде, тышкы яктан ишетелер-ишетелмәс кенә тук-тук-тук итеп өч тапкыр ишеккә шакып алдылар. Зәйнәп җавап бирмәгәч, тагын шакыдылар. Бераз торганнан соң:

— Мин бу, Зәйнәбем, ач әле тиз генә,— дип дәштеләр.

Гәрәй аның беренче штурман Галләм Галиев икәнен танып алды һәм, нишләргә белмичә, кинәт коелып төште. Ә Зәйнәп йокы аралаш әйткәндәй:

— Галләм абый, кәефем бик начар, авырып торган чагым,— дип җавап бирде һәм бераздан, тышкы якта Галиевнең аяк тавышы ерагаеп юк булгач, нәфрәтле офтану белән өстәп куйды:— Тәмам бәла булды бит, һич котылыр хәл юк... Хәер, кем белгән аның алай икәнен, башта ул бик кеше җанлы, бик җылы күңелле күренгән иде шул.

Гәрәй ирексездән:

— Ничек инде котылыр хәл юк, ул сиңа кем була соң? — дип сорады.

— Кем булсын... Мин бит аңар кияүгә чыккан идем. Сиңа әйтмәделәрмени?.. Аның кармагына эләккәнемне сизми дә калдым мин... Эш таба алмый интегеп йөргән чагым иде. Ул мине «Бурлак»ка кок итеп алып башымны әйләндерде... Ул гел шулай итә: берәрсе бәлагә тарыса, ярдәм иткән булып, үз кубызына биетә башлый.

Гәрәй, кубрикка төшкәч, караңгыга төбәлеп озак кына уйланып ятты. Таң беленгәндә генә борчулы авыр йокыга талды.

## X

Наратлы рейдында сал тагып нәүбәттәге рейска кузгалыр алдыннан пароходка утыз яшьләр чамасында бер ир кеше килде. Палубага сикереп менү белән, аны-моны сорашып тормастан, туп-туры капитан каютасына кереп китте. Ул соры кепка, шактый уңган яшькелт гимнастерка кигән, беләгенә кара плащ салган иде. Бер сүз белән әйткәндә, аның төсе-кыяфәте бу тирәдә адым саен диярлек очрый торган урманчыга охшаган иде. Команда членнарыннан аңар игътибар итеп караучы да булмады. Бары тик Гәрәй генә аны күрү белән таныды. Таныды һәм коты чыгып куркып калды.

Бу кеше — Кызыл ярда теге фаҗигале төндә Гәрәйне чак кына кулга алмый калган милиция лейтенанты Абдуллин иде. Куркудан бераз арынуга, Гәрәй тиз генә кубрикка төшеп китте һәм, лейтенант пароходтан төшми торып, өске палубада күренмәскә булды.

Ниһаять, рейдта эш тәмамланды бугай, өстә гудок кычкыртып, салчыларга якорьларны күтәрергә сигнал бирделәр. Менә кәрван акрын гына кузгалып та китте. Гәрәй иллюминатордан бик игътибар белән күзәтеп торса да, милиционерның пароходтан төшкәнен күрмәде. Шулай да ул үз-үзен юатырга, аның төшеп киткәнен, бәлки, мин сизми калганмындыр дип, тынычланырга тырышты. Бераздан ул өске палубага күтәрелде, күзгә бик чалынмас өчен, капитан каютасын читтән генә күзәтә башлады. Байтак вакыт караштырып та, шикләнерлек берни дә күренмәгәч, күңеле тәмам урнына утырды, юкка шүрләп калганы өчен ул хәтта үз-үзеннән көлеп куйды.

Көн буе кояш аяусыз кыздырган, эсседән бөтен команда тәмам гаҗиз булган иде. Бигрәк тә беренче штурманның эте Пират бик әлсерәгән, күләгәдә көч-хәл белән сулап ята иде. Кич белән Кызыл ярга житәрәк күк йөзендә соры болытлар күренде һәм, кешеләргә җиңеллек биреп, җилсез, күк күкрәүсез җылы яңгыр явып үтте. Гәрәй арткы палубага чыкты. Пароход тагын аның туып үскән поселогы яныннан узып бара иде. Ул бик нык дулкынланып, Кызыл ярның тау буйларына карап торды. Елга буйлап поселокка таба йөзеп китәсе килде. Шул мәлне ул пароходта көтелмәгән хәвеф, ыгы-зыгы башлануын тойды. Барысы да су өстенә карыйлар иде. Гәрәй кичке эңгердә буксирга тагылган сал янына куләгә яктан ямеренеп кенә берничә көймә килеп туктаганын күрде. Бу хәлне мостикта торучылар да күрделәр бугай, анда капитанның кемгәдер:

— Менә биноклядән карагыз,— дип әйткәне ишетелде.— Икәү көймәдән салга сикерделәр. Бәйләмне ычкындырмакчы булалар... Ычкындырдылар бит. Нәрсә карыйбыз, сал тарала! Кешеләргә әйтегез, көймәгә утырсыннар. Кузгалырга вакыт!

Гәрәй борт кырыена тотынып көймәгә сикереп төшкәндә, Халит белән штурман Галиев шунда иде. Алгы якта түземсезлек белән колакларын шәмрәйтеп Пират тора һәм тагын кемдер берәү бар иде. Галиев үзе койрыкта; Гәрәй белән Халитка ишкәккә утырырга кушты да кулындагы койрык — ишкәк белән көймәне читкә этәреп җибәрде. Иллюминатордан төшкән ут яктысында Гәрәй теге кешенең бүген иртән Наратлыда пароходка утырган лейтенант Абдуллин икәнен танып алды һәм кулындагы ишкәген чак кына суга төшереп җибәрмәде. Аннары йөзе белән аңар күренмәс өчен, ул якка борылып карамаска булды, карангыда, бәлкем, танымас та әле дип, үзен-үзе тынычландырырга тырышты.

«Бурлак» үз юлы белән бара бирде, көймәдәгеләр бүрәнә урлаучыларны куа киттеләр.

Пароход яныннан кузгалып киткәч тә, штурман Галиев ишкәкчеләр-

не ашыктыра башлаган иде. Әмма лейтенант Абдуллинның аланы бүтәнчәрәк икән:

— Юк, юк, хәзергә әле ашыгырга кирәк түгел, — диде ул.— Безне күрсәләр, алар бүрәнәләрен ташлап качачаклар. Без, күренмичә артларыннан барып, аларны яр буена туктаган җирләрендә эләктерербез.

Теге көймәләр барысы да моторлы икән. Бераз читкәрәк киткәч тә, сакланып та тормастан, бөтен елганы шаулатып моторларын эшләтә башладылар һәм өерләре белән уң як ярдагы тауларга таба юнәлделәр. Читтән караганда алар дингездә кораб талаганнан соң качып китеп баручы урта гасыр пиратларын хәтерләтәләр иде.

Бу хәлгә ачуы кабарган штурман Галиев каты кычкырып сүгенә, сал урлаучыларны куркытырга теләп булса кирәк, бөтен су өстен яңгыратып ачы тавыш белән сызгырып та җибәргәли иде.

— Кирәк түгел, шаулый күрмәгез,— дип, лейтенант Абдуллин аңар туктарга кушты.— Шулай ярыймыни!?. Әйтәм ич, без эзләреннән куып килгәнне сизеп алсалар, алар шундук бүрәнәләрен ташлап качачаклар. Зинһар, бүтән шаулый күрмәгез.

Көймәләр байтак юл алып, күздән югалган бер арада лейтенант Абдуллин ишкәкчеләргә җәһәтрәк ишәргә, тегеләр күргәнче таулар ягына чыгып калырга команда бирде. Таулар күләгәсенә посып шулай каты ишә-ишә борылыш артыннан чыкканда, «пиратлар» флотилиясе, су агымын файдаланырга теләп булса кирәк, әле һаман елга уртасыннан бара иде. Дачалар турысына житәрәк алар унга борылдылар һәм бер-бер артлы биек яр күләгәсенә кереп тагын күздән югалдылар. Бераздан бурлаклылар кисәктән генә өсләренә килеп төшкәндә, алар инде ярга килеп туктаганнар һәм, караңгыда бер-берсен ашыктырып, бүрәнәләрен судан өстерәп чыгарып маташалар иде.

Көтмәгәндә өсләренә чит кешеләр килеп төшкәч, караклар башта бик куркып калганнар иде. Галиевнең эте кулдан ычкынырга атлыгып ыргылдый башлагач, арадан карынкы тавышлы берсе танып алды:

— Фу, Галләм, син икәнсең әле, тәмам котны алдың,— дип җинел сулап куйды.— Аз гына сабыр ит, хәзер хуҗа хатын белән исәпләшкәч тә, сөйләшербез... Ә болары кемнәр, синең егетләрме?..

Штурман Галиев ни дә булса әйтергә өлгергәнче, лейтенант кесә фонарен яктыртып җибәрде, ачы тавыш белән команда бирде:

— Руки вверх! Кузгаласы булмагыз!

Караклар баскан җирдә катып калдылар. Карынкы тавышлысы — башлык булса кирәк,— кинәт читкә ыргылып, караңгыда күздән югалды. Гәрәй шундук аның артыннан ташланды, аяк тавышыннан чамалап, абына-сөртенә куа китте. Тиздән ярдәмгә Пират белән штурман Галиев тә килеп җиттеләр. Пират, хуҗасының кулыннан ычкынуга, качкынны куып җитте бугай, төн эченнән:

— Каравыл, талап үтерә, коткарыгыз...— дип кычкырган тавыш ишетелде.

Штурман Галиев аны ярсыган Пираттан көч-хәл белән аралап алды да:

— Ычкын, милиционер тырнагына эләккәнче үкчәңне күтәр,— диде.— Без сине куып житә алмадык, күрмәдек. Шулаймы, энекәш?..

Гәрәй соң дәрәҗәдә аптырап:

— Галләм абый...— дип каршы сүз әйтергә авызын гына ачкан иде, штурман Галиев аны ярты сүздән өзде:

— Кем икәнеңне онытма.

— Юк, болай ярамый... юк... мин моңа ирек куймыйм! — диде Гәрәй үҗәт бер кирелек белән.— Ә син нәрсә көтеп торасың, әйдә, кузгал! — дип ул каракның аркасына китереп төртте. Штурман Галиев теш арасыннан сүгенеп куйды, Гәрәйне милициягә бирү белән янады, алай да булмагач, тәмле тел белән ялвара башлады:

— Кеше бит, ялгышкан. Кызганырга кирәк.

Гәрәй дәшмәде, каракны якасыннан эләктереп торуын белде. Ул арада Халит та йөгереп килеп житте. Штурман Галиев бүтән үгетләп маташмады, карак та каршылык күрсәтмәде. Алар килеп житкәндә, су буена инде дачниклар да жыелып өлгергән, лейтенант Абдуллин сал талаучыларны такта коймa янына жыеп саклап тора; алардан читтәрәк бер хатын-кыз да бар иде. Гәрәй бик гажәпләнгән хәлдә:

— Бу хатын да көймәгә утырып сал таларга чыкканмыни? — дип кызыксынды.

Нигәдер бик ачуы чыккан лейтенант Абдуллин:

— Юк, анысы урлаганны жыючы, арзанга гына дача салырга уйлаган...Менә бу юлбасарлар бүрәнәләрне аңар сатып маташалар иде,— дип теге хатынның йөзен яктыртты һәм, үз күзләренә ышанмагандай, шаккатып әйтеп куйды: — Чу, Гөлсем ханым, сез түгелме бу?!.

## XI

Бу вакыйгадан соң юлда бүрәнә югалтулар бүтән кабатланмады. Бүрәнә урлаучылар белән штурман Галиевнең дә бәйләнештә булганлыгы беленде. «Бурлак»ның Кызыл яр турыннан кайчан үтәсен аларга телефоннан алдан хәбәр итеп торган икән. Тикшерү барышында бу хәл ачылгач, ул да жавапка тартылды.

Бер ай эчендә Иөгерек елгада су саегып, пароход йөри алмаслык хәлгә житкәндә саллар инде Иделгә чыгарылып беткән, урманчыларның кыш буе әзерләгән бүрәнәләре киләсе елга хәтле утырып калудан коткарылган иде. Шуның өчен рейд начальнигы «Бурлак»ны соңгы рейска озатканда урманчылар исеменнән командага рәхмәт белдерде, һәркайсын берәр айлык эш хакы белән бүләкләде.

Команда шат. Гәрәйнең дә күңеле күтәренке иде. Көндез вахтага чыккач, капитан Александр Терентьевич аны рубкага чакырып алды да бизгәк белән авырып Наратлы больницасында калган Халит урынына кочрыкчы булып эшли торырга кушты. Гәрәйнең моңарчы да берничә мәртәбә рульдә торганы бар иде. Хәзер дә ул бик теләп басты. Рульне борган саен пароходның көндәм авышуын күрү аның көчен арттыргандай итә, дөньяда елгачы булудан да кызыклы эш юктыр шикелле аңар.

Шулай матур хыялларга чумып бик әйбәт кенә барган чакта Александр Терентьевич бик гадәти нәрсә турында сөйләгәндәй:

— Гәрәй, мин кичә Кызыл яр милиция бүлегеннән хат алдым, теге чакта безнең пароходта килгән лейтенант Абдуллин язган аны,— диде һәм, бер мәлгә сүзеннән туктап, трубкасына ут ала башлады.

Бу көтелмәгән хәбәрдән Гәрәйнең күз аллары караңгыланып китте. Кай арада гына күрде икән, бер дә танымаган кебек иде бит, дип тәмам аптырап калды, шул арада әллә ниләр уйлап бетерде. Ә капитан китель кесәсеннән зәңгәр конвертлы хат алып, абына-төртелә укый башлады:

— «Безнең поселокта нахакка гаепләнгән һәм, куркудан булса кирәк, качып китеп хәбәрсез югалган Гәрәй Кәлимуллин дигән егетне сезнең пароходта очратып бик гажәпләнгән идем. Ул чакны ара тар булды, жаен туры китереп мин аның үзе белән сөйләшә алмадым. Ә без артык гаугалы бер хатын сүзенә ышанып, ул егетнең тормышын чак кына имгәтеп ташламадык. Әмма Гәрәйнең гаепсезлеге бик тиз ачыкланды. Дус кызы да савыкты, үзенең хәбәрсез югалуы гына безне бик борчый иде. Кургәнемчә, ул әйбәт коллективка эләккән, юлдан язып йөрми. Гәрчә, бу турыда мин сезгә әйткән идем инде. Тик шунысы бар: ул егет югары уку йортына керергә хыялланa икән. Әйтегез үзенә, курыкып качып йөрмәсен, әгәр тели икән, соңга калганчы, укырга керергә

документларын тапшырсын. Өенә кайтып этисен-энисен дә тынычландырсын иде...»

Александр Терентьевич, фуражкасын салып, тирләгән маңгаен, такыр башын кулъяулыгы белән сөртеп алды. Ә Гәрәй теге вакыттан соң беренче тапкыр җинел сулап куйды, күз алдында кинәт дөнья яктырып, иркенәеп киткәндәй булды.

— Александр Терентьевич, сез белә идегезмени, ничек берни дә әйтми йөрдегез? — диде ул, бик гаҗәпләнеп.— Ә мин белмәгәйләре дип, һаман шүрләп йөри идем.

— И, энекәем, бар ишеткән-белгәнне урынлы-урынсыз сөйләп йөреп булмый. Ул чакны әле үзенне дә белеп бетермәгән идем. Менә вакыт житкәч әйттем бит.— Александр Терентьевич чаларган мыек астыннан сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды.— Син укырга җыенып бик әйбәт итәсең, пароходта кеше житмәсә дә, без сине тоткарламабыз, әлбәттә. Әгәр сер булмаса, бәлкем, әйтерсең: син укырга кая керергә телисең соң?..

Фарватер читендәге кызыл маяк турыннан үтәрәк, Гәрәй рульне, капитан күрсәткәнчә, бераз уңгарак салды һәм «Бурлак» як-якка йөгерек дулкыннар кагып турыга бара бирде. Шул чак Гәрәй тиздән бу пароход белән саубуллашырга туры киләчәген аңлап алды, һәм аңар ничектер ямансу булып китте... Кыска гына вакыт эчендә бу иске буксир пароход аның күңеленә якын булып әверелгән бит. Кешеләре дә якын. Наратлыда авырып калган Халит та, йомшак күңелле Зәйнәп тә, тыштан кырыс күренсә дә, аталарча кайгыртучан менә бу карт капитан Александр Терентьевич та — барысы да якын, үз кешеләр бит.

— Я, ник әйтмисең? Кайда укырга, кем булырга телисең? — диде капитан, аның уйларын бүлеп.

— Дөресен генә әйткәндә, Александр Терентьевич, сез әйткән бу хәбәрдән уйларымның очын югалттым әле мин. Бер яктан чиксез шатмын. Шул ук вакытта күңелсез дә миңа, «Бурлак»тан, сездән аерыласым килми...

— Анысы өчен рәхмәт. Шулай да укырга кая барырга телисең син? Шул хакта уйлаганың бармы?

— Кайчандыр мин җырларга ярата идем, җырчы булырга хыяллана идем. Ләкин күрәм, ул коры хыял гына булган, аңлап, белеп сайланган юл булмаган. Әгәр көчемнән килсә, хәзер мин Елга институтына керергә; елгачы булырга телим. Бу инде коры хыял гына түгел, пароходны, елганы якыннан белеп туган теләк.

...Шул ук көнне кичкырын, кәрван Кызыл яр буеннан үткәндә, Гәрәйне көймә белән пристаньга төшереп калдырдылар. Үзе инде яр буенда булса да, аның күңеле әле һаман пароходта иде. «Бурлак» борылыш артына кереп күздән югалганга кадәр саубуллашу гудоклары биреп барды.

Тау өстенә менеп туган-үскән поселогына килеп кергәч, ул шатлыгыннан чак кына кычкырып җибәрмәде. Кечкенәдән күреп-белеп үскән һәр йорт, һәр тыкрык аны сагынып көткәндер, сөенеп каршылыйдыр шикелле. Менә үз урамнары. Үз өйләренә житәрәк, Нәсимәләр турыннан үткәндә, урамда коедан су алып маташкан бер кызны күреп йөрәге кинәт ешрак тибә башлады, күзләре томаланды. Чынлап шулмы бу, әллә миңа гына шул булып күренәме, дип уйлап куйды ул.

Менә кыз да ул килгән якка борылды һәм, әле һаман ышанмагандай, зур ачылган күзләре белән бер мәл шаккатып карап торды. Танып алгач, сулы чиләге кулыннан төшеп, бер читкә тәгәрәп китте, үзе соңга калудан курыккан кебек ашыгып Гәрәйгә каршы йөгерде.

● ● ● ●

*1933 елда Башкорт АССРның Кушнаренко районы Тартыш авылында туганмын. Уфага килеп һөнәрчелек мәктәбен тәмамлагач, токарь булып эшли башладым. Беренче шигырьләрем дә шул чорда туды.*

*1952—55 елларда Совет Армиясе сафында хезмәт иттем. Соңыннан журналистлыкка бирелдем. Балалар өчен дә шигырьләр язам. «Серле дөнья», «Язгы нурлар», «Йолдызлар» дигән китапларым басылып чыкты.*

*Хәзерге вакытта Уфада «Пионер» журналында әдәби хезмәткәр булып эшлим.*

## Әфган Гыйззәтов

# ХАТ ТАШУЧЫ



1

Авыр еллар. Авыл бушап калган.
Тынып калган гармун моңнары.
Авыл буйлап хат ташучы килә,
Сумка тулы кайгы нибары.
Күпме әна тагы һуштан язар,
Уку белән «үлде» хәбәрен.
Күпме сабый тагы ятим калыр,
Яшь коелыр елга кадәрле.
Күн сумкада шундый хатлар да бар,
«Мин исәнмен» дигән хат алар.
Язылганнар ләкин яу кырыннан,
Язылганнар соңгы кат алар...
Кемнәр генә йөгереп чыкмас дисең,
Хат ташучы картның юлына.
Гүя арысландай егетләрнең
Язмышлары аның кулында.
Авыл буйлап хат ташучы килә,
Тешен кыскан, сабыр, аз сүзле.
Күпме кешеләрнең кайгы йөген
Ул күтәреп алган бер үзе.

2

Еллар аша ул күтәреп чыкты
Күпме кешеләрнең газабын.
Ә бер көнне сумкасына салып,
Алып кайтты бөек яз аен.
Һәр йорт саен ишек, тәрәз шакып,
Кешеләргә аны таратты.

— Сугыш беткән! — шушы олы хәбәр
Күңелләргә якты нур атты.
Ләкин хат ташучы күралмады
Иртәгесен җиңү көненең.
Карт йөрәген тотып, кинәт кенә
Ауган имән сыман бөгелде.
...Аның исемен ташка язар өчен,
Юк, сайламас идем алтын мин.
Аңа һәйкәл итеп куяр идем
Өч почмаклы солдат хатын мин.

●

Күпме мин белгәннәр җирдән киткән,
Яшәр кебек идек гел бергә.
Очрашканда өлгергәнбез бары
Бер-беребезгә сәлам бирергә.
Кунак итеп бик еш чакырдыгыз,
Әллә нигә вакыт тапмадым.
Сизми калдым
 кавышыр капкаларны
Вакыт мәңгелеккә япканын.
Күчтәнәчләр салдым сиракн кенә,
Әллә нигә хатлар язмадым.
Эх, яшәүне кабат башлап булса,
Күрә белер идек азагын.
Үткәннәрнең кадере арта бара,
Еракланкан саен аралар.
Юл кыскарган саен юлдаш кими,
Югалтулар өсти яралар.
Сары томан булып сагыш килә,
Әрнү алып килә күңелгә.
Һәм өйрәтә
 туган-үскән җирнең,
Кешеләрнең кадерен белергә.

## ЧИЯ БАКЧАСЫНДА

Кызарып пешкән чияне
Өзәргә кыймый торам.
Кызлар ирене кебек ул,
Учыма җыймый торам.
Нигә соң кыймый торам?

Бакчачы кыз миңа карый:
— Авыз итмисең нишләп?
— Кайсын? — дигәч, кызара ул,
Алсу иренен тешләп.
Оялулары — и шәп!

Яшел чия пешәр иде,
Кагылса кыз битенә.
Баш очымда бер кош сайрый,
Үп, әйтмәм, ди, бер кемгә! —
Канат җилпеп үтенә.

Хәниф Хәйруллин

# ХУҖИДА ҮСКӘН БАТЫР

Очерк

## Беренче адымнар



Авылның МТСка якын булуыннандыр. Хуҗида әүвәл-әүвәлдән механизаторлар күп иде. Күрше-тирә колхозларда тракторчы, комбайнчы кем — барысы Хуҗидан. Иртә яздан кара көзгә кадәр алар басуда, я кышын ремонтта.

Очраганда тешләре генә ялтыраучы бу абыйларга карап, Дамир — ундүрт яшьлек үсмер малай — кызыгып кала. Бик еш кына: «Тау хәтле шул комбайн ничек кешегә буйсына, ничек үзе ура да, суга да, җилгәрә дә? Бу Таһаветдин абзыйлардагы баш миндә булса, ә?» дип уйлана торган иде. Шундый уйлар аны сигезенче класстан соң Чаллыга, авыл хуҗалыгын механикалаштыру училищесына алып килде. Аның бу эшен әнисе дә хуплады. Яшерен-батырын түгел, елларның авыр вакыты иде әле ул чакта. Тамакның туйганчы икмәк, өснең юньле кием күрмәгән чагы. Ә алар бер әнисе эшләгәнгә өч кеше — абыйсы Мияссәр, әбисе, ул — Дамир — кашык күтәрәләр. МТСта эшләүчеләр исә җиргә нык басып яши: икмәген дә, акчасын да мул ала. Дамир анда тагылма комбайннарның төзелешен, эшләү принципларын җентекләп өйрәнде.

1952 елның язында кулына «Комбайнчы» дигән таныклык алып, Теләче Тамак МТСына кайтты. Аны тәҗрибәле комбайнчы Таһаветдин Шәмсетдиновка ярдәмче комбайнчы итеп беркеттеләр. «Тере» комбайн янына кулына ачкычлар тотып килеп баскан Дамир башта шик-шөбһәгә төште: «Менә сиңа, мә! Училищеда «С-6», «Коммунар» өйрәндек. Ә бу «С-4».

Әмма Таһаветдин яшь егетнең техникага хиреслеген тиз абайлады. Аңа «С-4»нең серләрен төшендерде. Урып-җыюга керешкәндә, аларның кыр корабы инде сәгать механизмы кебек эшли иде.

Менә беренче адымнар, беренче сынаулар. «Урожай» колхозы (хәзерге «Игенче») кырлары. Штурвалда — Таһаветдин. Аның артында Дамир. Ул күзләрен иптәшенең кулыннан алмый, аның һәр хәрәкәтен күзәтә, нәрсә эшләвен күңеленә сеңдерә. Дамирның бирелеп карап торуын сизгәндәй, берничә тапкыр әйләнгәч тә, Таһаветдин артка таба борылды һәм:

— Помкапитан, курыкма, бас әле штурвал артына! — дип кычкырды.

Штурвал, штурвал, штурвал аның кулында! Мең дә бер төрле нурлар белән нәкышләнеп, диңгездәй дулкынланып утырган арыш басуы өстеннән күз яуларын алырлык тизлек белән агучы рәшә тасмасы, күгелҗемләнеп торган урман буйлары, зәңгәр күктә уктай атылган тургайлар, күрәсезме?! Кеше беренче тапкыр кулына кыр корабы штурвалын тота! Олы, мактаулы тормыш юлына беренче тапкыр аяк баса!

Ә куллар нык һәм ышанычлы күренә. Әнә ич, изге, хәерле сәгатьтә дигән кебек, Таһаветдин абыйсының да күзләрендә шатлык, сөенеч нурлары балкый...

Икесе дә уңган булып чыкты алар. Кояш белән ярышып эшләделәр: аннан иртәрәк торырга, соң ятарга тырыштылар. Атналар буе икесе дә салам копнителендә генә йокы туйдырдылар. Һәр буш минутын комбайнын карауга багышлаган, шат күңелле, уенчак, һәркемгә ярдәм кулын сузарга әзер торучы Таһаветдин белән беренче сынауны үтү Дамир өчен бик тә файдалы булды. Күп нәрсәгә өйрәнде ул аннан.

Көзен «чебиләр саналды»: Таһаветдин Шәмсетдинов агрегаты 837 гектар мәйданны урып-җыйды һәм элеккеге Ворошилов районы буенча беренче урынны яулады! Таһаветдинның үзенә ничек булгандыр, әмма аның ярдәмчесе Дамир Әхметовка, 16 яшьлек егеткә, бу җиңү алга таба очу өчен канат куйды. Оч кына!..

## Тырышкан таш ярган

Урып-җыю тәгәлләнеп, МТС гадәти үз тормышы белән яши башлаган гына иде. Чаллы механизация училищесында укырга кеше кирәк икән, дигән сүз таралды. Дамирның тагын да укыйсы килә иде. Тик ул МТС директоры С. Петров янына керергә шикләнеп йөрде. Әмма соңыннан тәвәккәлләде. Директор сүзне кыска тотты:

— Син инде законлы комбайнчы, таныклыгың бар, укыганың җитәр. Бездә самоучкалар да бар бит. Гарәфи абыйларны әйтәм. Әнә шуларны таныклык алган комбайнчы итәргә кирәк безгә,— диде.

Бу сөйләшүдән соң озак үтмәде, директор ниндидер курска укырга китте, аның урынында баш агроном Г. Шәрафиев калды. Директор тәкъдиме буенча ул, укырга җибәрергә дип, Гарәфи аганы чакыртты, тик тегесе алай-болай боргалана, инде олыгайдым, семьядан башка яшәве авыр, булдырып булмас, дигән төрле сәбәпләр китерә башлый. Бу сөйләшүдән соң яшь агроном Дамирны чакыртып алды.

— Барасыңмы?

— Китәм!

...1953 елның октябрь аенда егет яңадан Чаллы авыл хуҗалыгын механикалаштыру училищесының ишекләрен ачып керде. Тырышып, бөтен күңелен биреп укыды Дамир. Менә 1954 елның 5 апреле. Бу көнне ул, барлык имтиханнарны бары тик «5»ләргә генә биреп, «Механик-комбайнчы» аттестаты алды. Ул яңадан Т. Таман МТСына кайтты. Аңа Таһаветдин комбайнын бирделәр. (Ә Таһаветдин үзе бу вакытта Чистай авыл хуҗалыгы техникумында укый иде.) Ремонт узел методы белән үткәрелсә дә, Дамир комбайнның һәр узелын, частен үзе яңадан карады, тикшерде, төзекләндерде.

Комбайнга мөстәкыйль утырган бу көннәре әле дә исендә Дамирның. Ул вакытта әле аеры уру дигән ысул юк иде. Барлык иген турыдан-туры урыла. Чык төшкән көннәрне иртән дә, кичен дә ургычның иярткүче валына юеш үлән урала, ургыч тыгыла, вал кыза, күп очракта сына. Шушы бәладән комбайннар яну очрагы да булмады түгел, булгалады.

«Нишләргә? Моннан ничек котылырга?»

Урам аша гына яшәүче күршесе Габдрәфыйкны да бу мәсьәлә борчый, ул да комбайнчы. Тырышкан таш ярган дигәндәй, бергәләшеп уйлаштыргач, әмәлен дә таптылар. Авыш транспортерның иярткүче валы белән ияртүче валы арасында фанердан ясалган тоткарлагыч куйдылар. Бу яхшы нәтиҗә бирде: валга үлән уралмый башлады. Икенче елны ул фанерны калайга алмаштырдылар.

Алга сикереп булса да, әйтеп үтик: конструкторлар да авыл рационализатор-механизаторларының бу ачышын озакламый законлаштырдылар. Күп тә үтмәде, «СК-3», «СК-4» комбайннары ургычына бу җайланма заводтан ук куеп чыгарыла башлады. ...Кыр корабы күперчегенә башлап баскан елында да Дамир сынатмады. Беренчелекне алмаса да, сезонны әйбәт күрсәткечләр белән, алдынгылар рәтендә тәмамлады: 587 гектар мәйданны урып-җыйды.

1955 ел да шулай киеренке хезмәт белән үтте. Бу елны Дамир гөрләтеп туй ясап, үзе кебек үк уңган кыз Хәния белән тормыш корып җибәрде.

## Ватан солдаты

1956 елның көзе аеруча явым-төшемле булды һәм урып-җыю озакка сузылды. Шундый көннәрнең берендә Дамирга повестка тоттырдылар. Ул, комбайн штурвалыннан төшкәч, ял да итә алмады, Совет Армиясе сафына китте.

— Әйбәт яшәгез, өч ел тиз үтәр, мена әйләнеп тә кайтырмын,— диде ул. Хәния, әнисе, әбисе белән саубуллашып. Аннары бишектә яткан бер айлык кызы, әле бердәнбере, кадерлесе Әлфияне алып сөйде.

...Механизатор булгангамы, әллә, кем әйтмешли, бәхете шуннан булгангамы, ул тагын тимердән аерылмады: танк частена эләкте, Приморье краенда хезмәт итте, бер ел механик-водительлеккә укыды.

Әмма, кайгы агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри, ди бит халык. Бер көн шулай, танк йөртергә өйрәнү занятиесеннән кайту белән, аңа телеграмма китереп тоттырдылар. Бер мәлгә күз аллары караңгыланып китте Дамирның. Телеграмма бланкасындагы хәрефләр сикереште... «Кызыбыз... үлде».

«Кайтып җитеп булмас, ерак, мин кайтканчы күмеп куярлар. Аннан, мин кайтып кына терелтеп булмый. Нишләргә соң?»

Башта әнә шундый чуалчык уйлар кайнады. Кайгысын взвод командирына — өлкән лейтенант Михаил Тюкинга сөйләгәч кенә җиңелрәк булып китте Дамирга. Кече күңелле Тюкин Дамирның кайгысын үзенекедәй кабул итте, аны ничек тә оныттырырга теләп, ярдәмчесен эш белән күмде. Үткән көннәр, искән җилләр әкренләп күңел ярасындагы җөйләрне төзәтә башлады.

Курсантларны өйрәтү белән тулы көннәр бер-бер артлы үтте. Кинәт взвод командиры авырып, операциягә керде. Аннары, терелгәч, ул хәрби Академиягә укырга китте. Дамир, хезмәт срогын тутырганчы, взвод командиры вазифасын башкарды.

Армия сафында ул үзлегеннән укып, беренче класс механик-водитель таныклыгы алды.

## Киеренке хезмәт еллары

Акрын гына яңгыр сибәли. Авыл урамы буйлап кулына чемодан тоткан сержант атлый. Аны шунда ук танып алдылар.

— Дамир абый, Дамир абый кайта!

Койма ышыгында уйнаучы бала-чага, әнә шулай дип кычкыра-кычкыра, Гәүһәр ападан сөенеч алырга йөгерде. Менә капкадан җилдә шактый каралган йөзле, чәчләрен бәс сарган әнисе, күзләреннән шатлык нуры бөркеп торган Хәния йөгереп чыктылар:

— Исән кайттыңмы, улым!

— Дамир!..

Хәния артык сүз әйтә алмады, иртән үлән яфраклары очыннан тамам-тамам дип торган чык тамчылары кебек, күзләрен яшь пәрдәсе каплады, теле көрмәләнде.

— Тәнене нидер чыкты... Больницадан алып кайтканда, салкын тиде... Мин, мин генә... гаепле!

Кавышу шатлыгын кинәт моңсулык күләгәсе каплады... Дамирның да тамак төбенә ниндидер төер утыргандай булды. Ул читкә карады һәм тирән итеп сулыш алды да:

— Ярар, Хәния, әнкәй, үлгән артыннан үлеп булмый. Үзегез ничек яшәдегез соң?

— Әйбәт, тик әбиең генә сукырайды.

— Шулаймы? Кызганыч!..

Өйгә керделәр. Койкада бөгәрләнеп утырган әбисе бик кызганыч тоелды Дамирга. Авыр сугыш елларында әнисе көнө-төне сарык фермасында эшләп йөргәндә, аны тәрбияләп үстергән әбисенең күзләре күрми!

«Докторларга күрсәтергә кирәк!» — дигән ныклы карарга килде Дамир. Ике-өч көн кунак булгач та ул, әбисен алып, Алабугага сәфәр чыкты. 86 яшьлек карчыкка врачлар операция ясарга авырсынсалар да, Дамир үзенекен итте. Операция уңышлы чыкты. 93 яшьлек Мәфтуха әби хәзер дә исән, күзләре дә күрә. Дамирның кечкенә кызы Лилия гел аның алдыннан төшми, әбием дип кенә тора, кечкенә куллары белән әбисенең җыерчыклар сырган битен сыйпый, иркәли.

...Армиядән кайтып, 10—15 көн үткәч, 1959 елның 9 ноябрендә, Дамир үзе эшләгән МТСка юнәлде. Бу вакытта МТСлар РТС итеп үзгәртеп корылган, техника колхозларга сатылган иде. РТС директоры — шул ук С. П. Петров. Дамирны ул җылы каршылады. Исән-имин кайтуы белән котлагач та слесарь-монтажчы эше тәкъдим итте. Кышны автомашина, комбайн моторлары ремонтлап үткәрде Дамир.

...1960 елның урак өсте якынлашып килә иде. Филиалга (ул вакытта Т. Тамак РТСы Сарман РТСының филиалы итеп калдырылган, элекке Ворошилов районы бетерелеп, аның бер өлеше Минзәләгә, күпчелек хуҗалыклар Сарман районына кушылган иде.) Сәмәкәйдән «Авангард» колхозы председателе елардай булып килгән. Еларлыгы да бар. Урып-җыюга санаулы көннәр калып бара, ә колхозның үз комбайнчылары җитми. МТС вакытында бу үзен сиздермәде. Килделәр дә эшләп киттеләр. Ә хәзер, техника үзеңдә булгач, үз кадрларың кирәк.

Филиал директоры Хәйдәр Сафин Хуҗи егетләрен чакыртты. Менә алар — Дамир, Габдрафыйк, Әсгать, Хәниянең абыйлары Мәҗит һәм Шәрифҗан — директор кабинетында. «Авангард» колхозы председателе Җаббаров сандугач булып сайрый, әллә ниләр вәгъдә итә, егетләргә «кармак» сала.

Сүзгә Сафин да кушыла.

— «Мәгариф» колхозында, гомумән, безнең зонада комбайнчылар җитә, күршеләргә ярдәм кулы сузыйк, егетләр! Алар ипие — безнең ипи, ил ипие бит...

— Бармый булмас, без риза, иптәш Сафин.

Хуҗи егетләренең бу сүзләреннән Җаббаровның түбәсе күккә тиде. Ул канатланып кайтып китте.

Хуҗи егетләре ул елны сәмәкәйлеләрнең бармак белән генә санарлык комбайнчыларына эшләп тә күрсәттеләр күрсәтүен. Дамир 497 гектар, Габдрафыйк — 495, Мәҗит 517 гектар мәйданның игеннәрен урып-җыйды. Ә Сәмәкәй комбайнчылары 200—300 гектардан арттыра алмадылар.

...1961 елгы урып-җыюда да Дамирга үз колхозында эшләргә туры килмәде. «Чулпан» колхозында яңа гына председатель булып эшли башлаган Хәмир Хәйретдинов, Дамирның күптәнге танышы, филиал дирекциясенә ярдәмгә комбайнчылар сорап мөрәҗәгать итте һәм үзе күптән белгән Дамир, Әсгать һәм Шәрифҗанны җибәрүләрен үтенде. Бу инде сабан туйлары үткән вакыт иде.

Комбайннарны ремонтлап бетереп булырмы? — Егетләрне әнә шул борчыды. РТС директоры Ә. Мөхетдинов тизрәк эшкә керешергә кушты. Менә алар колхоз паркында. Комбайннар шул чаклы беткән, Дамир үз «бәхетенә» эләккән комбайнны, агач терәүләр белән ныгыта-ныгыта, көч-хәл белән РТС ихатасына алып кайтты. Озак та үтмәде, тырыша торгач булды тагын, егетнең комбайны кырга чыгарга әзер иде инде. Һәм ул бу юлы да сынатмады. Иптәшләре дә Дамирдан калышмады. Алар урып-җыюның иң кызган көннәрендә сафка басып, 10 көндә 2 комбайнга 540 гектар теземнәрне җыеп суктырдылар.

Әмма читтә «рекорд» куеп йөрүче комбайнчылар «Мәгариф» колхозы җитәкчеләренең күңелен кытыклый башлады. Бригада җыелышында «үз комбайнчыларыбыз үзебездә эшләсен», дигән карар да кабул иттеләр. Дамирга да бу карар бик ошады. «Үз колхозыңда эшләү әйбәт тә, җаваплы да. Чөнки синең һәр минутың авылдашларың күз алдында үтә. Үзеңнән-үзең бөтен барлыгың белән тырышасың, йөзне кызартасы килми», дип уйлый иде ул үзе дә.

...Әнә шушы вакыйгадан соң 1968 елга кадәр Дамир кышын «Сельхозтехника»ның Теләче Тамак бүлекчәсендә слесарь-монтажчы булып эшләде, ә җәйләрен тагын кыр корабы штурвалы артына басты.

# Тырыш хезмәт дан китерә

— Артельдә беренче урынны яулаган өчен Дамир Әхметовны кышкы пальто белән бүләкләргә!

— Район комбайнчылары ярышында икенче урынны алган Дамир Әхметовка баян тапшырырга!

— Районыбыз чемпионы — «Мәгариф» колхозы комбайнчысы Дамир Әхметовка «ИЖ-Планета» мотоциклы бүләк итәргә!

Соңгы елларда һәр сезон Дамир өчен әнә шулай тәмамланды.

Әйе, тырышып, маңгай тирен түгеп эшләгән хезмәт җимешне мул бирә һәм ул дан китерә. Хөкүмәтебез Дамир Әхметовның фидакарь хезмәтен югары бәяләде. Аңа СССР Верховный Советы Президиумының 1966 ел 23 июнь Указы белән Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде.

* * *

Былтыр, сентябрь ае ахырларында, колхозларда инде тары, карабодай кебек соңгы культуралар уңышы да бураларга салынган, игенче инде бер кавым киң сулыш алган көннәрдә, Сарман урамында очраттым мин Дамирны. Әнә ул, гади кепкасын бераз кырынрак салып, хром итекләрен елтыратып, район авыл хуҗалыгы идарәсенә таба атлый. Ерактан ук елмаеп килә.

Укырга китеше икән. Казанга, авыл хуҗалыгы институты янындагы 6 айлык курсларга, колхоз-совхозларга кече командирлар әзерләү мәктәбенә. Әмма күңеле әле һаман шик-шөбһәдән арынып бетмәгән кебек.

— Булмас ул, малай, миннән андый кеше, командир дигәннәре, чыкмас. Эш кушарга өйрәнгәнмени мин?.. Аны эшлә, моны эшлә, дип кешегә ничек әйтәсең?.. Ярый ла барысы да үзе белеп эшли торган җиргә эләксәң. Укып бетергәч диюем... Эшне үзең, үз кулың белән эшләүдән дә рәхәте юк инде аның. Әллә ник шунда риза булып ташладым, укырга барырга, дим.— Дамир шулай дип, Сарман урамын әле нигә таптап йөрүен аңлатты да әйтеп куйды: — Икенче яктан, укымый да булмый, заманасы шуны сорый бит. Ике-өч елдан комбайнның да әллә ниндиләре чыгар әле...

Без аерылыштык. Ул кызу адымнар белән идарә капкасыннан кереп югалды.

Дамир узган ел да үзенең кыр корабы белән күпме «диңгезләр» кичмәде! Көзен җырлап торган күтәренке күңел, гаять зур һәм кыйммәтле байлык белән тыныч бухтага якорь салды ул. Юбилей елында Дамир, чын батырларча, алай гына түгел, пәһлеваннарча эшләп, бөтен районны гына да түгел, республиканы таңга калдырды. Ул 505 гектардан 9.939 центнер гәрәбәдәй бөртек җыеп алды!

Әнә шулай, кыр корабы белән шаулы да, данлы да муллык диңгезләрен кичкән саен, канатлары һаман ныгыды Дамирның.

Ә курслардан укып кайткач, «кече командир» таныклыгы белән генә чыгарсалар да, эшнең зурысын тапшырдылар аңа: Социалистик Хезмәт Герое Дамир Әхметов «Ленинчы» колхозында партия оешмасы секретаре итеп сайланды.

**Мөхәммәт Мәһдиев**

# СЕБЕР ТАТАРЛАРЫ ИҖАТЫ

*Казан дәүләт университеты Томск. Новосибирск өлкәләренә фәнни экспедиция оештырган иде. Экспедициядә мин Себер татарларының җырлары белән кызыксындым. Мине бигрәк тә җирле колоритка — Томь, Обь, Өян елгаларының исемнәренә бәйле җырлар кызыксындырды. Болардан тыш, хәзерге кайбер фольклорчылар атап йөрткәнчә, «сюжетлы җырлар» да таптым, ахрысы. Мәсәлән, Кызылкаш авылында 70 яшьлек Хаҗиәхмәт бабай миңа үзләре яшь вакытта ничек итеп кыз озатканнарын сөйләде һәм җырларын яздырды. «Городок» һәм «Бандит» — Томск татарларының иң яраткан көйләре. Боларны белмәгән кеше юк. «Городок» — рекрутлар җыры булып исәпләнә икән, «Бандит» көе — элекке каторжаннардан калган көй дип санала.*

*Акбалык һәм Порт-Умар авылы (Новосибирск өлкәсе) татарларының бөтен көнкүреше Өян, Обь суларына бәйле. Шуңа, ахрысы, аларның җырларында бу елгаларның исемнәре телгә еш алына. Себер татарларының җыр хәзинәсе бетмәс-төкәнмәс. Монда әле бары тик ике-өч авылда очраганнары гына күрсәтелә.*

## Городок көе

**«Городок» — Томск шәһәренең читендә элек хәрби лагерьлар урнашкан район. Ул тау буенда. Томь суы буендагы татар авылларына городок күренеп тора. Городок көе Томск татарларында мәҗлесләрне, җырлы уеннарны башлап җибәрү өчен уйнала (безнең яктагы «Алмагачлары» урынына). Шунысы характерлы, бу җырның көе Себернеке булса да, сүзләре, нигездә, безнең җырларныкы. Ул җырлар нинди юллар белән Себер татарларына барып җиткәннәр. Халык бары тик күңелдәгесен генә җырлый. Ә Томск тирәсендәге татарлар өчен Томск каласы, Томь елгасы иң кадерле һәм иң матур урыннар. Шуңа күрә безнең җырларыбыз үзләренең конструкцияләрен саклаган хәлдә җирле колорит йогынтысына дучар булганнар.**

Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде — каласыз.
Том каласы ерак түгел,
Озатырга барасыз.

Сау бул инде, Том каласы
Лагерь таулары белән.
Сез булмагач, мин нишләрмен
Дөнья маллары белән.

Атларны яхшы күрсәтә
Безнең Том дугалары.
Кая барсаң шунда кирәк
Атана[1] догалары.

Городокның тавы биек
Утырып чана шуарга.
Дуслар килгән җыр тыңларга,
Җырлап бирик шуларга.

Городокның тавы биек
Алма тәгәрәтергә.
Дусларымның хәтере калган,
Ничек бәхилләтергә.

[1] Атана — ата-ана.

## Бандит көе

**Турысын гына әйткәндә, бу көйнең исемен ишеткәч, бераз каушап калдым. Ничек инде ул — бандит көе! Бәхеткә каршы, җырның сүзләрендә куркынычлы андый берни дә очрамады. Ә менә көенә килсәң — гаҗәп. Бу көй аһәңгә шулкадәр бай, шулкадәр тирән моң — монда иксез-чиксез тайганың шаулавына Себернең киң сулы елгаларының салмак агымы кушыла. Бу җырны тыңлаганда, ирексездән, богауларын чыңлатып тайга юлларыннан сөргенгә куылган бабайларның аһ-зарын, йөрәк сыкрануын ишетәсең. Ләкин халык җыры буларак ул тирән оптимизм белән сугарылган һәм, әгәр шулай әйтергә яраса, бу җырны мин тантаналы-драматик җыр дип атар идем.**

Бандит көе, бандит көе,
Бандит көен яратам;
Бандит көйләренә җырлап
Хәсрәтемне таратам.

Бандит көе матур чыга
Җырлаганда хор белән,
Кара төнне яктыртасың
Йөзеңдәге нур белән.

Томскиның базарында
Алдым чия майлары,

Сезне уйлап үтә инде
Җәйнең күкеле айлары.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Фәхерислам;
Томь суларына төшәрмен,
Сез дуслардан аерылсам.

Безнең Томьның суы тәмле,
Төбе комлыга күрә,
Моңлы баланы кызганам,
Үзем моңлыга күрә.

## Кыз елату

**Кияүгә киткән кызны йортыннан озатасы көнне аларга егетләр-кызлар җыелалар. Гармун, скрипка уйныйлар. Кызлар бии.**

Егетләр хоры:

Ак шарф та бәйләдең,
Күк шарф та бәйләдең.
Әткәң-әнкәң кулларында
Актык җәйләр җәйләдең.

Кызлар хоры:

Самоварны тиз кайната
Яшь каенның күмере.
Атанада кыз баланың
Унсигез ел гомере.

Безнең урам киртләч-киртләч,
Киртләч бетәр яз җиткәч,
Ирләр кайта хезмәт иткәч,
Кызлар кайтмый бер киткәч.

Китәсе кыз җавап бирә:

Агач башы күк тиен,
Атып алуы кыен.
Ятка бару берни түгел,
Ятка яравы кыен.

**Шул җырдан соң барлык кызлар да сәкегә утырып елыйлар.**

Томск районы, Кызылкаш авылы. Хаҗиәхмәт Аблиннан язып алынды. 70 яшендә

## Томск татарларының җырлары

Томь сулары буйларында
Йөреп туялмам инде,
Синең нурлы йөзләреңне
Күреп туялмам инде.

Томь суына басма салдым,
Үзем чыгармын диеп,
Аерылганда елап калдым,
Ничек чыдармын диеп.

Томь суына төшә яздым,
Кул кисәге таш өчен.
Җырлый белмәсәм дә җырлыйм,
Сез дусларым хакы өчен.

Том каласы бик зур кала,
Табалмадым кантурын[1],
Син бит минем СССРда
Сайлап алган матурым.

Том каласы бик зур кала,
Әйләнеп чыгалмадым.
Синең нурлы йөзләреңне
Бер күреп туялмадым.

Томь сулары иңләп ага,
Каршы йөзәрлек түгел.
Синең нурлы йөзләреңне
Күрми түзәрлек түгел.

Томь сулары бигрәк тирән,
Карап күзләрем тала.
Аерылганда «сау бул, бәгырем»
Дигән сүзләрең кала.

Безнең Томьның суы салкын,
Әллә шаулап акканга,
Төнлә төшләремдә күрәм,
Әллә уйлап ятканга.

Томь суларын кичкән чакта
Сизәм суның салкынын,
Томь сулары бигрәк тәмле,
Баса йөрәк ялкынын.

Томск районы, Кызылкаш авылы яшьләреннән язылды



## Акбалык авылы татарларының җырлары

Акбалык — тайга эчендәге борынгы Себер авылы. Ләкин соңгы гасырда бу авыл янына Теләче, Саба, Арча якларыннан күчеп килгән кешеләр Казанка исемендә бер авыл төзегәннәр. Акбалык татарларына безнең җырларга охшаш җырлар шул Казанка аркылы кергән булырга тиеш. Югыйсә, йөз чакрымнар тирәсендә монда башка бер генә татар авылы да юк.

Минем чапкан покосымны
Дусларым үлчәтмәсен,
Су астында җан бирүне
Ходаем күрсәтмәсен.

Ике җирән, ике кашка
Басып киләләр ташка,
Ашый да алмыйм, эчә дә алмыйм
Сез туганнардан башка.

Әнә килә пароход,
Обь суларын таратып;
Ерак юлны якын итеп,
Килдем сезне яратып.

Борылып менгән, сызылып төшкән,
Безнең артта су юлы.
Исән килдеңме җаный дип,
Суырып үпте бу юлы.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Нәгыймә,
Кар йомарлап, карлар тотам
Әрнегән йөрәгемә.

## Умар авылы татарларының җырлары

Йорт-Умар — Обь елгасы ярына урнашкан Себер татарлары авылы. Телләре безнең Казан татарлары теленнән бик нык аерыла — алар үзара сөйләшкәндә без берни дә аңлый алмадык. Ләкин җырлаганда безнең яклардагыча җырлыйлар.

Казаннарга барам әле,
Обь сулары ачылса,
Уф йөрәгем димәм әле,
Янулары басылса.

Чәчләремне тарыйм әле,
Уфа кызлары кебек,
Айкала күңелем, чайкала,
Өян[2] бозлары кебек.

---

[1] Кантурын — конторасын.
[2] Өян — Обьның кушылдыгы.

Обь суларын карап торып,
Агып китәрдәй булам.
Агып китеп, барып җитеп,
Алып китәрдәй булам.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр дилбегә,
Ямьле Умар буйларында
Тавышым калсын билгегә.

Омскидан Томскига,
Томскидан Самарга,
Санаулы көн түгел иде,
Калды инде санарга.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр әрдәнә,
Ялынып ятлар сөяргә
Безнең башлар гарьләнә.

Байкал күле, Байкал күле,
Байкал күлә күбекле,
Күп эзләдем, табалмадым,
Дуслар, сезнең кебекне.

Байкал күле төпләреннән
Таптым ал кашлы йөзек,
Байкал күленә батсаң да,
Тартып алырмын йөзеп.

Байкал бит ул, байтак бит ул,
Ат белән әйләнсәң дә,
Кимсетмәгез, кимсенмәмен
Кемнәргә бәйләнсәм дә.

Өян буе, Өян буе,
Өян сулары тәмле,
Өян суын эчкән кызлар
Нәзкәй билле, ак тәнле.

Биек тауның башларында
Усман байның тураты,
Берегез алма, берегез чия,
Берегез винограты.

✦✦✦✦✦✦

**Әхмәт Рәшитов**

# ГАЗАПЛЫ ЭЗЛӘНҮЛӘР, СӨЕНЕЧЛЕ ТАБЫШЛАР

Илленче еллар уртасында татар совет поэзиясенә берсен икенчесе белән бутап булмаслык, үзенчәлекле биш исем өстәлде. Илдар Юзеев шигырьләре укучылар күңелен күтәренке хисләре, ашкынулы, ярсулы романтикасы белән җәлеп иттеләр. Рәшит Гәрәй гади генә тормыш детальләренең шагыйранәлеген, матурлыгын күрсәтте. Шәүкәт Галиев чынбарлыгыбызның эч пошыра торган кайбер күренешләрен халыкка хас киная, нәзакәтле юмор белән сугарып сурәтләде. Гамил Афзал үз сатирасын гротескка, карикатурага, буффонадага якынайтты. Хисам Камалов исә шигърияткә култык таягының асфальтка тигән тавышын яңгыратып, чордашларының күкрәк түрендә авыр катлам булып яткан уй-тойгыларын, моң-сагышларын җырлап килде. Бөек Ватан сугышыннан авыр яра белән кайткан солдат-шагыйрь үзенең урынын көчлеләр, керәштәгеләр сафыннан эзләде, шулар хисен байрак итеп күтәрде.

Тормыш белән атлыйм,
Юк, сөйрәлмимен
Мин кемнең дә булса аявын,
Ә көчсезләр өйдә еласыннар,
Оптимизм — минем байрагым.

Шагыйрьнең «Яңадан сафта» дип исемләнгән беренче җыентыгы белән танышкач, безнең каршыбызга тормышны бөтен рәхәте-газаплары белән яратучы, илен, аның азатлыгын үз җаныннан да якын, кадерле күрүче, киң омтылышлы лирик каһарман килеп баса. Бу тема Хисам Камалов иҗатында елдан-ел, җыентыктан-җыентыкка байый, камилләшә, киңрәк фикер нагрузкасы һәм яңа матур бизәкләр ала барды.

Шагыйрьнең биографиясен сөйләп торуның кирәге дә юктыр, мөгаен. Чөнки аның бөтен тормыш юлы шигырьләрендә чагылган.

Синең нефтең
Авылым өйләрендә
Якты нурлар булып кабынса,
Чиялә тау,
Синдә узган матур яшьлегемне
Әрәм киткән диеп сагынмам.

Бу — аның туган ягы, аңа тәүге илһам биргән тарафлар. Әлмәт районындагы Кама-Исмәгыйль авылы турындагы шигырьләреннән. Биредә ул 1926 елда туган һәм малай чагыннан ук җир сөргән, иген үстергән, атлар караган. «Сугыш уты башка үрелгәч», туган ил азатлыгын сакларга фронтка да шуннан киткән. Аннары... яралану, госпиталь, педагогия училищесы, ВУЗ, беренче кат каләм тибрәтү, хезмәт кырлары.

Аның 1950 елларда яшьләр газетасында басылып чыккан шигырьләре — Ватан бәйсезлеге өчен барган яуларда үзен аямаган гади совет гражданины исеменнән әйтелгән ачы хакыйкать иде. Хисам Камалов үзенең шәхси газапларын, интим хисләрен ил язмышы белән, яңа чор кешесенең уй-хисләре белән үреп бирде. Шуңа күрә, шагыйрьнең беренче карашка үтә интим күренгән шигырьләре дә иҗтимагый яңгыраш һәм укучылар күңелендә теләктәшлек таптылар. Аның иҗатына хисләр муллыгы, кичерешләрнең драматик киерен-

келеге, уйлануларының тирәнлеге хас иде. Ул башта:

Ни булса да Олег, Зояларның
Үлеменнән әзрәк көнләшәм.
Мин көнләшмәм фәкать шул чагында,
Яшәвемне әгәр һәр ягыннан
Алар үлеменә тиңләсәм, —

дип борчылып, хәтта бераз сыкрангалап уйласа, аннан соң:

Безнең язмыш шулай иде инде:
Көйдек, яндык —
Искә алмыйк авыр үткәнне.
Ул елларда сөйгән Россиям бит
Матур калды, —
Миңа инде шул да җиткән дим, —

кебек юллары белән үз-үзен юатты. Ахырда, яңадан сафка кайтуның шатлыклы һәм горур хисен тоеп, автор кешенең тормыштагы урыны, яшәү мәгънәсе турында төплерәк һәм тирәнрәк уйлана башлады:

Ачык сезгә минем эчем, тышым,
Беләсез һәм минем үткәнне.
Мин үтенәм: мине җәлләмичә
Авыр эшләр миңа йөкләүне!
Кыен еллар кичергәндә илем,
Бер кабым да аерым капмадым.
Россия каршысында минем
Йөзем-битем сөттән пакь калды.
Кешеләргә файдам тисен иде,
Сезнең белән телим атларга.
Коммунистлар,
Дуслар, уйлашыгыз,
Мин ярыйммы сезнең сафларга?

Хисам Камаловның башлангыч чор иҗатына мөрәҗәгать итсәк, без анда бер-берсенә охшамаган дистәләрчә үзенчәлекле образлар белән очрашырбыз: үз бәхетен кешеләр бәхетендә тапкан Рәйзә, әтисенең «Европа тузанына буялган» дизелендә басуларны иңләүче тракторчы, сугышта югалган иренә һаман да турылыклы булган олы җанлы тол хатын, «әкияттәге озын яллы ак ат шикелле өй кырыенда чабып йөрүче», буран арасыннан менә-менә әнисе килеп чыгар дип көтүче ятим малай һәм башкалар, һәм башкалар...

Шигъри сукмаклардан алга барганда, тайпылулар да, кирәгеннән артык мавыгулар да булмады түгел. Артык интим шәхси кичерешләр, әрнү мотивлары рамкаларында кайчак беркадәр чикләнгәнлек тә үзен сиздерде. Натурализм элементлары, акланмаган өзгәләнү өстенлек иткән «Дилбәр», мин-минлеккә, икейөзлелеккә каршы күсәк күтәреп тә, асылда аю хезмәте булып чыккан «Син кирәк миңа», чамадан тыш сентименталь «Бер сагыну турында» шигырьләре Хисам Камалов әсәрләрен яратырга өлгергән укучылар күңелендә урынлы борчылу тудырдылар.

Шагыйрь бу чирдән зур күләмле «Яну» поэмасында да тулысынча арынып җитә алмады шикелле. Әлбәттә, мин авторны, кайбер тәнкыйтьчеләр кебек, бар нәрсәгә кара күзлектән карарга тырышуда, ниндидер «ремаркизмда» гаепләргә җыенмыйм. Биредә бәла бары артык таркаулылыкта, төп идеянең әсәрнең буеннан буена кызыл җеп булып сузылмавында, драматизм белән героиканың нисбәте сакланмауда, үзәк вакыйгаларның, төп геройларның икенче пландагы вакыйгалар әсирлегенда буталып калуында.

Социалистик реализм тудырган уңай геройлар үзләренең шәҗәрәләрен бөек Горькийның Данкосыннан башлыйлар. Халык тормышы, аның азатлыгы, бәйсезлеге өчен үз-үзеңне аямыйча, кирәк булса, хәтта гомереңне корбан итәргә әзер торып көрәшүче каһарманнар темасына язылган әсәрләр совет әдәбиятының алтын фондына керде. Хисам Камаловның бу героик темага мөрәҗәгать итүе дә тикмәгә генә түгел. Аны көчле шәхесләр, көчле характерлар дулкынландыра һәм, әйткәнебезчә, бу омтылышны аның иҗатының башлангыч чорында язылган шигырьләрендә дә абайларга мөмкин иде. «Яну» поэмасының үзәгенә автор кан-үлемнәр, утбомбалар арасында да үзенең кешелек сыйфатларын: гадәт-холыкларын, хәр күңеллелеген югалтмаган Заһит образын куя.

Гөлт кабынды, ой-ой, Заһит бит!
Танк түгел, үзе кабынды!
Аңын җуеп, әллә сизмичә,
Яна-яна алга ябырылды...
Аңга килеп, өстен ташлады,
Күлмәкләре яна башлады,
Тәне яна, яна керфеге, —
Күзен — күзен пәрдә каплады...
...Сискәнде дә танк гәрена,
Үлем көче белән котырып,
Соң шешәне шуңа томырып,
Тагын ауды аңын гел җуеп...

Ләкин Хисамның Заһиты идел түгел. Аңа йомшаклыклар да: әрнү һәм хәтта курку кебек сыйфатлар да хас. Шуңа күрә батырлыкның тууы моментында Заһитның «Әни!» дип өзгәләнүе дә бик табигый яңгырый. Григорий Чухрайның «Солдат турында баллада»сын гына искә төшерик.

Яшь солдат Андрейның сытып үтерер өчен үзен əзəрлеклəп килүче танкны, бер кешесез сугыш кырында күпме куышып йөргəннəн соң, ниһаять, кул астына очраклы килеп элəккəн утчəчəр белəн юк итүе бик символик күренеш бит. Ир язмышы ил язмышы дигəндəй, биредə кешенең үз-үзен саклау инстинкты белəн Ватанны дошман хəшəрəтлəреннəн аралау арасында ниндидер параллель үткəрелə. Хисамның Заһиты эшлəгəн батырлыкны да шундый җирлектəн карап бəялəргə кирəк. Үз тиресе өчен генə калтырап торучы кайбер хыянəтче образлары фонында Заһит батырлыгы калкурак булып күренə. Тик əсəрдə эчне пошырганы — авторның куркак җаннар белəн артык мавыгып китүендə. Җылы урынга кереп оялаган Уйгон, хəлиткеч моментта шүрлəп калган Волков, «паникага төшеп качканда» үзебезнекелəр тарафыннан атылган Рамай, «окоп ташлап артка сыпырткан» Сафин белəн Петров — бер поэма өчен, төп геройны башкалардан аерып кую өчен күбрəк түгел микəн! Аннан Заһит белəн Зөллə арасындагы мəхəббəт линиясе дə поэма тукымасына ак җеп белəн тегелгəн шикелле тоела. Шунысын да əйтик, хəзер автор бу поэманы яңабаштан эшли һəм ул, əлбəттə, әлеге кимчелеклəрдəн азат булыр дип өметлəнергə кирəк.

1958—61 елларда язылган «Мəхəббəт хаты» поэмасы Хисам Камалов өчен чын чыннан иҗат казанышы, алга таба хəлиткеч адым булды. Шагыйрь анда замандашларыбызның күркəм сыйфатларын ышандыргыч ситуациялəр, хəтердə калырлык образлар аша сурəтлəде. Əсəрнең төп герое Зилə тышкы кыяфəте белəн генə түгел, уе-омтылышлəры белəн дə матур·

Кызлар бик күп,
Иң ачыгы — Зилə;
Матурлар күп, Зилə — иң матур.
Ул караса бер ягымлы итеп,
Каты ташны хəтта йомшартыр.
Кызлар көлəч,
Иң көлəче — Зилə,
Башын артка ташлап көлə дə,
Кыңгырау кебек тавышы яңгырап китə,
Əй, көлүнең томен белə лə!
Яңа йортлəр безнең Əлмəтлəрдə
Иң беренче
Ишетəлəр Зилə көлүен...

Шагыйрьнең Зилəсе беркадəр Такташ Апсуын искə төшерə. Шул ук көлəчлек, кəянлык, тормышны, яшəүне сөю. Лəкин биредə тəңгəллек билгесе куярга һич тə ярамый. Зилəнең үз характеры, үз омтылышлары бар һəм ул шул үзенчəлеклəре белəн калку итеп сурəтлəнə дə.

Менə алдынгы эшче, активистка, агитатор Зилə тормыш каршылыклары, күңеле кабул итмəслек күренешлəр белəн йөзгə-йөз очраша. Əсəр шомлы һəм киеренке яңгырый башлый. Яңалык белəн искелек, коммунистик идеаллар белəн тар, мещан психологиясе арасында кискен конфликт туа. Поэманың төп герое Зилəнең бар яшəеше коммунизм төзүчелəрнең əхлак нормаларына буйсындырылган. Кемнедер алдау, үз интереслaрын җəмгыять интересларыннан өстен кую, авырлыклар каршында каушап калу аңа бөтенлəй ят нəрсə. Аның бар максаты — үзе инанган, үзе ышанган хыялларны чынбарлыкка ашыру өчен көрəш. Һəм шул көрəштə ул җиңүче булып чыга.

Тормышка чыгып, гаилəдə туган күңелсезлеклəр вакытында төп авырлыклар аның җилкəсенə төшə. Лəкин Зилə аһ-ваһ итми, шыңшымый, сыкрамый. Чөнки ул көчле натура — үзенең хаклылыгына ышаныч аңа көч бирə.

Поэмадагы конфликт яхшылык белəн начарлыкның традицион бəрелешенə корылмаган. Инсаф — Зилəнең антиподы түгел. Ул — бетəшкəн кеше түгел, һəркемдə була торган кимчелеклəр порциясе аңа күбрəк кенə элəккəн. Гаилə өчен тырышам дигəн булып, җае чыкканда «чумара» ясаудан да баш тартмый ул, «җыелыш өчен сине алдыммыни!» дип Зилəгə дə ярсып куя, «көнчелек өянəге тотып», салгалап та кайта. Шуларның нəтиҗəсе буларак, Инсаф хөкем ителүчелəр урындыгына элəгə. Җəмəгатьчелекнең, коллективның ярдəме генə аны яңадан хезмəттəшлəре сафына кайтара. Иптəшлəренең гадел хөкеме аны түбəнгə тəгəрəүдəн коткарып кала.

Ул ничектер һəрчак кимсенүле,
Аралашмый, ачылып дусларга,
Барысын, барысын эченə җыеп йөри,
Читен була менə шуңарга,
Үзе честный, хыянəтсез эшче,
Бездəн нидер җитми, ахрысы,
Бикле булса күңел — чүп үстерə,
Төшми анда кеше яктысы...—

ди бригадиры аның турында. Ачы, кырыс хакыйкать тулы сүзлəр аны дулкынландырə, күңелен сафлагандай итə.

Яше ага,
Сүз әйтәлми Инсаф,
Зал тын калып, аңа багалар,
Ә яшьләре —
Бар әйтәсе килгән
Шул сүзләре булып агалар.

Әсәрнең бәхетле тәгәлләнүе дә бик табигый. Чөнки биредәге конфликт антогонистик каршылыкларга корылмаган. Шуңа күрә Инсафның төзәлүе, аның яңадан коммунизм төзүчеләр сафына кушылуы укучыны шөбһәләндерми, зарури нәтиҗә буларак кабул ителә.

Хисам Камалов тормышны һәрвакыт җентекләп өйрәнә, хезмәт кешеләре белән тыгыз бәйләнештә яши һәм, күргәннәрен, кичергәннәрен йөрәк призмасы аша үткәреп, дулкынландыргыч әсәрләр иҗат итә. «Мәхәббәт хаты» поэмасы да шул илһамның, шул кичерешләрнең гүзәл җимеше булды.

Шагыйрь производство темасына әледән-әле мөрәҗәгать итеп тора. Югарыда билгеләп үтелгән әсәргә аваздаш буларак туган «Зәй буенда» һәм «Әлмәт эскизлары» да гади хезмәт кешеләренең бөеклеген җырлый. Хисам Камалов геройлары һәрвакыт алгы планда. Производство картиналары исә аларның характерларын тулырак ачу, хисләрен, уй-кичерешләрен җанлы тормышка, конкрет обстановкага бәйләп бирү өчен материаль җирлек ролен генә үтиләр. Мотор авазлары, девон гүләве, тимер-томыр шавы кешеләрнең кызыклы язмышларын күләгәли алмый. «Зәй буенда» поэмасында һәм «Әлмәт эскизлары»нда шагыйрь замандашларыбызның истә калырлык образларын тудырды: эштә янып-көеп йөрүче тынгысыз йөрәкле, саф күңелле Зөбәй; бар фәлсәфәсе:

«Москвич»ка җыя башлыйк, Зөбәй?!
Келәм, сервиз — булыр көзен дә.
Сиңа кирәк бостон костюм,
Кием —
Дәрәҗә ул кеше күзендә!..—

кебек сүзләрдә ачык чагылган Динә; ихтыярсыз һәм пошмас помбур Галим; түрәлек җене кагылган Гафаров; мәхәббәтендә алданган Лира; моңсу язмышлы сызымчы кыз Сөмбел; җирдә һәрнәрсә өчен үзен җаваплы санаган Харис; завхоз Зиннур һәм башкалар әнә шундыйлардан. Автор үз йөрәгенә якын Әлмәт якларын аерым бер җылылык белән, уңышлы тотып алынган детальләр, оригиналь охшатулар, поэтик бизәкләр ярдәмендә сурәтли. 60 еллар башында аның иҗатындагы күтәрелеш шагыйрьнең тормыш материалына ешрак мөрәҗәгать итүе, идея принципларының заман таләпләре югарылыгында булуы, фикер кыюлыгы белән характерлана. Хисам Камалов чынбарлыкның каршылыкларын шомартып, киметеп күрсәтү белән мавыкмый — аның өчен хакыйкать, ачы дөреслек бар нәрсәдән дә өстенрәк, аның шигъри акылы «матур йөзгә, матур ялганга» табынмый.

Хисам Камаловның әдәби тәнкыйтьтә зур борчылу уяткан кайбер иҗади чатаклыклардан арына баруы һәм чын-чыннан художник буларак формалашуы күн кебек ачык. Шагыйрьнең соңгы елларда язылган әсәрләреннән заман сулышы киңрәк сизелә, аларның сәнгатьчә эшләнеше дә торган саен камилләшә бара. Шигъри хикәяләү җанлы сөйләм теленә якыная, халык авыз иҗаты элементлары шигырьләргә органик бер бөтен булып керә, җырлар, мәкальләр, үткен сүзләр ул сурәтли торган картиналарны җанландыралар, тулыландыралар. Классик шигырь калыплары аның өчен катып калган канун түгел: кирәк чакта сүзләр гадәти шигъри ярлардан ташып чыгалар, ритмик дулкыннар әле бер якка, әле икенче якка ташланып уйный башлый. Шагыйрь фикергә формасы буйсындыра — шигырьнең гомуми настроениесе киеренкеләнә, кырыслана бара. Хисам Камаловның «уч төбе — көч кебек», «җилкенү — җилкәнә», «түгә шул— күз яше», «түгел ул — күнегү», «шул чәчәк — нур чәчә», «уклаудай — йокларга», «мылтыктан — куркыттың», «әрләндәй — гарьләнми», «бабайлар — алайга», «тишми ул — кеше юк» кебек беренче карашка сәеррәк тоелган рифмаларга мөрәҗәгать итүен дә авазларның эчпошыргыч яңгырашыннан, колакны тондырып бетергән бертөслелектән, шигырь архитектурасының артык бизәкләреннән качарга тырышу юнәлешендәге эзләнү адымы дип карарга кирәк. Шагыйрь шигырьнең музыкальлегенә эчке аһәң, хисләрнең куертылып бирүе аша ирешә, аны:

Кем үйлаган?
Комбат, хуш инде!
Аерылышу безнең шушы инде! —

рәвешендәге халыкчан мотивлар белән баета.

Төрле елларда язылган «Әнкәй үлеменә багышланган шигырьләр» циклында

шагыйрьнең тирән психологик детальләр таба алуы, кешенең рухи халәтен табигыйлегендә сурәтләве, лирик героеның эчке дөньясына кыю рәвештә үтеп керүе күренде. Бу сыйфатлар аның бар иҗатына яңа төсмер, яңа мәгънә өстәделәр.

Соңгы елларда шагыйрь әледән-әле Ленин темасына мөрәҗәгать итә. Бу бик табигый дә. Бөек юлбашчыбызның якты истәлеге барлык әдәбият дөньясын илһамландыра. Хәзер аның образы күп кенә очракларда революция чоры белән хәзерге заманның бердәмлеге фонында, лирик планда хәл ителә, аерым шәхескә, аның язмышына бәйләп бирелә. Татар совет поэзиясендә Сибгат Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Ленин фәрманы белән» дигән әсәрләре бу юнәлештә беренче карлыгачлар булды. Хисам Камалов та бу изге теманы үзенчә чишәргә, Ильич образын үзенең эчке кичерешләре аша гәүдәләндерергә тырыша. Аның «Ленинга» исемле шигыре, мәсәлән, кешеләрнең, чорның Ленинга якын итеп, үз итеп эндәшүе булып яңгырый. Шигырьдәге:

Тол аналар белән елый-елый,
Түздек һаман, җыйдык сабырлык.
«Ленин исән булса,
Болай булмас иде!..» —
Диде абый...
Без, тешләрне кысып,
Сине сагындык!.. —

дигән юлларны тетрәнмичә укуы мөмкин түгел. Шагыйрь бүгенге көнне Ленин үлчәве белән үлчи, Ленин принципларының тантанасын күреп шатлана.

Х. Камаловның «Күңелдәге язулар»ы Ленинның бөеклегенә дан җырлый. Ләкин бу коры, декларатив зурлау түгел. Киресенчә, автор безне хәтта:

Табыну кебек булып яңгырамасын
Ярату һәм Ленин кирәклек.
Тыя-тыя гына язам менә
Сентиментка тарткан йөрәкне,—

дип алдан ук кисәтеп тә куя. Шагыйрь үзенең уй-кичерешләрен, тормышка карашын, кешеләргә мөнәсәбәтен Ленин исеме белән бергә үреп бара.

Яшәп булмый гамьсез, тыныч кына,
Алга бара тормыш, алышына;
Бәяләүләр еш үзгәреп тора:
Яңалыклар баса каршыңа.
Яңалыкны кайчак сизеп булмый,
Аның яшерен, эчке көчләрен.
Акылың белән болай аңлыйсың күк,
Консерватор була хисләрең.
Төрле-төрле уйлар кылычы мине
Кисеп тора, җаным айкатып.
Капма-каршы фикер телгәләве
Белән яшим әле кайвакыт.
Шул тартыштан арып, хәлдән тайгач,
Мин Ленинга барып сөяләм.
Киңәшсәм тик һаман аның белән,
Уйларыма мин көч җыя алам!

Бу шигыре белән автор үзенең зур фаҗигаләр тулы үткән юлына күз ташлый, үзенә ленинчыл ориентир эзли. Биредә без Ленин турында уйлануга, ил язмышын, аерым шәхеснең кичерешләрен Ленин эше белән үлчәүгә юлыгабыз. Шагыйрь Ленин темасына язучыларның иң матур традицияләрен дәвам иттерә һәм шуңа күрә хаклы рәвештә уңышка ирешә.

Хисам Камалов тынгысыз һәм эзләнүчән шагыйрь, әдәбият сөючеләр аның шигырьләрен көтеп алалар, яратып укыйлар. Матур табышларына, гүзәл геройларына сокланалар. Шагыйрь киләчәктә дә безне яңа ачышлары, эчкерсез шигырьләре белән куандырыр дип уйлыйбыз.

■ ■ ■ ■

# ҖЫР БАШЛАУЧЫ, ЮЛ БАШЛАУЧЫ

МАНСУР МОЗАФФАРОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Әле кайчан гына ул безнең арада иде. Уртача буйлы, базыграк гәүдәле бу мөлаем кешене консерватория аудиторияләрендә, Композиторлар союзы уздыра торган һәртөрле утырыш-җыелышларда һәм кичәләрдә еш очрата идек. Гаҗәеп дәрәҗәдә тыйнак, кече күңелле һәм ихтирамлы иптәш, гаҗәеп дәрәҗәдә сәләтле һәм киң колачлы композитор иде Мансур ага.



Казанның үзеннән яки Мәскәү радиосыннан берәр әсәрен тапшыра башладылармы, күз алдына шунда ук композиторның җанлы сурәте килеп баса. Еллар әнә аңа да үз эзләрен салып өлгергән. Чәчләре көмештәй ап-ак, битен җыерчыклар баскан, адымнарыннан ук арыганлык, талчыкканлык сизелә. Әмма көлемсерәп торган күзләре яшьләрчә нурлы һәм сөйкемле, күңеле һич тә картаймаган, яшь-яшь калган. Ул һаман да яшьләргә хас энергия белән иҗат итә, бетмәс-төкәнмәс иҗади хыяллар, зур планнар белән яши иде. Яңа гына больницадан чыгуына карамастан, соңгы көннәренә кадәр эш өстендә булды, «Галиябану» операсын яңадан сәхнәдә куярга ашкынып йөрде.

Вакытсыз килгән мәрхәмәтсез үлем аның үзен безнең арадан алып китте. Иҗаты, теләсә нинди үлемнәргә дә каршы торырлык гүзәл әсәрләре безнең белән калды, безгә калды. Олы йөрәкле художник-гражданин тарафыннан иҗат ителгән ул әсәрләр әле бик озак еллар буе тыңлаучыларны дулкынландырыр, аларга эстетик ләззәт бирер. Чөнки алар чын иҗат ялкыны һәм сүнмәс дәрт белән сугарылганнар. Чөнки Мансур ага Мозаффаров үз гомеренең 40 елдан артыграк өлешен халкына багышлады, 40 елдан артыгракка сузылган шул иҗат гомеренең һәр минутын, һәр сәгатен үз халкының музыка сәнгатен үстерүгә багышлады.

* * *

Әле Октябрь революциясенә кадәр үк, татар халкының профессиональ музыка сәнгате яңа шытып-үсеп килә барган бер заманда, яшь музыкант «Сәйяр» труппасына килә, труппа каршындагы ансамбльдә эшли башлый. Әмма ярым һәвәскәр, ярым профессиональ башкаручы булып кына йөрү сәләтле яшь егетне канәгатьләндерми. Әнә шуңа күрә дә, революция булып, халык арасыннан чыккан яшьләргә киң

мөмкинлекләр ачылуга, ул зур дәрт белән укырга, белемен күтәрергә тотына. 1919 елның көзендә Мансур Мозаффаров Казан музыка училищесына керә. Кларнет классы буенча училищены тәмамлагач, Мәскәүгә килә, башкала консерваториясенең композиторлык факультеты каршындагы этнография бүлегендә укый башлый. Биредә ул А. Н. Александров, С. В. Василенко кебек атаклы профессорлар кулында тәрбияләнә, музыкаль әсәрләрне аерым инструментлар өчен эшкәртү серләрен үзләштерә, иҗат эшенең нечкәлекләрен өйрәнә.

Югары белем алган аз санлы композиторларның берсе буларак, Мансур Мозаффаров татар халкының мәдәният эшләренә бик иртә, утызынчы елларның башыннан ук, катнашып китә. Башта ул күпмедер вакытлар Мәскәүдәге татар театрының музыка җитәкчесе булып эшли. Аннан Казанга кайта һәм байтак еллар буе Татарстан радиосында музыкаль тапшыруларны алып бара. 1945 елдан, ягъни Казанда консерватория ачылган беренче көннәрдән үк диярлек, Мансур Мозаффаров укытучылык эшенә күчә. Композиторның егерме елдан артык гомере консерватория белән бәйләнгән. Ул музыка теориясенә караган фәннәрдән дәресләр бирә, теория һәм композиция кафедрасын җитәкли.

Татарстан композиторлар союзы идарәсе члены, СССР музфондының Татарстан бүлеге вәкиле, хезмәт ияләренең Казан шәһәр советы депутаты Мансур ага Мозаффаров үзенә тапшырган һәр эшне зур җаваплылык тоеп, тырышлык һәм сабырлык белән, җиренә җиткереп башкара торган иде. Мансур ага югары культуралы, үз эшен яратып башкаручы укытучы һәм могтәбәр җәмәгать эшлеклесе иде. Әмма бу өлкәләрдәге эшчәнлеге никадәр генә зур, никадәр генә хөрмәтле булмасын, ул барыннан да бигрәк һәм беренче чиратта талантлы композитор. Тышкы яктан шактый тыныч һәм сабыр күренгән шушы тыйнак кешедә бетмәс-төкәнмәс энергия, иҗат энергиясе кайнап торды.

Һөнәре буенча ул фольклорчы түгел иде. Шуңа да карамастан, татар халык җырларының үзенчәлекләрен тирән белүче иң авторитетлы кешеләрдән исәпләнде. Бәхәсләр туганда, аңа мөрәҗәгать иттеләр. Ул язып алган җырлар (бу эш белән ул гомере буе шөгыльләнде) иң төгәлләрдән саналды. Теләсә ничек язып алынган көйләрне халык иҗатына ят авазлардан арындыру, очраклы нәрсәләрдән чистарту — гаять авыр эш. Башка татар композиторлары белән бергә, Мансур Мозаффаров та бу өлкәдә искиткеч күп эшләде. Аның татар халык җырларына никадәр сак каравын, халык иҗатын никадәр көчле һәм тирән яратуын белергә теләсәгез, 1964 елда Мәскәүнең музыка нәшриятында басылып чыккан «Татар халык җырлары» исемле җыентыкка күз салыгыз. Ул җыентыкны З. Хәйруллина һәм Ю. Виноградовлар белән бергә, Мансур Мозаффаров төзеде. Нәкъ шундый ук саклык белән, халык җырларының җанын, үзенчәлеген, характерын тирән тоеп, композитор аларны аерым башкаручылар, күмәкләп җырлау һәм төрле уен кораллары өчен эшкәртте.

Утызынчы еллар башында халык җырларын хор яки төрле уен кораллары өчен эшкәртү гадәтләнмәгән, өйрәнелмәгән, хәтта бәхәсле эш санала иде. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, моңа кырын караучылар да байтак була. Тирән белемле, сәләтле яшь композитор кыю рәвештә әнә шул яңа һәм зур принципиаль әһәмияткә ия булган иҗат эшенә алына. Татар халкының «Кара урман», «Тәзкирә», «Зәңгәр шәл» кебек борынгы көйләре беренче мәртәбә Мозаффаров тарафыннан эшкәртелә. Ул эшкәрткән теләсә кайсы көйне тыңлап карагыз! «Әнисә» яки «Зиләйлүк»ме ул, я булмаса «Салкын чишмә» яки «Дисәнә»ме, аларның һәрберсе тавыш тембрларының һәм тәэсир чараларының бай булулары, күп төрле булулары белән аерылып торалар. Иң әһәмиятлесе шунда, М. Мозаффаров халык көйләре белән үтә сак эш итә, җырның табигатен, үзенчәлеген аз гына да бозмый. Композиторның бу өлкәдәге эшчәнлеге практик яктан да гаять әһәмиятле иде. Ул эшкәрткән җырларны аерым артистлар башкара, яңа оешкан җыр һәм бию ансамбле шулар белән үзенең репертуарын баета.

Композиторның үз иҗаты да халыкчанлык рухы белән сугарылган. Абстракт экспериментлар белән мавыгу аның өчен чит-ят иде. Татар совет музыка сәнгатенең үсеш юлын ул халыкчан, милли традицияләрдән баш тарту дип тә, аларның ролен кечерәйтү яки аларны күрмәмешкә салышу дип тә аңламады һәм аңлатмады. Ул иҗат итеп калдырган һәр әсәр, бер яктан, халык җырларына, татар халкының

музыка сәнгате традицияләренә барып тоташса, икенче яктан, бүгенге сәнгатьнең реалистик алымнарына нигезләнгән.

Мансур Мозаффаров исеме татар совет җырлары тарихы белән аерылгысыз бәйле. Аның күп еллык иҗат илһамы бу өлкәдә дә якты эз калдырды. Атаклы композитор Салих Сәйдәшев кебек үк, ул да яңа, совет җырларын беренче башлап иҗат итүче һәм аларны армый-талмый пропагандалаучы булды. М. Мозаффаров җырның интонациясен, аның мелодиясен һәм агышын искиткеч тирән сиземләүче композиторларыбызның берсе иде. Аның күңеле тулы җыр булды. Шуңа да совет кешеләрен куандырган, аларны дулкынландырган һәрнәрсәгә ул җыр белән җавап бирде. Җыр аның рухи ихтыяҗы иде. Утызынчы елларның башында ук, татар композиторлары арасында беренчеләрдән булып, ул күтәренке рухлы «Октябрь җыры»н яза, «Колхозчылар маршы», «Ударниклар маршы», «Пионерлар маршы» кебек тәвәккәл, якты хисләр белән сугарылган әсәрләр иҗат итә. Утызынчы елларның икенче яртысында аның бу өлкәдәге эшчәнлеге тагын да киңрәк колач ала. Ул иҗат иткән җырларның тематикасы һәм жанрлары төрләнә, эчтәлекләре тирәнәя. «Сайра, сандугач» (Мөхәммәт Садри сүзләре), «Җиләк җыйганда» (Муса Җәлил сүзләре), «Тын бакчада» һәм «Яшь егетләр, яшь кызлар» (Әхмәт Ерикәй сүзләре) — композиторның чын мәгънәсендә халыклашып киткән җырларының кайберләре әнә шулар. Мансур ага иҗат иткән җырлар дәһшәтле Ватан сугышы елларында да һәм аннан соңгы чорда да өзлексез яңгырап тордылар. Сугыш елларында язылган «Туган ил өчен», «Поход җыры», «Фронтка, иптәшләр» кебек җырларны хәтергә төшерик. С. Урайский сүзләренә язылган «Син кайтмадың» исемле җырны кем генә белми икән?!

Соңгы елларда язган җырлары белән Мансур ага Мозаффаров тынычлык өчен көрәште, төрле ил халыкларының үзара дуслыгын ныгытышты, совет кешеләренең тыныч хезмәтен данлады. «Тынычлык солдатлары» (Сибгат Хәким сүзләре), «Шәһәр кызы» (Әминә Бикчәнтәева сүзләре), «Тик булса иде ирек» (Муса Җәлил сүзләре), «Тагын язлар килер» (Муса Җәлил сүзләре), «Менәргә иде Урал тауларына» (Гөлшат Зәйнашева сүзләре)... Хәер, саный китсәң, алар күп инде.

Билгеле, композиторның иҗади эзләнүләре бер җыр жанры белән генә чикләнми. Ул үз көчен вокаль музыканың башка тармакларында да сынап карый. Татар совет музыка сәнгате тарихындагы иң беренче һәм иң уңышлы романсларның берсен Мансур ага Мозаффаров иҗат итә. 1937 елда, илебез А. С. Пушкинның үлүенә 100 ел тулуны билгеләп үтәргә җыенган көннәрдә, яшь композиторны даһи шагыйрьнең «Җырлама син миңа...» исемле мәгълүм шигыре үзенә җәлеп итә. Һәм нәтиҗәдә әлеге романс языла. Композиторның икенче бер иҗат тәҗрибәсе дә игътибарга һәм һәртөрле хуплауга лаек. Сүз хор һәм симфоник оркестр өчен язылган «Бәхет юлы» (Хәй Вахит сүзләре) исемле сюита хакында бара.

Мансур Мозаффаров — опера сәнгатен үстерү өлкәсенә дә билгеле бер өлеш керткән композиторларыбыздан. Ул «Зөлхәбирә» һәм «Галиябану» исемле опералар язарга алынган иде. Шулардан тик соңгысын гына ахырга кадәр эшләп калдыра алды. Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры Мансур аганың бу әсәре белән кабат кызыксынып һәм «Галиябану»ны сәхнәдә күрербез, дип ышанасы килә.

Композиторның иҗат диапазонын тулырак күзаллау өчен, аның симфонияләренә һәм инструменталь әсәрләренә, шулай ук балалар өчен язылган музыкасына да тукталмый булмый. Музыка сәнгатенең бу тармакларында да ул гаять үзенчәлекле бай мирас калдырды. Балаларның әдәби зәвык һәм таләпләренә искиткеч сизгер булу, алар яраткан җырлар репертуарын өзлексез баетып, тулыландырып торырга омтылу композиторны нәниләр өчен армый-талмый эшләргә этәрде. Кем белә, бәлки, нәкъ әнә шул нәни музыкантлар белән очрашулардан Мансур ага үзенә иҗади илһам алгандыр, үз иҗаты өчен яңа буяулар, яңа бизәкләр тапкандыр. Аның утызынчы елларда чыккан беренче җыентыгы ук балалар бакчасында тәрбияче булып эшләүчеләрнең өстәл китабына әйләнә. «Шаяру», «Кызлар биюе», «Вальс-скерцо» кебек фортепьяно өчен язылган әсәрләрен яшь музыкантлар әле дә яратып башкаралар.

Симфоник музыка өлкәсендә аның таланты тагын да тулырак ачылды. Мозаффаровның симфоник әсәрләре зур уңыш казандылар. Бу өлкәдәге эшчәнлеген, татар көйләренә увертюра, лирик сюита кебек әсәрләр язып, ул утызынчы елларның

уртасыннан ук җәелдереп җибәрә. 1944 елда композитор үзенең Беренче симфониясен тәмамлый. Бу әсәрләрдә бик матур урыннар, истә калырлык образлар күп. Шулай да иң әһәмиятле симфонияләр әле язылмаган, алар әле алда иде. Аларны язганчы яшь композитор байтак кыенлыклар аша узарга, бик актуаль һәм мөһим иҗат мәсьәләләрен уңай хәл кыларга, симфоник музыканың классик принципларын үзләштерергә, аларны милли традицияләр белән бәйли белергә өйрәнергә тиеш иде. Эзләнүләр, көн-төн тир түгүләр бушка китми. Мансур Мозаффаров Тукай һәм Мулланур Вахитовлар истәлегенә багышланган ике зур симфоник поэма иҗат итә, скрипка һәм оркестр өчен ике концерт тәмамлый. Бәлки, бу әсәрләрнең барысы да бер югарылыкта эшләнмәгәндер. Бәлки, аларда ахырга кадәр эшләнеп бетмәгән аерым урыннар да бардыр. Әмма, сәнгать әсәре буларак, аларның кыйммәтен, әһәмиятен бөркем дә шик астына ала алмас. Ул әсәрләр югары идеяле булулары, сәнгатьчә камил эшләнүләре белән аерылып торалар. Халык шагыйре Тукай һәм ялкынлы революционер Мулланур образларын иҗат иткәндә, композитор сәнгатьчә искиткеч зур гомумиләштерүләр ясый. Әгәр Тукай истәлегенә багышланган поэманың музыкасы лирик буяулар белән өретелгән һәм татар халык җырларының сафлыгы, пакьлыгы белән сугарылган булса, Мулланур Вахитов хакындагы поэманың музыкасы тирән омтылышлы һәм героик пафослы булуы белән аерылып тора... Җыеп кына алганда, Тукай премиясе лауреаты, Татарстанның халык артисты, композитор Мансур Мозаффаровның иҗат юлы әнә шундый. Үзе ул безнең арада юк инде, әмма музыкасы һаман яшәтелә. Һәрбер чын художник, халык бәхете өчен көрәшкән һәр каһарман үлемсез була, диләр. Мансур Мозаффаров мирасы да үлемсез. Татар совет музыка сәнгате тарихына аның исеме җуелмас хәрефләр белән язылыр. Чөнки ул яңа җыр башлаучыларның, яңа юл башлаучыларның берсе иде.

Я. ГИРШМАН,
сәнгать фәннәре кандидаты

++++++

# «ЭЗЛӘР»[1] БУЙЛАП

Шигырьне нәрсә тудыра? Бу шулкадәр киң колачлы сорау ки, җирдә яшәүче һәм яшәячәк шагыйрьләр никадәр күп булса, җаваплар да шулкадәр күп һәм төрле булачак. Ә яшь шагыйрь Рөстәм Мингалимов аңа болайрак җавап бирер иде кебек: минем шигырьләрне вагон тамбурларына, мәктәп коридорына, бораулау будкасы идәненә, университетның мәрмәр баскычларына һәм шул юллардан хәтер дәфтәремә күчеп уелып калган үз эзләрем тудыра.

Шигырьләр — эзләр... Салынган эзләр буйлап теләсә кем сәяхәткә чыгарга хаклы. Бәс шулай икән — юлга! Бәлки, безне бу юлда мавыктыргыч үзәнлекләр көтәдер? Ә бәлки, игътибарсызлык аркасында төзәтелми калдырылган юл сикәлтәләредер?.. Әйе, әйе, шигърияттә барысы да булырга мөмкин. Чөнки һәр яңа шигырь китабы ләззәтле билгесезлеккә салынган беренче эз ул...

Төнлә кайтам...
Вагон тәрәзенә ябыштырып куйган
рәсем кебек кереп киләм,
Татарстан, синең чигеңнән.
(«*Кайту*»).

Зур төзелешләрдә, заводларда, чирәм җирләрдә эшләп, озак вакытлар буе Татарстаннан аерылып торган, аны чиксез сагынган шагыйрь туган ягына яңадан кайтып килә. Лирик геройның ирләрчә кырыслыгын изге туган җир шатлыгы иркәли. Шагыйрь күңелендә балаларча эчкерсезлек пәйда була. Шуңа күрә, ул:

Төн бүген
көннең яктысын
Саклап калган үзендә,—

дип, биш еллык аерылу чорында төшендә генә күргән сыман тоелган туган ягын күзәтә.

Кар төшә,
кар бөртекләре:
үрелеп тотам берсен:
янәсе, авыр түгелме,
каты бәрелеп җиремне
авырттыра күрмәсен.
(«*Таныш кырларда*»)

Әлбәттә, кар бөртеге төшеп җирне авырттыра күрмәсен, дип борчылу олы кеше өчен бик үк табигый дә түгелдер. Ләкин ул — шагыйрьнең шушы мизгелдәге эчке кичерешләре белән аклана. Бу борчылу үзенең балаларча булуы белән хәтергә сеңеп кала, ул туган як турында җитди уйланулар, балачак хатирәләре булып үсә һәм, шигырьне укыгач, күңелдә туган якны сагыну хисе туа. Бу минутта син туган якның никадәр кадерле икәнен тоясың, синең акылың Ватан дигән төшенчәнең асылына тагын да тирәнрәк үтеп керә. Әйе, эчкерсез сабыйлыкның нигезендә һәрвакыт ниндидер бөеклек башлангычы ята.

Эзләр буйлап бара торгач, без шагыйрь укыган мәктәпкә килеп чыгабыз. Класс. Сары өстәлдә — глобус. Шагыйрь аны бармагы белән әле уң якка, әле сул якка,

[1] Рөстәм Мингалимов. Эзләр. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1967 ел.

әле тизрәк, әле акрынрак әйләндерә. «Материклар» һәм «таулар», «океаннар» һәм «кырлар», «елгалар» һәм «шәһәрләр» шагыйрь теләгән якка, шагыйрь теләгән тизлектә әйләнәләр. «Мин күргән беренче дөнья нинди җиңел булган!» — ди шагыйрь «Мәктәпкә кайткач» исемле шигырен тәмамлап. Ләкин шигырь әле моның белән генә бетми, ул укучы күңелендә дөньяның бүгенге йөзе белән аның балачактагы чагылышын янәшә куеп карау булып үсә. Әйе, без беренче күргән дөнья инде шактый үзгәргән. Дөресрәге, без үскәнбез, ныгыганбыз һәм безнең карашларыбыз бер ноктада гына торып калмаган, үскән. Вакытлар үтү белән без тормыш күренешләренә һәм әйберләргә карата булган шәхси карашыбызны яшәешнең бай тәҗрибәсе белән тулыландыра килгәнбез.

«Военкоматта» дигән шигырьдә шагыйрь, сугыш елларында әле малай гына булган яшьтәшләренең эштә чыныгып үсүләре турында сөйли дә, комиссия әгъзаларының шушы чыныккан малайларны хәрби хезмәткә яраклымы-юкмы дип төпченеп, аларны тимер үлчәгечләр белән үлчәп торуларына канәгатьсезлек белдерә. «Хезмәткә яраклы дип языгыз, үлчәмичә генә»,— ди ул. Бу шигырьдә дә бүгенге күренешләргә узганнар аша карау, бүгенге үсешне элек булып узган вакыйгалар аша күрсәтү алымы кулланылган.

Яшьлек елларымны,
сарут белән бутап,
аттым
яшел эскерт өстенә,
буразнага салдым —
кыр тутырып,
эре башак булып үстеләр;
кайсыларын
асфальт белән кушып
олы юлга җәеп калдырдым;
кайсыларын
корыч эреткәндә яндырдым.

(*«Минем яшьлек»*)

Шушы юлларны укыгач, ирексездән, шагыйрьнең «Военкоматта» дигән шигыре яңадан искә төшә. Һәм син шигырьдәге килешмәүчәнлекнең шартлы рәвештә генә икәнлегенә, аның шагыйрь өчен бик табигый халәт булуына һәм шигырьнең асылында кешеләргә, тормышка яхшылык теләү фикере ятуына тагын бер мәртәбә ышанасың.

«Җиргә бер сүз» дигән шигырь үзенең көн темасына багышланган булуы белән кызыклы. Монда шагыйрь бер үк вакытта шатлык һәм күз яшьләре, ракета һәм электр көче булдыручы, кеше өчен бер үк вакытта матур тормыш һәм вакытсыз үлем тудыручы Җиргә карата үзенең шәхси мөнәсәбәтләрен ачыкларга омтыла.

Кадер-хөрмәт күрсәталам диеп,
кызыктырма минем күңелне.
Каберлекләр күрсәталам диеп,
бозып торма минем күңелне.
Ике аралыкта торасың, дип,
син көләргә миннән кыйма, җир:
әнкәм мине шушы төштә тапкан,
син шушыннан миңа мәйдан бир.
Фикеремдәге шатлык монда юк та,
фикеремдәге кайгы да юк монда,
шушы төштә яшәп,
шушы төшкә охшаш
җырлар языйм әле шушында.

Һәм шагыйрь менә шушы туган Җирдә ритмик төзелешләре белән хәрәкәтчән, эчтәлекләре белән драматик шигырьләр яза. Беренче карашка, аларда, чыннан да, ике аралыктагы — яшәү белән үлем арасындагы — нәрсәдер бар шикелле тоела, ләкин шунысы әһәмиятле, бу «нәрсәдер» — якты, ачык рух белән сугарылган оптимизм. Эчтәлеге белән драматик характердагы «Сөйләшүдән өзек» шигырендә дә төп максат әлеге олы эчке оптимизмга кайтып кала. Шагыйрь кешенең тормышка мәхәббәте табигый хис икәнлекне раслый. Бу шигырьнең фәлсәфәсен якынча болай әйтеп булыр иде: «кеше дөньяга курку төшенчәсен белмичә генә туа. Шулай булгач, кеше табигате белән үк оптимист...

Шушы урында бераз гына тукталыш ясап, узган юлыбызда алган тәэсирләребезне барлап карыйк. Укучы инде, әлбәттә, китапны уку барышында шигырьләр — эзләрнең бик биографик икәнлекләрен сизгәндер. «Эзләр»дәге лирик геройның тормыш юлы авыр сугыш елларында һәм сугыштан соңгы елларда узган, шул елларда ук балалыктан балигъ булган. Аның тормышы шул чор шартларын һәм кыенлыкларын татып яшәгән совет яшьләренекеннән аз аерыла. «Эзләр»нең герое көндәлек тормышта безнең белән яши, безнең белән бергә кала һәм елый, очрашу шатлыкларын һәм аерылу сагышларын кичерә, кемнәр беләндер дошманлаша һәм яңа дуслар таба, атом һәлакәте турында ишетә һәм алмагачлар утырта.

Укучы, әлбәттә, Рөстәм шигырьләренең күбесе балачакка багышланганлыгын, яки шушы мәңгелек якты елларга чигенешләрнең күп булуын да абайлагандыр. Балачакка чигенешләр Рөстәм Мингалимов әсәрләренә бер якытан эчкерсезлек, күп төсләлек һәм җылылык бирсәләр, күп очракта алар шагыйрьнең шигъри алымына, шигырь корудагы төп чарага әверелеп китәләр. «Эзләр», «Военкоматта», «Энем, утыр, илтәм», «Минем яшьлек», «Матурлыкны шунда таныдым» һәм башка шигырьләрдә балачакка чигенеш шагыйрьнең бүгенге фәлсәфәсен аңлатуда төп алым булып тора. Әлбәттә, бу инде — әдәбият тарихы өчен таныш алым. Ләкин һәр кешенең балачактагы карашлары үзләренчә истәлекле, үзләренчә кызыклы. Шунысы куанычлы, Мингалимов шигырьләрендәге балачак узганнарны сагынып елау түгел, ә бүгенге чынбарлыкка төшенү юлы, аңа бәя бирү, андагы зур яңарышларны тою чарасы Димәк, әнә шул хисләрне төгәл сурәтләргә мөмкинлек бирүче әдәби алым. Бу — шагыйрьнең методологик табышы. «Эзләр»нең авторы шуның ярдәмендә төгәллеккә, зур максатларга, драматизмга һәм оригинальлеккә ирешә, аның шигырьләре аңлаешлы һәм бизәкләргә бай булулары белән аерылып торалар.

Сүзне төгәлләр алдыннан шуны да әйтеп үтәсе килә, Рөстәмнең шигырьләрендә модага ияру, фикерне кирәгеннән артык катлауландыру, форма кыланчыклыгы кайбер тәнкыйтьчеләр әйткәнчә үк күп түгел. Аның карашы «Эзләр» тулысынча эчкерсезлек белән сугарылган. Ә инде эчкерсезлек һәрвакыт диярлек яңалык та алып килә. Шунысы кызык, Рөстәмнең бу шигырьләре татар әдәби хәрәкәтендә традиция һәм новаторлык турында кайнар бәхәсләр барган чорда язылдылар. Хәтта шушы шигырьләрнең бер өлеше ул бәхәсләргә сәбәпче дә булды. Ул чорда яшь татар поэзиясенә карата булган тәнкыйтьтә образларны кирәгеннән артык детальләштерү һәм фикерләрне аңлы рәвештә артык ваклау белән мавыгу аркасында, шигырьләрнең аңлашылмавы, гомумиләшүе һәм прозаик яңгыраш алулары турында сүзләр булган иде. Боларның күбесе хәзер Рөстәм Мингалимов шигырьләренә хас сыйфатлар түгел. Шулай да кайчакта шигырь төзелешенең камиллеген прозаик юллар шактый бозып тора әле. Прозаизмнар шигырьнең беренчел дәрәҗәдәге әһәмиятле, ягъни шигырьнең төп фикерен тудыра торган юлларында түгел, ә логик бәйләнеш, шигырьнең форма төзеклеге өчен генә кирәк булган, ягъни әһәмият икенче дәрәҗәдә булган урыннарда ешрак очрыйлар. Кайбер очракларда («Эзләр» шигыре) шигъри детальләрнең артыграк, чамасызрак кулланылуын да күреп була...

Соңгы ноктаны куяр алдыннан «Эзләр»дән тагын берничә юл шигырь китереп үтәсе килә:

Барам,  
Җир,  
әйләнеп,  
эзләремне чорный үзенә —  
фотопленка сыман.

(«Эзләр»).

Эзләр яңа сәяхәтләргә чакыралар. Һәм без, яшь шагыйрь әдәбият сөючеләрне яңа шигырьләре белән яңа маршрутларга дәшәр дип, көтеп калабыз.

Ренат ХАРИСОВ.

## Рифгать Закиров

### Торналар киткәндә

И торналар оча,
Оча югарыдан:
Безгә дөнья иркен,
Чик юк дигән сыман.

Оча алар безнең
Туган җир аша да,
Безгә дус һәм дошман
Булган ил аша да.

Алар белми аны,
Алар оча ерак:
«Торыйк, мәңге тату
Торыйк!» — диеп җырлап.

...Без — кешеләр дә бер
Шул торналар ише
Йөрешербез микән,
Белмиенче чикне!.

### Тормыш җыры

Кем җыры бу! Җилләр, сезме!
Көне буе бертуктаусыз,
Һаман, һаман ял белмичә
Киң кырларда җыр сузасыз —
Чакырасыз...

Кем җыры бу! Ташкын, синме!
Болай шаулый ташкын гына!
Әллә ничек бу шау мине
Гел каядыр ашкындыра,
Гел чакыра!..

Кем җыры бу! Мин белмәгән,
Чибәр кызый, әллә синме!
Җырлар җырлап абыеңны
Еракларга өндисеңме!
Әйт, бу синме!..

Кем җыры бу!.. Көмеш кылдай
Чыңлый мәллә кояш нуры!
Ни булса да — дәртле җыр бу,
Мәгаен бу — тормыш җыры!!
Тормыш җыры...

Бу җыр сүнми,— күз алдымда
Чаткыланып яшен төсле,
Мине шулай ашкындырып,
Әле мең ел дәшер төсле!
Дәшер төсле!..

Эдуард Касыймов

# Җиде сорауга бер җавап

«Бир кулыңны, дустым!» повестем басылганнан соң, миңа байтак хатлар килде. Ихлас күңелдән чыккан җылы сүзләр, матур теләкләр белән тулган хатлар...

Язучы өчен шуннан да куанычлысы юктыр...

Илебезнең төрле якларыннан, төрле почмаклардан язалар. Хат авторлары — төрле профессия кешеләре. Шахтер да (Г. Ситдиков — Антрацит каласы), колхозчы яшьләр дә (В. Ардаширова, З. Хөсәенова, З. Аллабирдина — БАССР, Иске Биккенә авылы), сәүдә эшчесе дә (Вәлиәхмәтова — Октябрь Норлаты, Бурмәт авылы) һәм бүтән һөнәр ияләре дә үз фикерләрен язып җибәргәннәр. Мәктәп укучылары, укытучылар һәм китапханә хезмәткәрләре кулы белән язылган хатлар да байтак. Җылы сүзләре, киңәш-теләкләре өчен аларның барысына да рәхмәт!

Шулай, безнең бүгенге көн татар әдәбиятын һәр кайда да яратып укыйлар, ә бердәнбер журналыбыз «Казан утлары»ның һәр санын бик көтеп алалар икән. Монысы аеруча куандыргыч хәл!

Арада мине иң дулкынландырганы Киров өлкәсенең Вятка елгасы буенда утырган Түбән Шөн авылыннан килгән хат булды. Хатны математика укытучысы, хәзерге көндә пенсионер Мәрьям апа Маннапова язган. Шул авылның урта мәктәбендә мин заманында ике ел тарих укыткан идем, шунлыктан Мәрьям апаны бик әйбәт беләм: матур әдәбиятны бик күп укый һәм тәмен белеп укый, гомумән әдәби зәвыгы гаҗәп югары аның. Турысын әйткәндә, мин әдәби әсәрләр язган чагымда әдәбиятны яраткан, аны тирәнтен белгән һәм аңлаган, һәр вакыт таләпчән булган Мәрьям апа кебек укучыларны күз алдымда тотам да... Ниләр язган соң ул мөхтәрәм укытучы апа? Озынгарак китсә дә, мин аның хатыннан өзекләр китермичә булдыра алмыйм.

«Сезгә билгеле булганча,— диган ул,— мин әдәбият белгече дә, тәнкыйтьче дә түгел. Тик әдәбиятны яратып укучы гына. Шулай да повестьны укыганда туган уй-фикерләремне әйтергә уйладым.

Кешенең эчке кичерешләрен бик оста биргәнсез. Укыганда Әлбинә белән бергә көенәсе, бергә елыйсы килә, Роберт белән бергә Әхсәннең яңагына да чалтыратасы килә. Димәк, тәэсир көчле. Бусы инде тел байлыгына һәм тасвирлау осталыгына бәйледер. Әсәрнең тәмамлануы да бик матур. Иптәшлек, дуслык хисе, кирәк чакта чын күңелдән ярдәм кулын сузу — яшьләргә бик зур үрнәк булырдай сыйфатлар. Журналның икенче саны килгәнче «нәрсә белән бетәр?» дип күп баш ваттык. Төрле вариантлар «иҗат» итеп карадык. Ләкин көтелмәгәнчә бик тә күңелле килеп чыкты.

Темасы үзе дә (алданган кыз, ирсез бала тудырырга тиеш булган а в ы л укытучысы) бик кызыклы бит. Тормышта очрый торган хәл. Минем төрле җирләрдәге 35 еллык педагогик практикамда булды мондый хәлләр. Төрле очракта төрлечә хәл ителә иде...»

Аннары Мәрьям апа үзенең киңәш-табышы белән дә уртаклашкан:

«Лакин мин бер нәрсә белән риза түгел. Эш менә нәрсәдә: Әхсанне шул килеш кенә калдырмаска иде. Дөрес, Светлана аның башына бик көчле давыллар җибәрергә җыена. Лакин бу әле сүздә генә. Әхсан — яшь белгеч, спортсмен. Эшләгән җирендә авторитетлы кеше. Тик аның черек пижонлыгы, хатын-кызга шундый түбән карашы бер кемгә мәгълүм түгел. Ул алда да шул ук кабахәтлеген кабатларга мөмкин. Әгәр аның түбән җанлылыгы җәмәгатьчелек алдында фаш ителеп, аны ачы үкендерерлек дәрәҗәгә китерелсә, әсәрнең яшьләр өчен мораль тәрбия тәэсире тагы да көчлерәк булыр иде. Повестьның күләме зур түгел. Әзрәк сузганда да зарар итмәс иде. Әхсанише начар егетләр бездә юкмыни? Бар, әз дә түгел. Тормышта аларның күбесе «сәер иттем тегене» дип, бармак шартлатып йөрсәләр да, әдәбият битләрендә андыйларга кискен җәза кирәк иде.

Әсәрдә төп героиня итеп укытучыны сайлавыгыз һәм аны әшнә бик җитди караучы укытучы итеп күрсәтүегез миңа ошады. Кызганычка каршы, әдәбиятта бу образ бик сирәк очрый...»

Әйбәт киңәш.

Әйе, безнең бүгенге укучыларыбыз яңа басылып чыккан яхшы әдәби әсәрләрне яратып каршы алалар, әдәбиятны асылына төшенеп, белергә омтылалар һәм әсәрләрдәге геройлар язмышын үзләренә бик якын күреп кабул итәләр. Юк, ул гына да түгел, алар әдәби әсәрләрдәге теге яки бу мәсьәлә уңае белән борчылуга бирелеп, авторга үтә кыйммәтле фикерләрен әйтәләр, теләкләрен белдерәләр һәм күп кенә кызыклы сораулар бирәләр.

Аерым очрашуларда һәм Алабуга педагогия институтында үткәрелгән укучылар конференциясендә әйтелгән, шулай ук хатларда куелган сорауларны барлап-сөзеп чыксам, алар җидегә тупланды. Мин бу мәкаләмдә әнә шул сорауларга җавап бирмәкче булам.

Беренче сорау.

— «Бир кулыңны, дустым!» повестен язганда тормыштагы нинди күренешләр сезгә этәргеч сәбәп булдылар? Аны нинди теләк белән яздыгыз?

— Алданган кыз темасы яңа түгел. Халык иҗатында һәм матур әдәбиятта ул элек-электән үк яктыртылып киленгән (фольклордан «Мәгъсүмә», «Асрау кыз», «Сәрби» бәетләрен, XX йөз башы әдәбиятыннан З. Һадиның «Бәхетсез кыз» хикәясен һәм атаклы совет шагыйре Һ. Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» исемле мәшһүр поэмасын искә төшереп китик). Дуслык һәм мәхәббәт темалары әдәбиятта һәм сәнгатьтә гомергә алар, чөнки һәр буын аларга бәйләнешле олы, матур күренешләрне дә, күңелсез, хатта фаҗигале якларын да үзенчә яңартып бара. Язучы да үзенең караш-бәягенә һәм заман таләпләренә бәйле рәвештә бу проблеманы үз буяулары белән тасвирлап бирә. Мин дә, моңа керешеп, аны үземчә аңлап, үземчә куертып, бүгенге көн таләпләренә һәм нормаларына туры китерергә тырышып, әлбәттә, киң җәмәгатьчелек алдына аны бөтен катлаулылыгы белән китереп куярга омтылдым.

Мәгълүм ки, безнең татар кызлары әүвәлге заманнардан ук үзләренең сабыр һәм тыйнак, тотнаклы һәм әдәпле булулары белән билгеле. Ул халкыбызның бик борынгыдан килгән күркәм холык-табигатенә, матур гадәтләренә турыдан-туры бәйле. Кызганычка каршы, соңгы вакытларда бер өише яшьләребез, әлеге шул сыйфатларга төкеребрәк карап яки аны белмәмешкә салынып, җилбәзәкләнкә, хатта азып-тузып йөрүләргә хәтле баралар. Мондый хәлләрне ишетү ук йөрәккә агулы ук булып кадала, һәм мин бу турыда язмыйча булдыра алмыйм...

Тагын шунысы да бар: рәсми органнарның раславына караганда һәм күзәтүләрдән күренгәнчә, хәзерге яшүсмерләр моннан егерме-утыз ел элеккедән ике ел чамасы иртәрәк җитлегәләр. Бу исә педагоглар алдына зур һәм җитди проблемалар китереп куя. Аңардан тәрбияви йогынтысы гаять куәтле булган матур әдәбият та, ягъни сүз осталары да, читтә кала алмый. Һәм без моңарчы яшеренебрәк һәм томаланыбрак торган кайбер нәрсәләрне ачыграк, кискенрәк һәм кыюрак итеп күрсәтергә-аңлатырга бурычлыбыз. Тормышыбыз шуны таләп итә. Мин үзем әлеге повестьны язып, яшьләрне бу четерекле һәм җитди мәсьәләгә игърак карарга, уйланырга һәм тиешле нәтиҗәләр ясарга азмы-күпме этәрә алганмын икән, асыл максатыма ирешкәнмен дип саныйм...

Икенче сорау.

— Повестьтагы геройларның прототиплары бармы? Алар кемнәр? Бик тә акыллы һәм тыйнак кыз Әлбинәнең шундый хәлгә төшүе акланамы?

— Алдарак язылган «Кояш көн дә чыга» повесте һәм «Гомер ике килми» романының прототиплары бар иде, ә бу әсәр реаль тормышта яшәгән конкрет кешеләрнең язмышына турыдан-туры таянмый. Димәк, прототиплары юк. Ләкин, алда әйтелгәнчә, Әлбинә язмышына юлыкканнар дөньяда аз түгел. Минем төп бурычым тормышта булган аерым күренешләрне, аерым язмышларны мәгълүм дәрәҗәдә гомумиләштереп, конкрет геройлар язмышында, ягъни әдәби образларда гәүдәләндерү булды. Барысы да турыдан-туры тормышыбызга бәйләнгән хыял җимеше, иҗат җимеше...

Әлбинәнең үтә тырыш, уңган, акыллы һәм тыйнак кыз рәвешендә бирелүе... Юк, җилбәзәк холыклы, үзләре үк туарылырга йөргән кызларны әйтеп тормыйк, хәтта әнә шундый нык характерлы, акыллы кызлар да, кайчакның мәгълүм шартларында, абайламыйча абынып-сөртенеп куялар икән. Димәк, итәкләрсңне җыя белеп, үз-үзеңә, үзеңнең көчеңә дулкыннарыңа баш булып йөрергә кирәк... Аның укытучы, бигрәк тә авыл укытучысы булуы... Мин аны теләсә кайсы профессия, һөнәр иясе — әйтик, врач, тегүче, сыер савучы, инженер һ. б.— итә алыр идем. Ләкин аның укытучы булып керүе шулай ук тикмәгә түгел: үзе тәрбияче, ә үзе әнә нинди аяныч хәлдә. Бу инде әсәрнең драматик коллизиясен үстерү, ягъни аның тәрбияви-эстетик тәэсирен көчәйтүне күздә тотып эшләнде...

Өченче сорау.

— Роберт кебек егетләр тормышта чыннан да очрыймы?

— Бу уңайдан иң әүвәл Уфа каласында яшәүче укучы Госман Хәмзин хатыннан бер өзек китереп үтим. Менә ни яза ул: «Сезнең повестегыз миңа бик нык тәэсир итте, чөнки миңа да гомеремдә Роберт ролендә булырга туры килде. Роберт чын йөрәкле кеше, мин аны чын күңелдән ихтирам итәм. Ул үзе упкынга төшсә дә, чын дуслык кулын Әлбинәгә сузган...» Димәк, тормышта андыйлар бар, һәм, минемчә, аз да түгелдер. Аннан килеп, тормыштагы уңай күренешләрне, гәрчә алар сирәгрәк очрасалар да, киң катлау укучыларга үрнәк булырдай иттереп, калку рәвештә бирү, безнең совет әдәбиятында асыл сыйфатларның берсе бит.

Дүртенче сорау.

— Ни өчен повестьта Әхсән кебек «эт җанлы» кешегә бер төрле дә җәза бирелми?

— Монысы бик күп укучыларның бәгыренә тигән, күрәсең, алар да аңа каты җәза таләп итәләр. Дөрестән дә шулай, гәрчә әсәрдә аңа җәза бирелмичә калса да, ул каты җәзага бик тә лаеклы. Ләкин аны ашыгып эшләү урынлы булырмы? Әсәрнең сюжет тукымасына килик. Әхсән анда күп урын алып тормый. Аның характерындагы төп сызыклар Әлбинәнең кичерешләре һәм бүтән иптәшләренең мөнәсәбәте аша, ягъни нигездә информация рухында ачыла, Роберт белән бәрелешкән вакытта гына аны ачыграк күрәбез. Әхсәннең уй-кичерешләре ниндирәк юнәлештә бара, ул нинди планнар кора икәнен, һәм аның бүтән якларын белмибез. Бер Әхсән генә түгел, бүтәннәрнең дә, хәтта үзәк геройлардан Робертның да башка яклары (хезмәттә, кешеләргә мөнәсәбәте, идеалы һ. б.) безгә билгесез. Боларны, әлбәттә, сурәтләргә булыр иде, ләкин ул чакны автор төп темадан, сюжетның төп агышыннан — алданган кызның фаҗигасе-язмышы һәм шуңа дусларының мөнәсәбәтеннән — шактый читләшер иде. Әсәрнең начар куелган кибән сыман бүселеп торуы мөмкин.

Ләкин, шулай да, Әхсән кирәген алырга тиешле. Әмма ничек? Җыелышка куепмы яки башкача фаш итү юлы беләнме? Мөмкин, әлбәттә. Тормышта еш кына шулай эшләнә дә. Ләкин бу юл үтә җиңел. Минемчә, ул, укытучы Мәрьям апа Маннапова әйткәнчә, «ачы үкенергә», үз-үзен гаепләргә, көенергә-янарга, ягъни аның мещанлык карашлары челпәрәмә килеп җимерелергә тиеш. Ә бу повестьта әле моның өчен җирлек тә, вакыт та җитенкерәми. Темасы да икенче яккарак карый. Димәк, моның өчен вакыйгаларның дәвамлырак булуы таләп ителә (ашыгып, тормыш логикасын бозып куймыйк!), ягъни повестьның дәвамы кирәк булып чыга.

Бишенче сорау.

— Повестьтагы геройларның үзара мөнәсәбәтләре, язмышлары соңыннан ничек дәвам итә?

— Моны күп кенә укучылар: «Әлбинә баласын табамы? Октябрь бәйрәменә Роберт аның янына барамы? Светлана Әхсәнне Берләшмә кешеләре алдында фаш итәме? Гөлсинә йөргән егетенә кияүгә чыгамы?» — диебрәк, бик ваклап та сорыйлар. Әйткәнемчә, бу әсәр конкрет фактлар җирлегендә фикерләү һәм хыяллану җимеше, тормыштан турыдан-туры күчереп язылмаган. Анда укучылар өчен уйларлык бик күп нәрсәләр калдырылды. Мин барын да хәл итеп бетермәдем. Ләкин язган чагымда ук аның дәвамы булырга тиешлеген сиздем, белдем. Шунлыктан, чәчелмәдем. Аннары, бу сорауларда әдәби әсәрләрнең нинди нәрсә икәнлеген төшенмәү дә сизелеп тора. Кызганычка каршы, укучылар арасында язучы үз әсәрендәге вакыйгаларны тормышта ничек булса, нәкъ шулай итеп сурәтли дип уйлаучылар да бар. Бу мәсьәләне аңлау өчен әдәбият укытучыларына, күрәсең, күп тырышасы бар әле.

Шулай да әйтим, бу әсәрнең дәвамы кайчан да булса язылачак. Дөресрәге, ул бөтенләй икенчерәк темага караган бүтәнчәрәк әсәр булачак. Анда бер кеше язмышына (алданган кыз фаҗигасенә) мөнәсәбәттә генә түгел, бәлки тормышның бөтен катлаулыгында ике нәрсә: мещанлык идеологиясе, обывательчелек (Әхсән) һәм коммунистик мораль, чын кешелек карашлары (Роберт) үзара пычакка-пычак килеп бәрелешергә тиешләр.

Алтынчы сорау.

— Сезнең тормыш юлыгыз ничек булды, иҗат итә башлавыгыз кайчаннан бирле?

— Бу турыда сөйләшү бик уңайлы булмаса да, укучыларның теләген үтәү йөзеннән, кайбер мәгълүматларны кыскача гына әйтергә мөмкин. Менә алар — Татарстан китап нәшрияты 1968 елда чыгарачак «Татарстан язучылары» исемле био-библиографик белешмәлектә күрсәтелгән фактлар: Киров өлкәсенең Слободской районындагы Нократ авылында укытучы гаиләсендә 1930 елның Октябрь бәйрәме көнне (сигезендә) туганмын. Димәк, малай чакта: «Без Октябрьда туганнар, без Октябрь баласы. Октябрьда туганнарның Ленин була бабасы», — дип авыз тутырып җырлап йөрергә тулы хакым булган. Әтием Салихҗан әдәбият укытучысы һәм мәктәп директоры була. Әнием бик күп еллар буена балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Безнең гаилә тормышы «Гомер ике килми» романында шактый тулы тасвирланды. 1953 елны Казан дәүләт университетының татар бүлеген тәмамлагач, мин Азнакайда, Түбән Шөндә һәм Малмыж каласында укытучы булып эшләдем. 1957 елда Татар радиосы корреспонденты булдым, 1958—1960 елларда Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор секторында аспирантурада укыдым, шунда ук ике ел буена гыйльми хезмәткәр булып эшләдем. 1966 елда татар халык әкиятләрен тикшерүгә багышланган диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты дигән фәнни дәрәҗә алдым. Әдәби әсәрләр яза башлавым мәктәп елларында булса да, беренче кыска очерк һәм хикәяләрем илленче еллар башында басыла башлады. Хикәя, повесть, романнардан тыш, фольклор өлкәсенә караган гыйльми характердагы мәкалә-тикшеренүләрдән тыш, берничә җыентык туплап һәм әдәби эшкәртеп чыгарырга туры килде.

Хәзер Алабугада торам һәм нигездә әдәби-иҗат эше белән шөгыльләнәм.

Җиденче сорау.

— Хәзер нинди әсәрләр өстендә эшлисез? Алдагы планнарыгыз нидән гыйбарәт?

— Бондюг химиклары тормышына багышлап язылган «Томан аша» исемле романның беренче китабы басылып ята. Шушы язны «Ады-Ады» исемле кечкенә бер повесть тәмамладым. Ул әлегә тәнкыйтьче дуслар кулында. Ә бу көздән химикларга багышланган романның икенче китабына тотынам. Тик шуннан соң гына, янәдән кайтып әйтәм, «Бир кулыңны, дустым!» повестеның дәвамын яза алырмын шикелле.

10 июль, Алабуга.

## Шәйхи Маннур

### «Патша кызы»

Күктән барам,
Тугыз чакрымнан,
Бөтен галәм — зәңгәр океан.
Күз камаша аның сафлыгыннан,
Җанга рәхәт кояш балкудан.

Шул гаҗәеп зәңгәр океанда
Йөзгән чакта һава корабы,
Пәйда булды кинәт әллә каян
Ап-ак мәрмәр болыт таулары.

Ак якуттай ак сарай бар анда,
Тәрәзләре — сиксән сигезләп.
Каерылып шунда караганда,
Калды бер кыз миңа кул изәп.

Ничек сөйлим аның матурлыгын!
Саф булуын, әдәп-инсафын!
Күзләреннән күрәм сабырлыгын,
Тагын бик күп, бик шәп сыйфатын!

Таныдым мин аны!
Гомер буе минем күңелдәге,
Хыялымның изге түрендәге
Патша кызы булып чыкты ул,—
Йөрәгемнән кысып тотты ул!

Җирдән аны күпме мин эзләдем,
Күпме, күпме кызлар күзләдем,
Ошатмадым ләкин һичберәвен,
Табалмадым күңел гүзәлен.

Илләр гизеп-гизеп, күрәлмаган,
Бик теләп тә, өзелеп сөялмаган
Хыял кызы —
Әнәтерә кайда икән ул:
Минем ише тинтәкләрдән качып,
Зәңгәр күккә менеп киткән ул!

Кул изәде якут сараеннан...
Шаярамы?
Тагын алдыйммы?
Ярата мы мине әллә чыннан:
«Таптың, егет, тизрәк ал!» диме?..

Юк, хыялым кызы — таң йолдызы,
Елмайма син болай сөйкемле.
Табылсаң да хәзер,
Чакырсаң да,
Яр булсаң да —
Бик-бик соң инде...

## Кызлар хаты

Хат язды кыз сөйгән егетенә,
Әйтеп бирде монсу яшәвен.
«Шик төшерә,— диде,— өметемә
Синең болай озак дәшмәвең.

Гел шашардай булам хат көтүдән,
Бер сүзеңә синең тилмерәм.
Почта килер сәгатьләрдә өйдән
Мең мәртәбә чыгам, мең керәм.

Көнләшеп тә куям анда сине
Карыйдыр, дип, әллә кемнәргә.
Оныткандыр, бәлки, күптән мине...
Уйга чумам ялгыз төннәрдә.

Хатың юкка инде биш көн менә!
Яратуың шул гынамыни?
Ара ерак булган өчен генә,
Сөйгән күңел суынамыни?..»

Адрес язды, конвертлады хатны,
Сумкысына салып куйды ул.
Шунда гына йокысына ятты,
Тынычланып күзен йомды ул.

Ун көннән соң...
Яулык эзләгәндә,
Килеп чыкты ул хат сумкыдан...
— Ах! — диде кыз, черки тешләгәндәй,—
Онытылган икән чукынган!

Һәм, сабыйча көрсез елмаеп, ул
Хатны салды зәңгәр әрҗәгә:
Инде җавап көтәр моңаеп ул,
«Сөйгән яры» озак дәшмәүгә...

## Борынгы шагыйрьдән

Барган идек хатын белән театрга,
Күңелләрдә яхшы хисләр уятырга.

Утырабыз чекердәшеп тату гына,
Ә сәхнәдә уен бара матур гына...

«Эх, әйбәт тә уйный соң шул Галимәкәй!
Үзе дә ул сөйкемле бер күбәләктәй!..»

Дигән идем... хатын кинәт көлмәс булды,
Күзләренә яман хәтәр ярсу тулды.

Ике очкын — гүя төнге киек күзе,
Кызган тимер суда чыжлый — һәрбер сүзе...

Туры килде миңа аннан тиз кайтырга,
Телемнен дә итәк-жиңен кыскартырга...

Бармыйм инде моннап ары театрга,
Хатыным бар яхшы хисләр уятырга.

## Картлар гыйшкы

Ник борчылам икән мин бүген?
Сизәм жаным тыныч түгелен...
Ятлар күзе керә алмаслык
Бикле микән синең күңелең?..

Сәер иттең мине, «карак» кыз,—
Урлап киттең тынычлыгымны.
Мин угырам көйләп бер ялгыз
Көзге жилдәй кырыс жырымны...

Акыл әрли.
Әйдә, әрләсен,
Алланың бу тинтәк бәндәсен.

Мүкләнмәгән йөрәк,
Нишләсен,
Ник көймәсен,
Нигә сөймәсен?
Бу сүзләр бик иске булса да:
Нигә, «жаным!»
«Бәгырем!» димәсен?

Дөрләсен ул,
Әмма сүнмәсен!
Татып бирсен, әйдә, һәммәсен,
Дусларыннан сине көнләсен.
Бер тилерү — үзе бер гомер!
Көймә тиздән
Комга төртелер...
Анда инде йөрәк дигәннән
Самавырга калыр тик күмер...

●

Омтыла кеше янага,
Иске итәктән тота.
«Кыю бул», дип әйтсәң аңа,
«Аю бар», дип куркыта.

Куркыта Куян абзанны
Һәм яшәтә сак кына,
Эчендәге Арысланны
Тик богаулап яткыра.

●

Кайтып булса сабый чагыма,
Әллә ниләр сорамыйча гына,
Йөрер идем «айт-тайт» уйнап,

Өстәл астына качып.
Бу искереп беткән дөньяны
Өр-яңа итеп ачып.

●

Женем сөйми көзге дигәннәрен,
Ватар идем бәреп,
Чалт! итеп —

Анлый белми һич тә бәндә хәлен:
Күрсәтә ул картны
Карт! итеп.

## Рәдиф Гатауллин

*Үз-үземә*
*ике шарж*

### Үпкә

Янган чагым булды! — бар дөньяга
ялкын бирер булып...
(Хәзер сүрелеп барам. Күгемдә дә
йөри соры болыт!)
Янган чагым булды! Шунда, кызлар,
Сөя алмадыгыз.
Нигә хәзер — сүрелер чакта гына
сөеп алдавыгыз?!
...Язган чагым булды! Давылланып,
Гейнеларча янып.
(Хәзер шактый үтмәсләнде каләм,
сөю-хиссез язып...)
Шагыйрь чагым булды! — Шунда, дуслар,
Бер сүз тапмадыгыз.
Хәзер, прозага күчәр көндә,
Нигә мактадыгыз?!

### «Бөеклек» турында

Бөекләрнен мин тормышын беләм:
Байрон — бөек, Пушкин — бөек, Хафиз — бөек.
Әмма — алар барыбер Кеше: синең кебек,
минем кебек.
(Юк дисәң дә, табып була бер кимчелек).
Әйтик, Байрон азрак аксак булган икән,
Хафиз — дәрвиш, гомере буе илләр гизгән.
Унмаганнар мәхәббәттән Пушкин, Гейне,
Ә Хәйямның сәрхуш булып гомере узган.

Булган, булган:
Беркатлылык, Дон-Жуанлык һәм башкалар...
Тик, уйласаң, бу сыйфатлар миндә дә бар.

Миндә дә бар! — Димәк, дуслар,
Фәкыйрегез — мин дә бөек?!
Әмма бәла: нидер минә житми, нидер ерак, биек.
Шуны уйлап, «бөек» күңелем бүген боек.

## Зәки Нури

### Өйләнүдән курыккан ирләргә

— Менә хатын, яңа сүзлекләр.
Русчаны бел, өйрән гарәпне!
— Кирәге юк! Синең өстеңнән
Мин сүзлексез язам әләкне.

— Менә эргән. Алтын ачкычлы.
Үзе уйный шуны борганда.
— Нәрсәмә ул! Миңа бик житкән
Уйнаулары синең нерваңда.

— Менә ваткыч. Аша чикләвек,
Шикәреңне вакла чәйләргә.
— Кирәк түгел! Колак итеңне
Үз тешем дә үтә чәйнәргә.

— Алдым менә яшен үткәргеч.
Кирәк иде безгә күптәннән.
— Кирәк, имеш!.. Кереп түбәңнән
Мин үзем дә чыгам үкчәңнән.

— Менә көзге. Шуның каршында
Чәчләреңне майлап тарарсың.
— Сиңа булсын! Тырнак эземне
Бит-башыңнан үзең карарсың.

— Токмачка он... ярма — бәлешкә...
Калганнарын тормыйм тезеп мин.
— Токмач итеп телеп-турармын
Камыр итеп сине изеп мин!..

* * *

Сез әйтерсез: кара буяуны
Шигырьдә дип, шагыйрь, мул тоттың.
Өйләнүдән курыккан ирләрне
Юри генә шулай куркыттым!

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## В. И. ЛЕНИННЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫ УҢАЕ БЕЛӘН

Август аенда Казанда культура работникларының Бөтенсоюз киңәшмәсе булды. В. И. Ленинның 100 еллык юбилеена багышлап үткәрелгән ул киңәшмәдә культура-агарту эшләре буенча Үзәк фәнни-методик кабинет вәкилләре, культура һәм ял парклары директорлары — барлыгы 180 кеше катнашты.

Киңәшмәдә республикабыз культура министры Б. М. Гыйззәтуллин доклад белән чыкты. Ул Ленинның 100 еллыгына хәзерлек уңае белән республикабыз культура учреждениеләре башкара торган эшләр хакында сөйләде. Бөек юлбашчыбыз юбилеена хәзерлек, диде ул, Татарстанда да киң җәелә. Күп кенә районнарда Ленин бүлмәләре, кинолекторийлар оештырыла, Ленин ордены белән бүләкләнгән хезмәт батырлары белән очрашулар үтә, юлбашчының тормышы һәм эшчәнлеге хакында, республикабызда Ленинга бәйле тарихи урыннар турында күргәзмә стендлар, альбомнар ясала, телдән журналлар чыгарыла. Киләчәктә бу эшләр тагын да киңрәк колач алачак.

Киңәшмәдә шәһәребезнең баш архитекторы иптәш Солдатов та чыгыш ясады һәм кунакларга алдагы елларда Казанда булачак төзелешләр турында сөйләде.

Республикабызның комсомол оешмалары, үзләренең юбилеен каршылап, культура-агарту учреждениеләре белән берлектә нинди эш алып баралар? Киләчәктәге планнар нинди? Комсомолның өлкә комитеты секретаре Роберт Фәрхиев әнә шул хакта сүз алып барды.

Кунаклар Казандагы истәлекле Ленин урыннарына: юлбашчының йорт-музеена, университеттагы Ленин аудиториясенә, В. И. Ленинның беренче сөрген урыны Ленино (Кокушкино) авылына экскурсия ясадылар. Алар шулай ук шәһәребезнең Максим Горький музеенда һәм крайны өйрәнү музеенда да булдылар.

Киңәшмәдә катнашучылар үзләренең эш тәҗрибәләре белән уртаклаштылар. Аннары алар шәһәребезнең үзәк культура һәм ял паркы эше белән таныштылар һәм Ленинга багышлап «Мәңге исән» дигән девиз астында үткәрелгән театральләштерелгән зур бәйрәмдә катнаштылар.

Киңәшмә барышында республика культура-агарту эшләре методик кабинеты директоры Хәлим Мөбәрәкшин, Халык иҗаты йорты директоры Габдулла Саликов иптәшләр кадрлар һәм үзешчән сәнгать түгәрәкләре белән эшләү тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

Мәскәү өлкәсе методик кабинеты директоры Александра Макаровна Ладаха В. И. Ленинның 100 еллыгына әзерлек уңае белән үз өлкәләрендә эшләнә торган эшләр турында сөйләде. Билгеле булганча, Мәскәү өлкәсе В. И. Ленинга бәйле булган тарихи урыннарга бик бай. 1894 елның җәендә Кузьминка поселогында В. И. Ленин «Нәрсә ул «халык дуслары» һәм алар социал-демократларга каршы ничек көрәшәләр» дигән әсәренең икенче һәм өченче чыгарышлары өстендә эшләгән, ул Подольскида, Горкида булган. Кашино авылындагы беренче авыл электростанциясен ачуда катнашкан. Пушкин районында булган, Можайский һәм Раменский районнары крестьяннары белән очрашкан.

В. И. Ленин булган тарихи урыннар юлбашчының тормышын һәм революцион эшчәнлеген халык алдында ачык һәм хәтердә калдырырлык итеп аңлатырга — бай материал. Мәскәү өлкәсендә 1400 культура-агарту учреждениеләре бар. Шуларның 1100 ендә Ленин бүлмәләре һәм почмаклары оештырылган.

Район культура йортлары каршында «Өчбуын клублары» эшли. Бу клубларның членнары В. И. Ленин, Надежда Константиновна Крупская, Михаил Иванович Калинин һәм башка күренекле революционерлар турында бай материаллар туплаганнар.

Пушкин шәһәрендәге культура йорты үзләренең якташлары, «Урак һәм Чүкеч» эмблемасының авторы художник Камволкинның тормышы һәм иҗади эше турында күп материаллар җыйнаган. Анда «Өчбуын клубы» членнарының инициативасы белән художникның квартира-музее ачылган.

Киңәшмә зур хәзерлек белән һәм кызыклы үтте.

Эстония, Үзбәкстан, Украина, Белоруссия һ. б. республикалардан килгән вәкилләр киңәшмәдә катнашкан барлык культура работниклары исеменнән мондый очрашуның бик файдалы булуы, киңәшмәдән күп яңалыклар алып китүләре турында әйттеләр.

## «ТАТАРСТАН ТАРИХЫ»НЫҢ ЯҢА БАСМАСЫ

Әле күптән түгел генә Татарстан китап нәшрияты «Татарстан АССР тарихы»ның үзгәртелгән яңа басмасын бастырып чыгарды. СССР Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан әзерләнгән ул китапка Казан дәүләт университеты һәм педагогия институты галимнәренең дә хезмәте кергән.

«Татарстан АССР тарихы»ның эшкәртелгән, өстәмә материаллар белән тулыландырылган һәм рус телендә чыгарылган бу яңа басмасы Җ. Гыйльманов, М. Мөхәррәмов, Ю. Смыков һәм Х. Хәсәнов иптәшләр тарафыннан әзерләнгән.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

### Унай бәя бирелде

Секциянең 13 августта үткәрелгән утырышында язучы-драматург Рәнсә Ишморатованың яшьләрне тәрбия итү проблемасына багышланган «Яшьлек канат җәя» исемле драма әсәрен укып фикер алышу булды. Секциядә катнашкан язучылардан Г. Мөхәммәтшин, Б. Гыйззәт, Л. Ихсанова, З. Шаһиморатов, Ә. Камал, Р. Ишморат, С. Шәкүров, Г. Зәйнашева, И. Беляев һ. б. иптәшләр, әсәрнең эчтәлегенә һәм художество ягыннан эшләнешенә уңай бәя бирү белән бер рәттән, аны тагын да яхшырту өчен авторга киңәшләр бирделәр.

Секция утырышында катнашкан Республика күчмә театрының баш режиссеры Равил Тумашев һәм режиссер Ленар Садриев иптәшләр пьесаны үзләренең театр сәхнәсендә куярга алынганлыклары турында да хәбәр иттеләр.

## ТЕАТРГА ТӘКЪДИМ ИТЕЛДЕ

Драма секциясенең 20 августта үткәрелгән чираттагы утырышында язучы Зәйни Шаһиморатовның «Йосыф-Зөләйха» исемле трагедиясе укып тикшерелде. Әсәр хакында фикер алышуларда драматурглардан Риза Ишморат, Хәй Вахит, Әнәс Камал, театр белгечләре Баян Гыйззәт, Мөнип Газар, Һәнүс Мәхмүтов һәм әдәбият белгече Шакир Абилов катнашты. Алар барысы да З. Шаһиморатовның бу яңа әсәре уңышлы язылганлыгын әйттеләр һәм аны Г. Камал исемендәге татар академия театры сәхнәсенә кую өчен секция исеменнән тәкъдим ясарга дигән карар кабул иттеләр.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР, ПОЧЕТ ГРАМОТАЛАРЫ

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының шушы елның 5 августында игълан ителгән Указы нигезендә, совет сынлы сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен, Татарстан художниклары Мәснәви Хәйретдин улы Хәйретдиновка һәм Иван Лаврентьевич Язынинга «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының шул ук көнне игълан ителгән Указы нигезендә, совет сынлы сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен, Татарстан художниклары Мәхмүт Усман улы Усманов һәм Николай Степанович Артамонов Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнделәр.

* * *

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының шушы елның 24 июлендә игълан ителгән Указы нигезендә, совет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен, Казан шәһәренең Ленин комсомолы исемендәге яшь тамашачылар театры артисты Василий Александрович Чернецкийга Татарстан АССРның халык артисты, шул ук театрның артистлары Валентина Прокофьевна Козловага, Юрий Александрович Максимовка һәм Борис Залмонович Роскинга Татарстан АССРның атказанган артисты дигән мактаулы исемнәр бирелде.

## УКЫРГА КИТТЕЛӘР

Бу ел А. Н. Островский исемендәге Ленинград дәүләт театр, музыка һәм кинематография институтына ундүрт татар егетләре һәм кызлары укырга китте. Анда укырга керергә теләүчеләр күп булды. Татарстаннан гына түгел, бәлки Астрахань, Оренбург, Алма-Ата һәм Пермь шәһәреннән дә байтак кеше имтихан тапшырырга килгән иде. Кыскасы, имтихан алырга Ленинградтан килгән күренекле педагогларга — РСФСРның атказанган артисты, актерлык осталыгы кафедрасы доценты, булачак татар студиясе җитәкчесе А. Ян, сәхнә теле кафедрасы доценты вазифасын башкаручы З. Савкова һәм институт укытучысы, А. С. Пушкин исемендәге Ленинград академия театры артисткасы Л. Дачко иптәшләргә эш күп булды. Һәм алар әлеге күп санлы татар егетләре һәм кызлары арасыннан иң өметле ундүрт иптәшне студиягә укырга кабул иттеләр.

## ТАТАР АРТИСТЛАРЫ УРТА АЗИЯДӘ

Татарстанның атказанган артисты Илһам Шакиров җитәкчелегендәге артистлар группасы күптән түгел генә Урта Азиядә гастрольдә булып кайтты. Үзбәкстан һәм Кыргызстанның Ташкент, Фергана, Нәмәнган, Андижан, Фрунзе, Ош, Җәлал-Әбад һ. б. бик күп шәһәрләрендә татар артистлары кырыктан артык концерт куйдылар.

Җырчыбыз И. Шакиров белән бергә, бу концертларда Татарстанның атказанган артисткасы, танылган биюче Зәйтүнә Абдуллина, баянчылар Рәфкать Гомәров, Ирек Галимов, Зиннур Гыйбадуллин һәм яшь язучы Роберт Батуллиннар да уңышлы чыгыш ясадылар.

Халкыбызның борынгы җырларын, татар композиторларының яңа әсәрләрен, татар-башкорт биюләрен, шагыйрь-язучыларыбызның әсәрләрен Кыргызстан һәм Үзбәкстан тамашачылары бик яратып кабул иттеләр.

— Башка республикада яшәүче татарлар сәнгатебез кешеләре белән очрашуга бик тә сусаганнар,— ди Р. Батуллин,— һәр

калада клублар, культура сарайлары, ял паркларындагы ачык заллар һәрвакыт шыгрым тулы була. Хәтта кайбер шәһәрләрдә, тамашачы соравы буенча, рәттән 2—3 концерт куярга туры килгәләде. Һәммә жирдә концерттан соң бер үк сүзләрне ишетә идек: «Артист туганнар! Сирәк киләсез, язучыларыбыз ун елга бер генә күренә, Казанга кайткач башка артистларга һәм язучыларга житкерегез: ешрак килсеннәр!»

Ай ярымлык бу гастрольдә артистлар 20 меңнән артык тамашачыга культура хезмәте күрсәтте.

## КЫЗЫКСЫНЫП КАРАДЫЛАР

Кама буена урнашкан борынгы Алабуга шәһәрендәге атаклы художник Иван Иванович Шишкин музей-йортын карарга һәр җәйне бик күп кеше килә торган иде. Ә узган җәйдә Шишкин музеенда аеруча зур җанлылык хөкем сөрде. Чөнки бу ел анда бөек художникның өйрәнчеге Николай Николаевич Хохряков картиналарының күчмә күргәзмәсе оештырылган иде. Күргәзмәдә Н. Н. Хохряковның Кировтан А. М. Горький исемендәге музейдан китерелгән 89 картинасы күрсәтелде. Вятка һәм Кама буйлары табигатенең матурлыгын чагылдыручы ул картиналарны тамашачылар бик кызыксынып карадылар. Художникның «Алтын көз», «Авдышева авылы», «Елгадагы күпер» исемле картиналары һәм интерьерлары күргәзмәгә килгән кешеләрдә аеруча зур соклану хисе тудырды.

## ОПЕРЕТТА ҺӘМ ЖЫР КИЧӘСЕ

Республикабызның Минзәлә шәһәре культура йортында Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры артистлары оперетта һәм җыр кичәсе үткәрделәр. РСФСРның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты Фәхри Насретдинов, ТАССРның халык артисткасы Рәйсә Билялова, Татарстанның атказанган артисты Йосыф Гыйззәтуллин һәм артист Габдрахман Сәлимов башкарган татар совет композиторлары әсәрләре, халык җырлары һәм биюләре Минзәлә тамашачылары күңелендә җылы тәэсир калдырды.

* * *

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры артистларының бер төркеме Ульяновскига һәм Ульяновск өлкәсе районнарына барып концертлар бирде. Артистларның барлык концертлары да уңышлы үтте. Ульяновск тамашачылары РСФСРның атказанган артисткасы З. Хисмәтуллина, Татарстанның атказанган артисты Н. Ишбуляков, артистлар Ә. Заһидуллина, Х. Гыйниятова, баянчы М. Макаров, биючеләр Л. Бакеев һәм Н. Шакиров чыгышларын яратып кабул иттеләр.

## ЛАТИН АМЕРИКАСЫ АРТИСТЛАРЫ КАЗАНДА

Шушы елның август аенда Латин Америкасы артистлары Казанда гастрольдә булып киттеләр. Латин Америкасының унөч илennән килгән сиксән биш артист тарафыннан Спорт сараенда башкарылган концертларны Казан тамашачылары бик яратып кабул иттеләр. Чилидән килгән «Лос Кампесинос» вокаль-инструменталь квинтеты башкарган көйләрне, Кармен Венегас җырлаган чили халык җырларын, Венесуэла җырчылары Роса Вирджиния Чосин һәм Карлос Отера җырлаган җырларны; Бразилия вокаль-хореографик ансамбль башкарган биюләрне, парагвайлы Луис Альберта дель Паранз житәкчелегендәге «Лос Парагвайос» ансамбле, Ямайка җырчысы Тотлин Мелседес Джексон, Мексика, Перу, Боливия һәм Уругвай ансамбльләре чыгышлары казанлыларда аеруча җылы тәэсир калдырды.

* * *

Бөтенсоюз конкурсы лауреаты язучы-сатирик Игорь Мэй, композитор Илья Лазовский һәм җырчы-шагыйрь Леонтий Шишко, Ленинградтан килеп, Казан тамашачылары алдында утыздан артык чыгыш ясадылар. Аннары алар сентябрь аенда республикабызның нефть районнарында комсомолның 50 еллыгына багышлап үткәрелгән фестивальдә катнаштылар. Тамашачылар аларны һәркайда хуплап каршы алды.

## ОЧРАШУЛАР

Язучыларыбыздан Нәби Дәүли, Зәки Нури һәм композитор Арслан Батыршин Леонов исемендәге пионерлар лагерендә ял итүче пионерлар белән очраштылар. «Туган илеңне ярат!» дигән девиз белән хәрби-патриотик темага багышлап үткәрелгән ул очрашуда шагыйрь Зәки Нури үзенең Ватан сугышы елларында партизан булып фашистларга каршы көрәшеп йөргән вакытлары, язучы Нәби Дәүли сугыш елларында дошман концлагеренда тоткынлыкта булган совет солдатларының ничек итеп фашистларга каршы яшерен көрәш алып барулары хакында пионерларга кызыклы һәм гыйбрәтле истәлекләрен сөйләделәр, аннары пионерларга үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар.

Композитор А. Батыршин пионерларга хәрби-патриотик темага язылган көйләрне баянда уйнап күрсәтте.

Соңыннан пионерлар Туган ил турындагы җырларны башкардылар.


* * *

Язучы Мәҗит Рафиков һәм шагыйрь Рәшит Гәрәй Балык Бистәсе районының «Габдулла Тукай», «Татарстан», «Маяк», «Победа», «Россия», «Кызыл юл» һәм Калинин исемендәге колхозларында китап яратучылар белән очрашулар үткәрделәр. Алар ул очрашуларда бүгенге татар әдәбияты турында сөйләделәр һәм укучыларны үзләренең яңа әсәрләре белән таныштырдылар.

* * *

Язучыларыбыздан Атилла Расих, Гөлшат Зәйнашева һәм Роберт Әхмәтҗанов Норлат районының «Дружба», «Татарстан», «Комбайн», «Алга», «XXI партсъезд» һәм «Игенче» колхозлары колхозчылары белән очрашулар үткәреп кайттылар. Халык аларның чыгышларын бик җылы кабул итте.

* * *




1941 елны Муса Җәлил Курск өлкәсенең Марьино поселогында хәрби курсларда укыган. Хәзер бу бинада мемориаль такта куелган.

## ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯЛӘР

Апас районының Муса Җәлил исемендәге колхозында, ел саен герой-шагыйрьнең туган көнендә, производство планнарын намус белән үтәүче, әдәбият һәм сәнгать белән кызыксынучы, җәмәгать эшләрендә актив катнашучы, семьяда һәм кешеләр арасында үзләрен әйбәт тотучы өч колхозчыга «Колхозның Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты» дигән исем бирелә. Лауреатларга шул хакта таныклык тапшырыла, алар Почет кенәгәсенә кертеләләр, портретлары клубка эленә.

Кандидатларны «Муса Җәлил премиясе комитеты» билгели. Комитет колхозчының үзенә тапшырылган производство планын үтәве, ел буе ничә китап укуы, ничә фильм һәм спектакль каравы, җәмәгать эшендә ничек катнашуы белән кызыксына. Аннары колхозчыларның гомуми җыелышына тәкъдим кертә.

Алдынгыга лауреат исеме бирү көне колхозда бәйрәм булып санала. Бу көнне герой-шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында лекцияләр укыйлар, үзешчәннәр концертлары була, кичен клубта яңа лауреатларны хөрмәтләү үткәрелә.

Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты исеме иң беренче булып колхозның карт механизаторы, механик Мөбәрәкша Мөхәммәтшинга бирелде. Ул 100 сум күләмендәге беренче дәрәҗә премияне алды. 80 сумлык икенче дәрәҗә премия чуваш кызы, сыер савучы Мария Зантимировага бирелде. Тракторчы Рифкать Шакиров өченче дәрәҗә премиягә лаек дип табылды.

Быел беренче премияне шикәр чөгендере звеносы җитәкчесе, рус егете Петр Викторович Синягин, икенче премияне комбайнчы, чуваш егете Николай Маркелович Чернов, өченче премияне сыер савучы, татар кызы Нурҗиһан Хәлилова иптәшләр алды. Николай Чернов М. Җәлил премиясе лауреаты исемен инде икенче кат яулады.

Быел районның Тукай исемендәге колхозы да Габдулла Тукай исемендәге 3 премия билгеләде. Колхоз лауреатлары 1969 елда, шагыйрьнең туган көнендә билгеле булачак.

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗГА АЧЫК ХАТ

Бу эшлекле, конкрет һәм, уйлавыбызча, һичшиксез нәтиҗәле буласы сүзне, хөрмәтле иптәшләр, без, барыннан да элек, сезгә — журналның барлык укучыларына, аны язучы һәм таратучы күп санлы актив җәмәгатьчеләргә Татарстан язучылары союзының, «Казан утлары» редколлегиясе һәм редакциясе коллективының зур рәхмәтен белдерү белән башлыйбыз. Сез бу рәхмәтнең тормыш белән әдәбият бәйләнеше, укучылар белән әдипләр дуслыгы көннән-көн ныгый баруын, күңелләрегезнең яхшы әдәби әсәргә, нәфис сүзгә һаман саен көчлерәк тартылуын күреп әйтелгән куанычлы рәхмәт икәнен, әлбәттә, аңлыйсыз.

Сезнең киңәшләрне, сез белдергән теләкләрне, журналда басылып чыккан теге яки бу әсәр турында әдипләр һәм укучылар фикерен искә алып, без һәрвакыттта да «Казан утлары»ның тематик һәм жанр офыкларын киңәйтергә тырышып, әдәбият сөючеләрне анык яңа ачышлары белән күбрәк куандырырга, яшь һәм яңа талантлар белән ешрак очраштырырга теләп, гомуман биш миллионлы халкыбыз өчен татарча бердәнбер калын әдәби журналның идея-эстетик сыйфатын югары итү максаты белән эшләдек һәм эшлибез.

Инде үтеп бара торган бу елда, мәсәлән, «Казан утлары» 64 меңнән артык тираж белән чыкты. Димәк, татар язучыларының соңгы елларда һәм соңгы айларда иҗат иткән иң яхшы роман яки повестьларын, хикәя яки очеркны, шигырь яки поэманы, тәнкыйть мәкаләсен яки публицистик чыгышны, әдәбият, сәнгать һәм культура өлкәсендә күренекле әдипләребезнең иҗаты турындагы исбатлы сүзне, халкыбыз һәм әдәбиятыбыз тарихына яңа материалларны күп санлы укучыга, беренче булырак һәм мөмкин кадәр тиз рәвештә, шул журнал ирештерде.

Ә инде газета һәм журналларга 1969 елгы подписка «Казан утлары»ның алдагы саннары белән тагын да күбрәк укучыны очраштырыр дип ышанырга кирәк. Ул яңа саннарның материалын мул да, күп төрле дә, сыйфатлырак та итү өчен редакция бик күп көч куя. Чөнки алар әеруча җаваплы буласы саннар — тур урынны бөек юлбашчыбыз Ленинның 100 еллыгы һәм туган республикабыз Татарстанның 50 еллык юбилее уңае белән әдәби тантанага бирәсе саннар бит! Алар республикабыз һәм халкыбызның бүгенге казанышларын һәм ирешкән уңышларын көр тавыш белән зурлый торган көчле, истәлекле, матур яңгырашлы сүз әйтергә тиешләр. Казанда укыган, революцион эшчәнлеген Казанда башлаган, Татарстан җирендә яшәгән Ленинның безгә кагылышлы һәр документны эзеннән йөреп, Казаннан киткәч ул булган бик күп урыннарга барып республикабыз язучылары күп төрле яңа әсәрләр иҗат итә алалар һәм иҗат итәчәкләр. Бу темага чыгышлар системалы, дәвамлы һәм һәр санда булыр. Революция ветераннары, сугыш һәм хезмәт геройлары булган, культура һәм фән өлкәсендә дан казанган якташларыбыз турында олы һәм җылы сүзне сез журналның «Батырлар китабына» дигән яки «Замандаш» исемле даими бүлекләрендә укырсыз. Безнең шулай ук даими дәвам иттереләчәк юмор һәм сатира бүлекләребез (берсе «Елмаеп-көлеп кенә», икенчесе «Ут чәчеп һәм ук чәнчеп» исемле) бар. Балалар өчен яңа һәм кызыклы әсәрләр язучы авторлар иҗаты, билгеле булганча, «Балаларга укыгыз» бүлегендә урнаштырыла. Яңа китаплар турындагы һәр төрле бәлешмәләргә һәм тәнкыйть-библиографик материалларына без «Синең китап киштәңә» рубрикасы белән киң урын бирәчәкбез. «Дуслар җыры» битләрендә исә тугандаш әдәбиятлардан һәм дөнья әдәбиятыннан иң яхшы үрнәкләрнең татарчага тәрҗемәләре басылачак. Төрле милләтләрнең халык иҗаты энҗеләре дә шунда ук урын алыр. Журнал сезне республикабызның барлык күренекле композиторлары, җырчылары, художниклары һәм сәхнә осталарының иҗат портретлары яки яңа иҗади казанышлары белән таныштырып баруны планлаштырды. Һәр санда бер-ике язучының рәсемен яки фотосын биреп, без мәктәпләрдә, китапханәләрдә һәм барча культура учакларында әдәби стендлар яки фотоальбомнар булдыру эшенә дә өлеш кертергә телибез.

Кыскасы, яратып укыр нәрсә күп булырга тиеш. Якындагы саннарда нинди яңа әсәрләр басыласын без алдан ук хәбәр итеп торачакбыз. Подпискасы инде башланган яңа елга хәтле, мәсәлән, журналда Ләбибә Ихсанованың «Ана көндәлеге» исемле повесте, Эдуард Касыймовның «Томан аша» романыннан зур өзек, Шәйхи Маннур, Нәби Дәүли, Гамил Афзалның юмористик, Хәсән Туфанның сатирик шигырьләре, Ибраһим Гази, Ибраһим Сәләхов, Әхәт Фазылҗанов, Илдар Юзеев хикәяләре, яшьләребездән Мөдәррис Әгъләмов, Мөхәммәт Садыйков, Гәрәй Рәхим һәм башкаларның шигырьләре чыга. Ленин турындагы хикәя, шигырь һәм истәлекләргә шактый урын бирелә. Һәр санда нотасы белән басылган бер яңа җыр, бүгенге көн темасына берничә очерк булачак. Журнал өчен Атилла Расихның «Каһарманнар юлы» романы, Әмирхан Еникиның «Вөҗдан», Фатих Хөснинең «Гыйльменисса», Хәсән Сарьянның «Кнопкалы өтер», Әхсән Баяновның «Декабрьнең 13 көне» повестьлары, Сибгат Хәкимнең Курск дугасындагы сугыш темасына шигырьләренең зур циклы әзерләнә һәм редакцияләнә. Юныс Әминов, Газиз Иделле иптәшләр берәр пьеса тәкъдим иттеләр. Дисталәгән яңа китап турында фикер бар.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Үзегез торган яки эшләгән урыннарда шуларның барысы турында да сөйләп, сез 1969 елда журналны тагын да күбрәк тарату эшендә булыша аласыз. Бу хатны бүтәннәргә дә укыгыз һәм подписка вакытында актив эшләргә тырышыгыз. Туган илебезнең барлык почмакларында диярлек укылган «Казан утлары»ның нуры күбрәк күңелләрдә, күбрәк урында балкысын.

1969 елда журналның күләме тагын ике табакка артачак. Ул Бөтенсоюз каталогы буенча таратыла — аңа Советлар Союзындагы теләсә кайсы почта бүлегендә язылырга мөмкин. Моның өчен журналның каталогтагы 73210 номерлы индексын әйтергә кирәк. Почта белән акча җибәреп (аена 50 тиен исәбеннән) аны Казаннан да алдырып була.


*Адрес: Казань, ул. Куйбышева, 17/26, отдел Союзпечати.*


***РЕДАКЦИЯ.***

# КАЗАНЫМ

ӘНВӘР БАКИРОВ музыкасы

ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВА сүзләре






Анчарлан булам мин,
Дулкынга кунам мин,
Иделем киңлеген кичкэндэ.
Анчарлан шикелле,
Ак йөзле, сөйкемле
Ирнам дә Иделдә үсканга.

Кушымта:

Казаным, Казаным,
Дан, шөһрат казандың.
Диңгезлэр дулкыны — Иделдэ.
Бу матур заманда,
Яшәсәң Казанда,
Мәхәббәт сүрелми күңелдә.

Анчарлан булам мин,
Дулкынга кунам мин,
Иделдә яңа җыр туганда.
Җыр төрле, моң төрле,
Гүзәллек мең төрле,
Илемдә дуслар күп булганга.

Кушымта.

Анчарлан булам мин,
Дулкынга кунам мин,
Иделем диңгезгә тиң хәзер.
Кулы гел хезмәттә,
Үзе гел хөрмәттә,
Халкымның колачы киң хәзер.

Кушымта:

Казаным, Казаным,
Дан, шөһрат казандың.
Диңгезлэр дулкыны — Иделдә.
Бу матур заманда,
Яшәсәң Казанда,
Мәхәббәт сүрелми күңелдә!..

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210